1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН
№ 12 / 2021

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ӨМЕТЛӘР чыршысы
хыяллар чынга аша

тормыш дәвам итә
«КЫЗЫЛ ЗОНА»дан
репортаж

бәйрәм табынында – ДЕЛИКАТЕС

Резеда СӘМИГУЛЛИНА:
«Күңел касәләре яратудан мөлдерәмә булсын!»

PRESSA



БЮРО B БАНУ





ТР, Казан, Габдулла Тукай ур., 72 нче йорт, 2 нче офис.
Тел. +7 917-250-25-89 burobanu Реклама

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2021



Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зәлия Ахунова, Ирада Әюпова, Зилә Вәлиева, Гөлүсә Батталова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Альбина Насыйрова, Алсу Нәбиева, Сәрия Сабурская, Гүзәл Сәгыйтова, Нурия Һашимова, Рафаэль Шәвәлиев.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Алсу Шакирова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррире
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Резеда Сәмигуллина
Фото: Анна Арахамия

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр
Ильмира Сөләйманова
Виталий Матвеев

Формат: 225x290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 29.11.2021 ел.
Чыгу көне: 10.12.2021 ел.
Заказ Е-3987
Тираж 10526

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: П0279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+





Фото: Газинур Хафизов

Эльвира ҺАДИЕВА

Аклык кайта

Буран бүген, дисең, чыкмыйк әле,
Күңелләрне чуалдырган бу ташуга.
Ә мин сиңа карап елмаям да,
Шәлъяулыгым бөрким –
Җан ашыга!
Анда бүген котып түгел –
Җылы бигрәк.
Рәхәт шундый, коелса да галәм үзе.
Күрәсеңме –
Гасыр төсе бу чоңгылда,
Әни ялъяпкычы кебек җиһан,
Әти эзе...
Күрәсеңме, кичәгечә янмый анда
Моңсулыкның үзе булган ярым ай да...
Буран түгел, бәгырь, җиргә әрнеп-әрнеп
Аклык кайтадыр ул...
...Бары аклык кайта!

Безнең тышлыкта

«Мине иң тетрәндергәне – ата-ананың баласын җәберләве. Шундый якын кешеләрең синнән кан-яшь түктерсен әле?! Нигә андый әти-әниләрне мәҗбүри рәвештә психологка йөртергә дигән закон юк икән дип, гел уйлыйм. Күп гаиләләрне шулай коткарып калырга булыр иде.»



10 Җандагы ташлар
Гөлнур Сафиуллина

Заман һәм без



6 Барысы да әйбәт булыр!
Чулпан Галиәхмәтова



16 «Күңелдә үкенечләр юк...»
Гөлнур Хәсәншина



14 «Ак Барс, алга!»
Гөлнур Хәсәншина



20 «Ретро җырларга гашыйк без»
Чулпан Галиәхмәтова

Татар дөньясы



22 Татарны Европада танытасым килә
Вәсилә Рәхимова



26 Уңышым – шәкертләрем
Эльмира Закирова



30 Үз юлым белән барам...
Алсу Шакирова

Мәдәни тормыш



36 Буран
Гөлнур Сафиуллина

Яшәеш



44 Могҗиза
Фәгыйлә Шакирова



48 Аркаим кояшы
Гөлүсә Закирова

Хуҗабикә

57 Яңа ел макияжы
Чулпан Юнысова

58 Яңа елны көткәндә...
Ләйсән Рәхмәтуллина



60 Бәйрәм табынына – деликатес









Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

БАРЫСЫ ДА ӘЙБӘТ БУЛЫР!

«Үзем өчен түгел, балам өчен куркам»

Республика клиник хастаханәсенең Перинаталь үзәгенең ишек төбендә басып торам. Каршыдагы утыргычка яшь хатын килеп утырды. Ике бала анасы булган бар тәҗрибәмне искә төшереп, аны күзәтәм. Бүген булмаса, иртәгә бала табачак. Үзе генә килгән, бик тыныч... Димәк, беренче баласы түгел. Йөзендә елмаю. Димәк, бар да яхшы.

– Кемне көтәсез? Кайчан табасыз? – дип сорыйм, күзләребез очрашкач.

– Кыз! Вакыты җитте инде. Монда табарга килешү төзедем. Табибка күренергә килдем, – дип елмая ул.

Танышып киттек. Динара исемле икән. Туачак кызларына исем дә сайлап куйганнар – Даяна. Үземне кызыксындырган сорауны бирергә ашыгам: «Бүгенге эпидемиологик вазгыятьтә ничек курыкмый бала табарга булдың?»

– Ә нәрсәгә куркырга?! Ковид белән инде ике тапкыр авырырга өлгердек. Җиңел кичердек. Авырмый гына тормыйсың, иң мөһиме – тиз үтсен. Улыбыз Тимурга 4 яшь тулды менә. Балаларның яшь аермасы аннан да зуррак булырга тиеш түгел дип саныйбыз ирем белән. Икенчесен алып кайтырга булдык. Әле монысын җиңелрәк тә күтәрдем кебек. Чир килер дә китәр ул, Аллаһы Тәгалә биргәндә балаларны вакытында табарга кирәк... Балалар бит ул – бәхет!

Динара янына табибы чыкты. Гөр-гөр килеп, кереп киттеләр. Минем янга да хастаханәнең матбугат хезмәте җитәкчесе Валерия килеп басты. Ниятем – «кызыл зона»га кереп, авыру әниләр, табиблар белән аралашу.

Безне Перинаталь үзәгенең бала тудыру бүлеге мөдире, вакытлыча инфекцион госпиталь җитәкчесе Светлана Гобәйдуллина каршы алды. Коронавируска каршы көрәш максатында оештырылган госпиталь изоляторына авыры 22 атнадан узган авыр хәлдәге хатыннарны алып киләләр. Без кергәндә бүлектә 66 пациент бар иде. Табиблар төгәл саннар әйтеп сөйләшми, чөнки бер-ике сәгать эчендә бу саннар бөтенләй үзгәреп куярга да мөмкин.

Бүлмәдә (табибларның ял итү бүлмәсе, ахры. Анда караватлар да, чәй өстәле дә бар) махсус костюм, озын кунычлы бахилылар, баш киеме кигәннән соң «кызыл зона»га керәсе ишек төбендә шәфкать туташы Наташа ике кат перчатка, респиратор, күзлек кидерә. «Көнгә йөзешәр кеше киендерәм шулай», – ди ул. Кулларына күз иярми,







Фото: Светлана Бочкарёва

Менә ике ел инде кешелек COVID-19 инфекциясе белән көрәшә. Бу чир Җир шарын бик тиз колачлап алса да, кешелек бирешми. Ә хәтерегездәме, Россиядә пандемия игълан ителеп, өйдә утыра башлагач, дөнья туктап калыр, килеп кергән тоннельдә якты ут булмас кебек тоелган иде. Коронавирус авыруы башлангач, хатын-кызлар да балага узудан куркып калырлар кебек иде. Юк икән, ана булу теләгенә вирус кына чик куя алмый. Моны раслап, көн саен балалар туа. Сау-сәламәт балалар туа...

ашыгудан борын очларына тир бәреп чыккан. «Бер операция ясаганда гына да «кызыл зона»га 12 кеше кирәк. Ә авыруларны карар өчен көнгә әллә ничә тапкыр кереп чыгабыз, – ди Светлана Владимировна. – Наташа иялэшеп бетте инде ул». Табиб һәрберебезне тикшереп чыга. Күзлек, борын тирәләренә җилем-ленталар ябыштырта. «Һава кереп, күзлегегез дымлана икән, бернәрсә күрмәячәксез», – ди ул. Әле болай да күзнең күрүе авырлашты – бөтен дөнья яшькелт төстә. «Киенергә өлгермичә керергә туры килгән чак булдымы?» – дип сорыйм, табиб артыннан калмаска тырышып йөгерә-атлый. (Болай киенеп йөрү бик кыен икән. Аяк та сизми, бармаклар да тоймый кебек.) Табиб барган җиреннән кисәк кенә борылды. Битлек астыннан бары зур зәңгәр күзләре күренә. «Беләсеңме, безнең хакта Дзержинский нәрсә дигән? «Табибларның куллары чиста, йөрәге кайнар, башы салкын булырга тиеш!» Башсызланып, үз сәламәтлегебезне куркыныч астына куярга тиеш түгел без. Беркайчан да!

«Кызыл зона»га керүгә үк каталкада ятучы алҗыган, әмма бәхете йөзенә чыккан хатынны күрдек. Бала тапканнан соң әниләрнең йөзләре шундый була! Әле яңа гына Эльвираның кызы туган. Беренче баласы! Табар вакыты җиткәч кенә коронавирус эләктергән. «Балам өчен бик курыктым», – ди. Булачак әнине монда китергәннәр. Ике көннән соң үзе сау-сәламәт кыз таба. Беренче тапкыр күрешү мизгелләре булмаган. Баланы ананың күкрәгенә дә куймаганнар. Ул әле нарасыен сыйпый да алмаган. Сабыйның киндеген тиз генә кискәннәр дә, алып та киткәннәр. Бу – саклык чарасы. Бала бернинди инфекцияләрсез туа бит. Ана сабыен фотодан гына күргән. Педиатрлар әниләргә шулай сәлам хаты җибәрә икән. «Баламны тереләч кенә күрәм бугай хәзер», – ди Эльвира. Ул хәтта авыруы турында оныткан кебек, әни булган бит. Моннан да зур шатлык юк! Әнә, безнең котлауларга рәхмәт әйткәндә, куанычтан авызын да җыеп ала алмый. Бала тудыру залын үтеп (ә ул үзе бер автоном хастаханә кебек. Монда тормыш итәр өчен бар нәрсә дә бар!), реанимациягә керәбез. Палатада аппаратлар эшләгән тавыш һәм авыру хатыннарның йөткергәне ишетелә. Алар чиратлап йөткерә кебек: берсе туктый, икенчесе башлый. «Хәлләрегез ничек, кызлар?» – Светлана Владимировнаның шат тавышын ишетеп, авырулар башларын күтәрә. Палатада яткан тугыз хатын йә кислород битлек кигән, йә борыннарына кислород бирүче көпшәләр тыгылган. Юлия инде ике атна реанимациядә ята икән. Башта туган шәһәре Бөгелмә хастаханәсендә дәваланган. Хәле авырлашкач, Казанга җибәргәннәр. Өч көн ИВЛда булган. Туасы сабые 28 атналык, өйдә дә сабые көтә. «Балаларым турында гына уйладым. Ходайдан сорадым. Хәтта туганнарым чиркәүгә барып минем өчен шәм куйды. Тизрәк өйгә кайтасым килә», – ди ул. «Бүген син кислородсыз бит, әйеме. Ашыкма әле өеңә кайтырга. Ныклап дәваланып бетәргә кирәк. Бала табасың бар», – ди аңа табиб. Юлиянең күршесендә генә Камилла. Ул да йөткерә-йөткерә генә сөйләшә.

– Мин – монда, балаларым – Республика балалар клиник хастаханәсендә, – ди ул яшьле күзләрен яшереп кенә сөртергә тырышып. – Бала тудыру йортыннан чыгуга ук ипотекага рефинансирование ясатырга банкка бардык. Шуннан «ияртеп» алып кайттык, ахрысы. Улым белән икәүләп авырый башладык. Тикшерткәч, барыбызда да ковид булганы ачыкланды. Ирем генә авырмый. Ул прививка ясаткан иде. Кайнанам да хастаханәдә. Улымда



Алексей ЕВСТРАТОВ, Перинаталь үзәгенең анестезиология һәм реаниматология бүлеге мөдире

– «Кызыл зона»дагы пациентларның иң куркыныч дошманы – паника һәм курку. Сәламәт авырлы хатын да бала тудыру залына кергәч, йә операция өстәләнә яткач, борчыла башлый. Ә коронавирус белән авырганда, икеләтә курка. Дәвалау бит ул – табиб белән пациентның уртак эшчәнлеге. Терелү өчен авыру беренче чиратта үзе тырышырга тиеш. Безнең бүлеккә үтә дә авыр хәлдәге авыруны китерделәр. Кабул иткәндә үпкәсе 15 процентка зарарланган булса, ике көн эчендә 65–70 процентка кадәр артты. Көмәненең срогы кечкенә иде. Бик нык паникага бирелде. Хәле көннән-көн начарланды. ИВЛга тоташтырып, ясалма комага җибәрергә туры килде. Терелүенә өмет юк диярлек иде. Шул көннәрдә авыруның әнисе белән кызы килде. Алар янына чыктым. 7 яшьләр чамасындагы бала күзләремә туп-туры карады да: «Минем әнием үлмәячәк бит? Сез бит аны терелтәчәксез?» – дип сорады. Бу вакыттагы халәтемне аңламассыз... Балага «белмим» дип әйтергә хакым юк иде. Кечкенә кешенең күңелендә табибларга карата ышаныч бетәр, алар бернәрсә дә белми дигән фикер калыр иде. «Әйе, әлбәттә. Барысы да яхшы булачак!» – дидем. Шундый зур җаваплылык иде бу! Бер атнадан соң авыру үзе сулый башлады. Хәлен белешергә килгән туганнары янына чыкканчы, пациент янына килдем дә, кәгазь каләм биреп, хат язарга куштым. «Мин терелдем, барысы да яхшы», – дип, шарлар, йөрәк рәсемнәре ясап, хат язды ул. Чыгуга: «Әниеңнән», – дип, хатны кызга суздым. «Мин әниемнең терелачәген белә идем. Сез бит сүз бирдегез», – диде ул. Чынлап та, хатын терелеп гаиләсе янына кайтып китте. Кызганыч, карындагы баланы коткара алмадык, әмма өйдәгеләрне ятим итмәдек. Әнә шундый өметсез авыруларны терелтергә, безнең тырышлыктан кала, могҗиза да, биргән вәгъдәләр дә ярдәм итә, күрәсең. Бары тик авыру үзе, туганнары гына өметен өзмәсен.

пневмония, өч атналык кызым билгеләрсез генә үткәрә. Иремә бик авыр инде аларны карарга. «Һаман елый да елый, ничек тынычландырырыга соң аны?» – дип, гел шалтырата. Ярый әле аңа ярдәмгә улыбыз бар. Ул зур инде – 3 яшь. Әтисенә булыша. Күңелем белән шулар янындамын. Алар өчен дә борчылам, үзем өчен дә... Балаларыма сау-сәламәт килеш кирәк бит мин. Ковид авыруының нәрсә икәнен беләм – әбием шуннан үлде... Үземә дә тын алырга авыр булды, температура югары, бизгәк тотты. Һава җитмәгәндә бик авыр икән. Күкрәк сөтемне югалтасым килми: һаман савып торам. Кызыма күкрәк сөте имезәсем килә. Аңа хәзер әни сөте бигрәк тә кирәк...

Реанимация шәфкать туташы Миләүшә Нургалиева Юля янына килеп, кислород битлеге кияргә кирәклеген әйтә. «Реанимация болай да тыныч урын түгел. Хәзер бигрәк тә. Авырулар күп. Октябрь аенда берьюлы 22 хатын ятты. Узган ел да октябрьдә шулай булган иде. Бүген менә тугыз авыру гына. Бу аз дип исәпләнә инде. Минут эчендә аларның хәлләре үзгәрергә мөмкин. Һәрвакыт игътибарлы булырга кирәк. Реанимация ясаган вакытлар да булды. Җитмәсә, бу авыру психикага да тәэсир итә. Паникага бирелгәннәр дә була. Аларны тынычландырабыз. Авыр, әмма без күнектек инде. Шунысы зур шатлык: сау-сәламәт балалар туып тора», – ди Миләүшә.

Ишек янында яткан авыру яшь әни чалкан яткан. Ул борынына җайланган көпшәләрдән селкенергә түгел, башын борырга да курка кебек.

– Монда килгәч, үпкәмне төшерделәр дә, сурәтен үземә күрсәттеләр. Анда бик күп кечкенә-кечкенә караңгы урыннар бар иде. Курыктым, әмма балаларым өчен күбрәк куркам, – ди Наилә, гыж-гыж сулап. – Икәү бит алар минем. Олысына 2 яшь тә юк. Ә монысын күрмәдем дә әле. Педиатр фотосын гына җибәрде. Бик тә күкрәгемә куеп имезәсем килә. Бала табуымны болай итеп күз алдыма китермәгән идем. Күкрәк тулы сөт, ә балага имезергә яраксыз. Бик авыр, әмма баламның, үземнең исән калуыбызга сөенеп бетә алмыйм. Монда эләккәч, терелә инде. Табибларга рәхмәт...

– Менә шундый инде безнең әниләр, – ди Светлана Владимировна. – Үзләре өчен түгел, балалары өчен куркалар. Коронавирус үзеңне саклау инстинктын бетерә. Шулай булмаса, авыру бу кадәр тарала алмас иде. Сакланмый бит халык. Ә авырудан соң өзлегүләр күпме: тромблар, сулый алмау, гайморит... Авырлы хатыннар өчен ковид аеруча куркыныч. Балага кислород җитмәскә мөмкин. Шуңа карындагы баланың йөрәк тибешен әледән-әле тикшереп торабыз. Әнисенең хәле ничек буласын ул безгә алдан ук сиздерә. Коронавирус инфекциясе бик җитез ул, тиз арада карар кабул итмәсәң, соңга калырга да мөмкинсең. Шуңа тәүлек әйләнәсе эшлибез.

– Авыр очраклар да булгандыр. Иң элек кемнең гомере өчен көрәшәсез?

– Ике гомер өчен дә. Ана сәламәтлеге өчен – баланы, бала сәламәтлеге өчен ананы корбан итәбез дигән төшенчәләр юк Россиядә һәм булырга да тиеш түгел. Ана белән бала – тигез бизмән тәлинкәләрендә. Бик авыр хәлдә бер авырлы хатынны китерделәр. Баланы ярып алырга туры килде. 600 граммлы бала реанимациядә ята хәзер. Аның гомере өчен барыбыз да көрәшә. Бик озак көткән беренче баласы. ЭКО юлы белән авырга узган булган. Ничек инде шул гомер өчен тырышмыйсың?! Ул терелеп өенә кайтып китте. Баласын күрергә килеп йөри. Андагы өмет тулы күзләрне күрсәгез сез... Берничек тә кул кушырып утырып булмый. Табиб этикасы, табиб йөрәге моңа һич юл куймый.

Коронавирус инфекциясе сәламәтлек саклау системасын үтә мобиль эшләргә өйрәтеп бетерде. Авырулар күбәя башлый икән, өстәмә урыннар булдырыла, кими икән, җыеп алалар. Өске каттагы урыннарының кирәге калмагач, япканнар. «Инде кабат әзерләргә кирәк булмасын», – ди шәфкать туташлары. Реанимациядән соң авыруларны башка корпустагы изоляторга күчерәләр.

«Без кызларны бала караган кебек карыйбыз. Алар сабыйлар кебек: еларга гына торалар. Шуңа күрә төрле психологик алымнар да кулланабыз. Бүлектә дәфтәр-карандашлар өләшеп чыктык. Авыру нәрсә тели, шуны яза

анда. Борчылуларын да, догалар да, анализ нәтиҗәләрен дә, рәхмәтләрен дә, дәгъваларын да. Барысын да укып, күзәтеп барабыз. Бер кыз шигырь язды да, шигырь язды. Алар шулай итеп эмоцияләрен чыгара. Бу да үзенә күрә терапия», – ди табиб.

#бытьдобру

Чит кеше комачауламый калмый. Моны искә алып, «кызыл зона»дан чыгарга ашыгабыз. Томалап куелган битлек аша сулыш алырга да кыен, ә «кызыл зона»дагылар ничәшәр сәгать шулай киенеп эшләп йөри! Әле ярый эссе җәйләр үтте...

Киенгәндәге кебек, чишенүнең дә тәртибе бар икән. Светлана Владимировна өйрәтеп тора, без әкрен генә чишенәбез. Күзгә, борынга бор кислотасы тамызалар, тамакны 70 градуслы спирт белән чайкаталар. «Спирт артыннан су капмасагыз, яхшырак», – ди Наташа. Авызның әчетүенә йөз сытыла. «Түзегез, түз, безнең табиблар көнгә әллә ничә тапкыр тамак чайкый», – ди ул.

Чишенеп бетүгә, тузган чәчләрне бармаклар белән тарый-тарый, Светлана Владимировна янына ашыгам. Аның да чәчләре тузгыган. «Менә шундый «матур» причёска белән йөрибез инде без», – дип көлә. Һәрвакыт көр күңелле табиб ул. Шулай булмаса, инстаграмындагы һәр постын #бытьдобру сүзләре белән тәмамламас иде.

– Бу сезнең шигарьме? – дип сорыйм.

– Укытучым Наталья Голованованың әтисе гел шулай дип тост күтәрә иде. Үземнең шигарем итеп алдым. Башкача яшәп тә булый. Әгәр яхшылык җиңәсенә өметләнмәсәк, моннан күптән куркып качкан булыр идек. (Светлана Владимировна әледән-әле тамак кыра. Респиратордан тамагы шулай утыра икән. Җитмәсә, спирт белән тамак чайкарга кирәк. Бу бит көн саен кабатланучы халәт!) Әбашта бик авыр иде. Нинди күренмәс дошман ул? Нәрсә ярата? Нәрсәдән курка? Берни белми идек. Әмма беркем дә «кызыл зона»га бармыйм», «теләмим», «арыдым» димәде. Табибларда патриотик хис тагын да артты кебек. Хәзер инде ковид турында хәбәрдар без. Ул инфекцияле авырулар законына буйсынмый. Уенын-чынын әйтсәк, мин аны мистик җан итеп күз алдыма китерәм. Кемгәдер: «Син нык, синең белән эш чыкмый», – дип чыгып китә, ә кемгәдер кереп утыра да һич кенә чыгарып булмый. Миңа калса, ул ир затыннан. Күрдегез инде, безнең бүлектә гел чибәр кызлар. Әле ул тазарак хатыннарны үз итә... Бу инде, әлбәттә, шаяртып сөйләшү. Вирус нинди булса да, аны җиңәргә өйрәндек. Республика җитәкчелеге, клиниканың баш табибы Рафаэль Шәвәлиев безнең бүлек өчен күп эшлиләр. Дәвалауда кыйммәтле препаратлар кулланабыз, алар җитәрлек күләмдә. Табиблар, шәфкать туташлары – үз эшенең осталары. «Без – спецназ», – дим, чөнки тәүлекнең теләсә кайсы вакытында көрәшкә ташланырга әзербез. Бервакытта да табибларның күзләренә игътибар итми идем. Хәзер барыбыз да битлекләрдән йөргәч, күзләр генә күренеп тора. Табибларыбызның күзләре куркусыз, шәфкатьле, кайгыртучан икәнен аңладым. Шундый күзләр генә зур йөрәккә иядер, үз-үзен аямый эшлидер. Һәр авырлы хатын турында белеп торабыз. Мессенджерда эш буенча бик күп чатлар. Тиз генә чара күрер өчен бик уңайлы. Әлбәттә, авыр очраклар да була. Әмма монда вакытында килгән авырулар терелеп чыгып китә. Быел безнең бүлектә 2 мең хатын дәваланды. Җитлегеп туган бер сабый да үлмәде. Менә шундый шатлыклы мизгелләрне уйлыйбыз да, тагын да канатланып эшләргә тотынабыз...

Ковид белән авырган анадан сау-сәламәт бала туа. Үзе үк могҗиза түгелме инде?! Республикада яңа туган бер сабыйга да бу диагноз куелмый. Алар әниләренең терелүен генә көтеп яталар. Ананың карыны никадәр көчле орган, ананың теләкләре никадәр зур кодрәткә ия!.. Светлана Владимировна хаклы: балалар тудыру йорты хастаханә түгел, ул – өмет, шатлык йорты. Анда могҗизага да ышаналар. Хәзер бигрәк тә. Быел балалар туу кимемәгән. Дөньяда нинди генә хәлләр булмасын, сабыйлар тууы дәвам итә... Табиб белән сөйләшеп бетергәч, тизрәк урамга ашыгам. Инде «кызыл зона»да ук урамга чыгып, күкрәк тутырып һава сулыйсы килгән иде. Рәхәтләнеп сулыш алу зур бәхет икән бит ул!

...Яңа яуган ап-ак кардан йөгерә-атлый барган җирдән туктап калдым. Янымнан бер кочак чәчәк, шарлар күтәргән кешеләр үтеп китте. Татарча сөйләшәләр.

– Кодагый, Гүзәл дип кенә кушсалар инде. Бик матур исем бит, әйтергә дә җайлы.

– Әни!.. Без исем уйладык инде!

Ирексездән елмаеп куйдым. Әйе, тормыш дәвам итә...



Нигина НИГЪМӘТУЛЛИНА, Республика клиник хастаханәсенең акушерлык-гинекология ярдәме буенча баш табиб урынбасары, Перинаталь үзәгенең җитәкчесе

– Без – ике гомер өчен көрәшүчеләр! Шунысы сөенечле, хәзерге вакытта ковид белән авыручы авырлы хатыннар саны кими төште. Республика буенча профилактик чаралар оештыру белән бәйледер бу. Авырлы хатыннар организмында коронавирус инфекциясе бик тиз тарала. Кан куера башлый. Ә бу карындагы бала өчен бик куркыныч. Хатын-кыз авырый башлаганда, үзен начар хис итмәсә дә, үпкәсенең зарарланган өлеше зур булырга мөмкин. Нәтиҗәдә, сулыш алу кыенлаша. Авыруны аппаратка тоташтырырга туры килә. Карындагы баланың хәле авырлаша башласа, аны ярып алабыз. Авыру никадәр иртәрәк мөрәҗәгать итсә, заманча препаратларны кулланып, коронавирусны шулкадәр тизрәк җиңү мөмкинлеге бар. Препаратлар авыру башланганда гына нәтиҗәле. Соңыннан башка терапия үткәрергә кирәк. Тын юлы авырулары, артык авырлыгы, югары кан басымы булганнар ковидны авыррак кичерә. Шулай ук ЭКО алымы белән авырга узганнар өчен коронавирус инфекциясе үтә куркыныч. Моның нигә шулай икәнен әлегә аңлата алмыйбыз. Шуңа күрә дә әни булырга җыенучыларга киңәшебез: якыннарыгыз профилактика узсын, хәзер прививканы көмәнле хатыннарга да ясыйлар. Зинһар өчен, җәмәгать урыннарында, сәүдә үзәкләрендә йөрмәгез, зур компанияләрдән читтәрәк торыгыз. Үзегез һәм туачак балагыз турында уйлагыз!



ҖАНДАГЫ ТАШЛАР

Гөлнур САФИУЛЛИНА



Без күп вакыт аларның барлыгын белмибез дә. Инде күптән онытылган, хәтернең әллә кайсы катламнары астына төшеп яткан, күңелнең иң ерак почмагына яшерелгән кебек бит. Әйе, белмибез, әмма авырлыгын тоябыз. Алар беркая да китми, ачуташларга әйләнә дә, гомер буе синең җанда яши. Сиздермичә әрнетә!.. Үзгәрәм, тормышымны яхшыртам дисәң, шушы авыр йөктән котылу кирәк. Ә моңа гафу итү, ярату, ышаныч аша гына ирешеп була. Шәхси үсеш тренеры, коуч – сиңа шушы юлда ярдәмче ул. «Бу эш – иҗат кебек. Чөнки син бит кешенең күңеленә сукмак саласың», – ди әңгәмәдәшем Резеда СӘМИГУЛЛИНА. Ә калганы... Калганы барысы да үзеңнән тора. Җандагы авыр ташларны кузгату, алып ташлау, ул буш урынны мәхәббәт белән тутыру. Иң авыр юл – үз-үзеңә кайту юлы, иң авыр эш – үз-үзеңне табу. Иң җиңеле – барысын да язмышка сылтау...

Резеда, берәү дә бер көндә генә коуч та, шәхси үсеш тренеры да булмыйдыр. Ә сез моңа ничек килдегез?

– Бик озак килдем... Кечкенәдән үк үземнең кешеләргә файда китерә торган белгечлек буенча эшләячәгемне белә идем. Ул чактагы көндәлекләремдә: «Җәмгыяткә файдалы булсам иде» дигән сүзләр еш очрый. Бүгенге яшьләр өчен мәзәк тоелыр инде... Мәктәптә укыганда ук философия, психология белән кызыксындым. Ул чакта бу темага китаплар да юк бит әле. Каяндыр кулыма Виктор Пекелисның «Твои возможности, человек!» дигән китабы килеп эләкте – мин аны ятлап бетердем. Ничек хәтерне яхшыртырга, ихтыяр көчеңне арттырырга, холкыңны үзгәртергә... Үземне гел үстерергә тырыштым.

Без әле дөньяда коуч дигән һөнәр барын белми дә идек, мин язучы, журналист булырга хыялландым. 11 нче класста укыганда татар теленнән олимпиадада район буенча беренче урынны алдым. Линейкада мине котладылар. Ә ике көннән икенче урынга калуым турында әйттеләр...

Минем өчен фаҗига булды бу, мине сындырды. Аны анализлаудан әлегәчә туктаганым юк... Кечкенә чакта алган травмаларның үскәч тә тормышыбызга ничек тәэсир иткәнен шуңа да үземнән беләм... Инде язганнарым республика матбугатында басылып чыга башласа да, әлеге хәлдән соң иҗат минеке түгел икән дип, хыялымнан баш тарттым. Әниләр: «Авыл хуҗалыгы институтына керәсең», – дигәч тә әллә ни карышып тормадым: үз-үземә һәм дөньяга ышанычым кимегән иде. Икътисад бүлеген тәмамладым. Дөрес, студент елларында кабат талпынып алдым: телевидениедә, Илфат Фәйзрахманов кул астында эшләдем. Ул: "Читтән торып укуга күч, безгә эшкә кил», – дип чакырды. Әниләр исә: «Башта диплом ал, аннары теләсә нишләрсең», – диде. Дипломлы булганда, телевидениедә зур үзгәрешләр булып ята, анда яңа кешеләргә ихтыяҗ юк чак иде.

Үткәннәрне киредән «язып» була,
ә бүгенге ситуацияне үзгәртү өчен ниндидер адымнар ясарга кирәк.

Бухгалтер булып эшкә урнаштым. Бер-бер артлы хезмәт урыннары алыштырдым. Иң озагы «Сбербанк»та эшләдем – җиде ел. Ипотекага кредит бирү бүлеге булганга гына анда озак тоткарландым шикелле – кешеләргә торaклы булырга ярдәм итәм дип саный идем. Чираттагы эштән киткән саен: «Хәзер китап язарга утырам», – дип уйлыйм. Ә аннан тагын яңа эшкә барып керәм... Акча да, икебезгә ике машина, фатир да бар. Дөнья түгәрәк кебек, ә күңелдә канәгатьсезлек хисе үскәннән-үсә... Бу эшкә барасы килмәү генә түгел, ә шушы юнәлештә үсәсе килмәү. Кулыннан эш килмәгән икән моның дигән фикер калмасын. Институтны тәмамлагач, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә эшләдем: ике елдан мине бүлек начальнигы итеп куйдылар, министрлыкка эшкә чакырдылар... Банкта офис җитәкләдем, урынбасар урыны тәкъдим иттеләр... Бу юнәлешләрдә үсү мөмкинлегем бар иде, әмма күңелем тартмады – берсе дә минем юлым түгел икәнен сизә идем.

2013 елда банктан бөтенләйгә киттем һәм... башланды! Бер атнадан балага узганымны белдем. Югыйсә икенче баланы алып кайтырга күптән телим, декретка чыгармын да, кире банкка кайтмам дип уйлый идем. Мин кечкенә бала белән өйдә утырганда, «Красный Восток»та инженер булып эшләүче ирем кыскартуга эләкте. Ә безнең ипотека бар... Акча җитмәгәч, өйдә тавыш чыга башлады – аерылышуга кадәр барып җиттек... Шундый парадокс бар: тормышыңны үзгәртеп, үз юлыңа кайта башласаң, каршылыклар туа. Үз-үзеңнән ерак китсәң дә, тормыш көрәшкә әйләнә. Кинәт үзгәрергә теләсәң дә, проблемалар тау булып өеләчәк. Дөнья – стабильлекне сакларга көйләнгән. Баш мие дә шулай: безне бик тырышып яңалыктан – стресстан саклый. 2010 елда, беренче тапкыр шәхси үсеш буенча тренингка язылгач, аварияга очраган идем. Моның сәбәбен соңыннан анализлагач кына аңладым...

Гаиләне саклап калдык без. Минем өчен гаилә беренче урында – балалар әти белән үсәргә тиеш иде. Иремә дә рәхмәт – ул да тырышты. Фатирыбызга кеше кертеп, бакча йортына күчендек. Йөк машиналары сатып алып, үз эшебезне ачтык. Тормыш җайлана төште. Бухгалтер, диспетчер вазыйфалары башкарам һәм... тренинг арты тренинг узам. Аларның һәркайсы үземә кирәк булачагын сизә идем. Шушы темага тулы бер китапханә тупладым һәм бөтен белемнәремне бер системага салу өчен китап язарга утырдым. «Үзең теләгән дөньяга сәяхәт» дип атала ул. Тормышта уңышка омтылган һәр татар кешесенең өстәл әсбабы булырга тиеш бу китап.

Аннан, бизнесыбызга яңа сулыш өрәм дип, Аяз Шабутдинов тренингларында катнаштым һәм үземдә лидерлык сыйфатлары барлыгын ачыкладым. Шәхси үсеш өлкәсендәге белемнәремне ничек кулланырга мөмкин икәнен дә, ниһаять, аңладым: инде башкаларны үзем уңышка рухландыра алам икән!

Бүген тренингларга кешене нинди сәбәпләр алып килә?

– Күпләр, әлбәттә, акча эшләү белән проблемалар бар дип килә. Сүз уңаеннан, акчаны бөтен кеше дә табарга сәләтле, тик моңа комачаулаучы установкалар бик күп. Һәм аларның күбесе, әлеге дә баягы, балачактан килә. Әти-әни белән мөнәсәбәтләр дөрес булмаса да, акчага юл ябыла. Бигрәк тә әти белән мөнәсәбәт акчага тәэсир итә. Әниең белән мөнәсәбәтләр исә –

Фото: Анна Арахамия

Бер тренингның тәэсире ярты елга да, ике-өч елга да җитәргә мөмкин – ул кешенең үзеннән тора.

гаиләгә. Шуңа да аларны көйләргә кирәк. Вафат булсалар, гафу сорарга… Диагностика ясый башлангач, акчасызлыкның әллә нинди сәбәпләре ачыла. Клиентлар үзләре дә аптырап кала. «Болар, чынлап та, шулай тәэсир итәме?» – диләр.

Алып килгән сәбәпләр исә күп: бизнестагы торгынлык, гаиләдә ир, кайнана, балалар, әти-әни белән мөнәсәбәтләр, үз-үзеңне, гәүдәңне кабул итмәү, үзеңне яратмау… Бер ханым килде менә. Шул ук акча мәсьәләсе белән. Сөйләшә торгач, ул: «Аякларым кәкре… Гомерем буе кимсендем», – диде. Ә тәнең белән бәйле бер комплекс, гадәттә, тау кадәр комплекс тудыра: ул үзен гел ямьсез санаган, шуның аркасында иреннән аерылган, улы белән мөнәсәбәтләре бозылган… Шундый техника бар: без ике атна буе аның аякларыннан гафу сорадык. Ник Вуйчичны искә төшердем: «Кулы да, аягы да юк, бөтен дөньяга танылды, ә синең аягыңа ни булган?» – дим. Ул кинәт уянып киткәндәй булды: «Чынлап та, аякларыма ни булган?» – ди.

«Товарыма бәяне күтәрә алмыйм», – дип килүчеләр бар. Эшли башлагач, аның үз-үзенә биргән бәясе түбән икәне ачыклана: ул йә балачакта төшкән, йә гаилә коргач. Хатын-кызның үз-үзенә булган бәясен ир-ат бик төшерә: төрле сүзләр әйтеп, уңышларын күрмичә… Әмма бу очракта хатын-кызның үзеннән дә күп тора: ә сез ирнең үзен бәялисезме? «Безнең өчен бик күп эшлисең, арыйсыңдыр… Рәхмәт сиңа!» – дип әйткәнегез бармы? Мин үзем хәзер әйтәм. Эшли бу алым! Икенче көнне булса да, ул да миңа «рәхмәт» ди!

Без аңасты белән эшлибез. Аффирмация, визуализация, манифестация кебек техникалар ярдәмендә аңастыннан үпкә-рәнҗешләр, куркуларны алабыз. Әмма без могҗизачылар түгел. Коуч – моңарчы син үз-үзеңә бирмәгән сорауларны бирүче ул. Гап-гади сораулар, әмма тормыш мәшәкатьләренә күмелеп син аларны күрмисең. Җавапларын үзең табасың – бу проблемаңны чишү юлын табу да була.

Сез кешенең күңел түрендә яткан иң яшерен серләренә кагыласыз… «Бу хакта беренче тапкыр сөйлим…» – диючеләр күптер…

– Әйе, ул серләргә кайчак һич уйламаганда килеп чыгасың. Хәтта клиент моны үзе дә көтмәгән була. Аңасты гаҗәп: безнең белән булган һәр очракны яхшыга-начарга бүлә һәм саклый. Үзебез моңардан хәбәрдар булмасак та… Бер кыз килде. «Акча белән мөнәсәбәтләремне җайга саласым килә», – ди. Эш таба алмый, бер эштә дә озак тоткарланмый икән. Тренер каршында әйбәт булып утырудан мәгънә юк – ахыргача ачылырга кирәк. Шунсыз алга китеш булмаячак… Сөйләшә торгач, без бу кызның күңелендә үзен гаепле сизү хисе ятканын ачыкладык. Мәктәпкә укыганда, аннары студент чакта ул берничә тапкыр кеше акчасын урлаган булган икән. Зур суммалар түгел, әлбәттә. Әмма: «Мин – гаепле, яхшырак тормышка, зур акчаларга лаек түгелмен», – дигән уй аңастына кереп утырган. «Бу хакта берәү дә белми иде», – диде ул. Техниканы эшләдек: уе белән әлеге кешеләрдән гафу үтенде. Нәтиҗәләр үзен озак көттермәс.

Тагын бер очрак менә. «Якыннарым миңа әйтмичә генә коронавирустан вакцина ясаткан. Кирәкми, дип, күпме үгетләдем аларны. Барыбер саклый алмадым… Инде нидер булса, берсен дә коткара алмаячакмын… Кулымнан эш төште – бизнесым туктады. Елыйм да елыйм», – дип бер хатын килде. Психологка мөрәҗәгать итсә, дөресрәк булыр иде, әмма миңа килгән икән, ярдәм итәргә тырышырга кирәк, дим күңелемнән һәм сорауларымны бирәм. «Ә сез тагын кемне саклый алмаган идегез?» – дим. «Юк, тормышымда мондый ситуация булмады», – ди ул. Ә мин әйләнәм дә тагын теге сорауны кабатлыйм. Яшь чакта аборт ясаткан булган икән… Егете ташлаган, акчасы, торыр урыны булмаган. Әтиәниләренә әйтергә йөрәге җитмәгән… Кияүгә чыккан. Ире дә, гомумән, бер кеше бу хакта белми. Ул гомер буе: «Мин баламны үтердем», – дигән уй белән яшәгән. Кияүгә чыкканына ун ел, әмма һаман да балалары юк икән. «Ирем дә, үзем дә сау-сәламәт, табиблар балага уза алмавымның сәбәбен тапмый», – ди. Техникалар үттек, ул күңеленнән тумый калган баласы белән «сөйләште». «Әни, үпкәләмим, гафу иттем, мин сиңа кире кайтам», – дип әйтте ди. Җиңеләйдем, күңелемдә ышаныч туды, дип китте. Берәр зур яңалык булса, хәбәр итәрсез дип озаттым. Аңа әле кырык та тулмаган – бала алып кайта алыр яшьтә.

Безнең бөтен проблемаларның башы балачакка барып тоташа дип инде берничә тапкыр кабатладыгыз…

– Әйе, дөрес! Юкка гына: «Һәр кешенең эчендә бала яши», – димиләр. Нинди генә проблемага кагылсаң да, аның тамырлары балачагыбызга китә. Бер ханым килде менә. Эшмәкәр, соңгы вакыт эшем гел кирегә китте, ди. «Юньләп ашаганым да юк – гел диетада, әмма тазарам да тазарам», – ди. Бер-бер артлы сораулар бирәм – балачакка барып җиттек. Ул шунда ук елый башлады. Балачагына «кайтса», гомумән, күпләр елый, хәтта анда психик травмалар булмаса да… Клиентым үги әти белән үскән икән, ә ул аны гел кыйнаган. Әнисе исә, моны белеп, күреп торса да, кызын якламаган. Ханым бу травманы күңеленә бикләп куйган да, шушы авыр йөк белән яшәгән дә яшәгән: аңастында булса да, аның

тормышны җимерә торган көчкә ия икәнлеген белмәгән... Үги әти инде юк, әнисе дә инде картайган – ул аны үзе янына алып килгән. «Бер түбә астында яшибез, тик аның белән аралаша алмыйм», – ди. Күңелендәге үпкәсе үги әтигә түгел, нәкъ менә әнисенә аның. Эшли башладык. Үткәндә калган әлеге ситуацияне күз алдына китереп, үпкәләгән кешеңнән гафу үтенсәң, җиңеләясең. «Әни – ул сиңа җан биргән кеше, аны гафу итәргә кирәк», – дим. Ул башта үзен – кечкенә кызчыкны «кочып» елады, аннары әнисен... Юк, шунда ук килеп чыкмады бу, әлбәттә. «Моны уемда да эшли алмыйм, әни коры кеше, ул мине кочакламаячак», – ди. «Үпкә белән түгел, күңелдә ярату, мәхәббәт, рәхмәт хисе булган килеш кочакла», – дим. Ә аннан беркөнне әнисе поликлиникадан кайткач, ул аны ишек төбендә чынлап торып кочаклап алган. Әнисе дә аны кочып елаган... Ул да гомер буе үзен гаепле санаган, әмма кичер дип әйтә алмаган, күрәсең. «Җилкәмдә авыр дага – әнигә үпкәмне асып йөргәнмен һәм хәзер шуны алып аткан кебек тойдым. Ул авырлыкны күтәрү өчен миңа зур гәүдә кирәк булган – шуңа тазарганмындыр», – диде ул. «Инде ул дага урынына канатлар үскән дип күз алдына китерегез», – дим. Ул тагын елый башлады. Тик инде болары шатлык яшьләре иде. Шундый берничә сессиядән соң ул ябыга башлады, кереме дә артты.

Коуч-тренер буларак, сез бөтен кешене дә кабул итә аласызмы? Әгәр ул, әйтик, күңелегезгә ятмаса?

– Коуч ялкау булырга, ягъни клиенты турында артык уйлар уйламаска, үзенә килгән берәүне дә гаепләмәскә тиеш, диләр – нинди генә ситуация туса да, аны һәрбер кеше үзе дөрес дип тапканча хәл итә. Ул башкача эшли алмый иде, дип уйларга тиеш коуч... Яшь кенә бер кыз килде менә. Борынгы профессия вәкиле, әйе, фахишә... «Керемемне арттырырга, ярты миллионга җиткерергә телим», – ди. Эшенең нечкәлекләрен сөйли башлады. «Йә миңа порнога кереп китәргә, йә бәяне күтәрү өчен моңа кадәр эшләмәгәннәрне эшләргә кирәк булачак», – ди. Мин аны кабул итә алмадым, гафу үтендем. Кемдер акча өчен андыйлар белән дә эшлидер – һәркемнең үз принциплары. Ә мин дөньяны булдыра алганча яхшырак итәргә телим...

Клиентны борчыган уйлар сезгә дә кагылган чаклар барыбер бардыр ул. Бөтенләй битараф булу мөмкин түгелдер.

– Бар, әлбәттә... Әти кеше белән бәйле үкенечләрне тыныч кына тыңлый алмыйм. Бер кыз килде менә. Аның әтисе ул кечкенә чагында таудан егылып һәлак булган. Аның күз алдында... Кыз әле бик кечкенә булган, әмма күңелендә барыбер үкенү яши. «Ярдәм итә алмадым», – дип елый. Минем дә күземдә яшь... Әтигә «яман шеш» дигән диагноз куйдылар һәм операция ясадылар. Әмма аннан соң «үпкәсе ялкынсынган гына булган» дип җибәрделәр. Ярты елдан соң ул кинәт сулый алмый башлады. Ирем кайтып, аны Казанга алып килде. Ул көнне, әтине хастаханәгә салгач, әни кире Сарманга кайтып китте. Төш вакытында телефоннан шалтыратам – әти алмый. Апа да шалтыратып караган, энем дә. Күңелдә барыбер шик булмады, эштән соң гына янына киттем. Керсәм, палатада урыны буш, телефоны шунда – берөзлексез шалтырый да шалтырый... Беркем алып җавап бирмәгән. Бәлки, авыр хәбәрне җиткерәселәре килмәгәндер, белмим. Төш вакытында ук өзелгән булган икән инде... «Бомж кебек бер ялгызың яттыңмы, әти җаным?!» – дип өстенә капланып елаган идем...

Нәрсә генә булса да, тренингның һәркайсы кеше өчен стресс...

– Әйе, стресс. Шуңа күрә, үзе теләп килсә дә, кеше карыша, биргән күнегүләрне эшләми. Йөз төрле сәбәп таба, вакыт юк, ди. «Тагын ун ел шулай яшәргә вакытың бармы соң?» – дип, кайчак катырак та әйтәсең, шулай селкетеп аласың. Максатны бит үзләре: «А ноктасыннан Б ноктасына барып җитәргә телим», – дип яза. Теләк, белем генә җитми, нидер эшләргә – кайбер адымнар ясарга да кирәк.

Тренингларга башлыча хатын-кызлар йөри, әмма арада эшмәкәр ир-атлар да шактый. Аларны да үсеш кызыксындыра хәзер. Бизнесның нәтиҗәсе синең үзеңнән тора, ничек уйлыйсың – шулай барачак. Барыбер бармый дисең икән – торачак. Моны аңлаучылар күп хәзер.

Тормышта үз урыныңны табу белән генә проблемалар бетми әле. Әмма син инде аларны башкача кабул итәсең. Килеп чыккан ситуацияләрне анализларга өйрәнәсең: нигә болай булды, тормыш миңа нинди дәрес бирергә тели?.. Җавабың дөресме-түгелме икәнен дә үз-үзеңнән сорарга кирәк. Моңа аңастың җавап бирергә тиеш – аның бөтен сорауларга да җавабы бар. Менә ни өчен аңастын, интуицияне үстерергә кирәк. Шул очракта гына кеше язмыш билгеләрен алдан күрә, таный башлый.

Тренингта катнашкан бөтен кешенең дә тормышы үзгәрәме? Бу – аның үзеннән, моңа әзер булу-булмавыннан тора. Беренче шәхси үсеш тренингыннан соң үзем бернинди үзгәреш сизмәгән идем. Әмма ул барыбер миндә эз калдырды – аңастының ниндидер катламнарын ачты. Хәтта алар вакыт белән кире ябылса да, син инде элеккеге халәттә булмыйсың.

Һәркемнең күңелендә ун касәсе бар, алар әти-әнигә, балаларга, оныкларга, яшьтәшләргә, дусларга, үз-үзеңә, хезмәттәшләргә, фикердәшләргә, Аллаһы Тәгаләгә, социумга, Галәмгә карата ярату белән тулы булырга тиеш. Әйтик, ата-аналар белән мөнәсәбәтең тулы түгел икән, ул бушлык булып тора, һәм касәләрнең калган тугызы да тулып бетә алмый. Кеше мәхәббәт белән туып, аны тулыландырып, Җирдән ярату белән китәргә тиеш. Җаныбызның төп ихтыяҗы – мәхәббәт.

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

«АК БАРС, АЛГА!»

Без Гөлфизә апа Камалиева белән аның иң зур байлыгын (җанатарлар аңлар!) – значокларын шулай берәм-берәм карыйбыз. Ул илебездәге бөтен хоккей клубларын үзенең биш бармагы кебек белә! Илдәге генә дә түгел... Гөлфизә апа – «Ак Барс» хоккей клубы җанатарларының иң өлкәне. Аңа – 66 яшь.

60 яшенә кадәр хоккей аны ялгыш та кызыксындырмый. Алай гына түгел, телевизор эченә кереп китәрдәй булып хоккей карап утыручыларга шакката. Ә бервакыт сеңлесенең кызына ул укыган колледждан хоккейга билетлар бирәләр. Әнилекызлы уенны карап кайталар да, кабат... үзләре билет сатып алалар. Тик көне килеп җиткәч, Гөлфизә апаның сеңлесе авырып китә һәм апасына: «Минем урынга син бара алмассыңмы икән?» – ди. Әле 18 яше тулмаган кызны ялгызын җибәреп булмый бит – ризалаша Гөлфизә апа. Икенче тапкыр да очраклы гына эләгә ул хоккейга. Ә өченче тапкырга инде билетны үзе сатып ала! Һәм менә шуннан бирле бер генә матчны да калдырганы юк аның!

«Ак Барс»ларның фан-клубына – җанатарлар арасына эләгүе үзе бер тарих.

– Мин аларга шунда ук игътибар иттем. Гадәттә, җанатарлар аерым секторда басып торалар. Ерактан күренәләр: кигән киемнәре, кулларында шарфлар, флаглар... Алар гел: «Ак Барс!», «Ак Барс» – Казан!», «Ак Барс» – алга!», «Берәү – меңнәр өчен, меңнәр – берәү өчен!» – дип кычкырып, уенчыларны рухландырып торалар. Энергия миндә дә җитәрлек – алар арасында буласым килде. Башта сеңлемнең кызын җибәрдем: «Бар, белеш әле», – дим. «Ак Барс» командасы Магнитогорскига, чираттагы очрашуга җыена икән. Җанатаралар исә алардан беркайчан калмый. Сеңлемнең кызы: «Мин дә барам!» – дип язылып ук килгән. Баланы үзен генә ничек җибәрәсең – миңа да язылырга туры килде... «Апа, юл бик ерак бит. Авыр булмасмы икән сезгә?» – диләр. «Арагызда әби барын сизмәссез дә», – дидем. «Гөлфизә апа, хәлегез ничек? Арымадыгызмы? Берәр нәрсә кирәк түгелме?» – дип сорап кына тордылар. Автобустан кулымнан тотып төшерделәр, кая гына чиратка бассак та, алга уздырдылар... Шуннан соң мине дә фан-секторга керттеләр.

Чиләбе, Уфа, Түбән Кама, Ярославль, Екатеринбург, Түбән Новгород, Череповец, Мәскәү, Санкт-Петербург, Красноярск, Сочи... «Ак Барс» җанатарлары белән Гөлфизә апа булган-күргән шәһәрләрне санап та бетерә алмам. Моңа кадәр Казаннан беркая чыкмаган кеше хәтта Швейцариягә кадәр барып җиткән! Дөнья күргән!

– Беренче матчлар вакытында сеңлем белән кызының сөйләшүләренә колак салам: «Глухов кертте!» – дип куаналар. Абросимов, Захарчук, диләр... «Ничек аларның бөтенесен беләсез? Кайсы номер белән кем уйнаганын кайдан хәтерлисез?» – дим аптырап. «Өйрән», – диделәр. Мин дә өйрәндем... Беренче мәлдә төнлә уянып яза идем: Абросимов – 16 нчы сан, Глухов – 12 нче, Захарчук – 7 нче... Иртән тикшерәм – дөресме, юкмы?

Телевизордан «Ак Барс» клубы катнашкан уеннарны күрсәтә башласалар, операторлар соңгы елларда трибуналардагы меңләгән тамашачы арасыннан гел берәүне эзләп табалар – башындагы калфагына сәйләннәр белән «Ак Барс» дип чигелгән, ак шәл ябынган сөйкемле Гөлфизә апаны! Калфакны махсус чиктергән, ә ак шәлен әбиләр янына ашларга йөргәндә бәйләргә дип, лаеклы ялга чыккач алган булган. Ул чакта планында абонемент сатып алып, «Боз сарае»на йөрү булмаган бит әле... Хоккей карарга килгән тамашачы да таный аны: «Ак Барс»ның абикасы!» – диләр. Шулай, әбисе! Әби кеше оныкларын яраткан кебек, хоккейчыларның барысын бертигез якын күрә әнә – аерып бер исемне дә атамый. «Барысы да үземнең балаларым кебек!» – ди. Алар тормышындагы булган яңалыклардан хәбәрдар: Даниил Журавлев өйләнгән, Тимур Билаловның кызы туган... Егетләрнең кайберләренә Гөлфизә әбиләреннән туган көннәренә өстенә хоккей алкасы куелган бүләк – торт та эләккән.

Гөлфизә апаның ике дәфтәре бар. Берсенә бөтен матчларны язып бара ул. Әйтик, «Авангард» «Салават Юлаев» белән уйнады: шулкадәр уен узды, алканы шулар-шулар кертте... Икенче дәфтәрдә – яраткан «Ак Барс»ы турында гына. Нинди генә мәгълүмат юк анда! Бу сезонда бозда кайсы командалар белән очрашкан, ничә алка керткәннәр, кем керткән, кайсы хоккейчы нинди сан астында уйнаган... «Язып бару – хәтерне яхшырту өчен менә дигән күнегү!» – ди ул үзе.

– Хоккейга гашыйк булганчы алты ел өйдә генә утырдым бит. Тәмам картайдым, авырайдым, чиргә сабыштым... Кан басымы белән җәфаландым. 2013 елда микроинсульт кичердем. Тормышның кызыгын, мәгънәсен югалткан идем... Ә хоккейдан кан басымының нәрсә икәнен онытып кайтам мин. Бернинди диетасыз да ун килограммга ябыктым. Юлга чыксак, автобуста беркайчан йоклаганым юк, әмма арымыйм! Олы кеше күз-колак бит ул: тукталыштан кергәгә санап чыгам – барысы да урындамы? Автобуста тәртипме? Яшьләрне башка клубларның җанатарлары белән очрашканда коткыга бирелмәскә өйрәтәм. Ә андый хәлләр чыгып кына тора. Уфада башта начар уйнадык шулай. Тәнәфес вакытында: «Ак Барс» – чемпион, дигән буласыз, ә үзегез...» – дип килеп бәйләнделәр. «Ярар, бүген сезнең көн... Тик көн тәмамланмаган бит әле!» – дим. Соңгы матчта өч алка керттек! Аларның җанатарлары трибунадан торып чыгып киттеләр. Әйе, җиңелүләр дә була... Андый чакта бик авыр...

«Ак Барс»ның җанатары булу өчен таләпләр берничә. Беренчесе – үз клубың өчен чын-чынлап җан ату. (Алар турында сөйләгәндә Гөлфизә апаның күзләре ничек януын, балкуын күрсәгез!) Икенчесе – үзеңдә клубның атрибутикасын булдыру. (Гөлфизә апада аларның барысы да бар. Бу урында, ул атрибутиканың бик арзан булмавын гына әйтим дә: значокларның гына да һәрберсе 600–800 сум тора әнә.) Өченчесе – клуб тормышы белән яшәү. (Гөлфизә апа өчен «Ак Барс» та, аның фан-клубы да күптән икенче гаилә инде.) Дүртенчесе...

– Хоккейны телевизордан да карап була, диләр. Зурракны да сатып алдым менә. Тик кызык түгел! Тәэсирләр җитми! Оператор нәрсә күрсәткәнне генә түгел, барысын үз күзләрем белән карап утырасым килә! 17 нче сектор, 9 нчы рәт, 2 нче урында. Бу – минем яраткан урыным!

Гөлнур ХӘСӘНШИНА



– Бу – «Динамо», Мәскәү, ә монысы – безнең «Ак Барс», «Авангард», «Торпедо», «Северсталь», «Сочи», «Барыс», «Нефтехимик»... Владивостокның «Адмирал»ы... Тагын «Амур», «Автомобилист». «Салават Юлаев»... Беләсез инде, ул – Уфаныкы... Ә менә болары – Гагарин кубоклары! «Ак Барс» бит аларны өч тапкыр яулады! Беренче тапкыр – 2009 елда. «Локомотив» белән уйнады ул елны. 4:3 исәбе белән без җиңдек! Монысы – 2010 ел. Исәп тагын «Ак Барс» файдасына 4:3 булды! Бу уеннарны мин карамадым. Ә менә 2018 елдагысын үз күзләрем белән күреп утырдым. Сез аның нинди тамаша икәнен белсәгез иде! Андагы эмоцияләр! Мин аны беркайчан онытмаячакмын! Без анда ЦСКА белән уйнадык. 4:1 исәбе белән җиңдек! 42 нче минутта гына бер алка кертә алдылар... Мин хәзер дүртенче кубокны көтәм!

Фото: Анна Арахамия

«КҮҢЕЛДӘ ҮКЕНЕЧЛӘР ЮК...»



Фото: Анна Арахамия

Гөлнур
ХӘСӘНШИНА

– Безнең өчен иң куркынычы – ут! Андый-мондый хәл булып, янгын чыкса, нәрсә буласын күз алдына китерәсездер... Менә бу сыешлыклардагы тонна-тонна нефтькә ут капсамы?! Куркынычсызлык кагыйдәләрен саклау беренче урында торуы шуңа да бик аңлашыла. Әйе, утның булуы да һәм шулай ук булмавы да начар безнең өчен. Кизү торган бер төнемне гомер онытасым юк. 8 гыйнвар иде ул. Ут кичке уннарда ук бетте. Насослар эшләүдән туктады. Дегетне кая җыярга белмим... Ул инде ташып, агып чыга башлады... Установкада берүзем! Башка беркем юк! Бөтен җирдә кар өемнәре, көрт – бата-чума бер баштан икенче башка йөгерәм... Дөресен әйтәм, утырып елыйсым килде ул чакта. Мондый авария белән беренче очрашуым иде бит. Ярый әле кыш иде, дегет агып чыга да, катып, туктап кала. Ә җәй булса, бөтен резервуар кап-кара төскә керер иде, һәм безгә аны бөтен бригадабыз белән юарга туры килер иде... Юк, юк, нефть өлкәсендә эшләп калуына үкенә икән бу дип уйлый күрмәгез тагын. Һич юк! Эшебезнең никадәр катлаулы һәм җаваплы булуы турында гына әйтәсем килгән иде...

Роза – рәссам. Иҗатка тартылу кайдан килгән аңа – үзе дә белми. Әнисе Саимә апа гомер буе бухгалтер булып эшләгән, әтисе Рәсим ага – күп классташларының әтиләре кебек үк, нефтьче. Кызларын да алар нефть лабораторияләренең берсендә эшләүче лаборант итеп күрәләр. Ак халаттан, җылыда, корыда... Ә Роза алты ел буе сәнгать мәктәбендә белем ала, һәм мәктәпне тәмамлагач, биш кыз белән бергә Лениногорскига укырга китеп бара. Рәсем, сызым һәм хезмәт укытучысы дипломы белән кайта ул аннан. Җәлил сәнгать мәктәбендә балаларга белем бирә башлый. Хыялы чынга аша!

Әмма чынбарлык кына хыялдан шактый нык аерыла...

«Цехларның берсенә рәссам кирәк. Бәлки, барып карарсың? Нефтьчеләрдә хезмәт хакы мәктәптәге кебек кенә түгел инде», – ди бер танышы. Җәйге ял вакытында Роза үзен сынап карарга уйлый. «Җәлилнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенә ул беренче тапкыр шулай аяк баса. Язмыштан китә аласыңмыни?!

– 3 нче промыселны Әхәт Хәкимович Мәннанов җитәкләгән чак бу. «Үзеңнең сәләтеңне күрсәтергә мөмкинлек бирәбез – ошасаң, алырбыз», – диде ул... Мине иртән иртүк кырга – ГЗУларның берсе янына илтеп куйдылар. Әле аның нәрсә икәнен дә белмәгән чагым. ГЗУ – нефть скважинасыннан күпме сыеклык һәм газ суыртылганын исәпләү установкасы ул. Скважинаның дебитын да ул билгели... Буяулар да биреп калдырдылар. Бөтен нәрсә стандарт буенча булырга тиеш: буяулар, аларның төсләре, хәрефләрнең зурлыгы... Җиң сызганып эшкә тотындым. Кызу көн иде. Мине кичкә – эш сәгате беткәндә генә кире килеп алдылар. Эшнең төрлесен куштылар: скважиналарның номерларын язарга, стендлар бизәргә, күрсәткеч язулары ясарга...

Идарәдә әле «производство эстетикасы группасы» булган чаклар бу. Анда бары тик махсус белемле профессиональ рәссамнарны гына туплаганнар. Эшләре иҗаттан ерак булган дип әйтү дөреслеккә туры килмәс. Әйе, алар плакатлар да ясаганнар, биеклеге егермешәр метрлы, тонна-тонна сыеклык сыйдырышлы резервуарларны да буяганнар, аларга саннар суккannар, язулар язганнар, юл, борылыш күрсәткечләрен эшләгәннәр... Әмма «Татнефть» нефть җитештерү компаниясенә кергән һәр оешма, беренче көненнән үк, тирә-юньне матурлау юнәлешендә дә һәрвакыт зур эш башкарган. Чишмәләр – шул юнәлешләрнең берсе булып тора. Аларның тирә-юнен матурлауда рәссамнарның хезмәте бәяләп бетергесез. Сүз уңаеннан, «Татнефть» буенча барган ярышта, нефть һәм газ табучы берләшмәләр арасында «Җәлилнефть» карап торган Тырыш чишмәсе яңа гына беренче урынны алган. Бөтен Җәлилгә билгеле бу чишмәгә реконструкция ясалган: халык анда су алырга гына дип йөрми, күңеле белән ял итеп, табигатьтә дә булып китә.

Рәссам буларак, Розага да «Җәлилнефть» карамагындагы чишмәләрне байтак матурларга туры килгән. Аларның цехына ул чакта өч чишмә беркетелгән була.

Улларым һәр эштә таяныч, алар бик мөстәкыйль булып үстеләр.

Кызганыч, Күтәмәле авылы артында, бик матур урында урнашкан Таза чишмә бүген инде юк: авыл таралгач, ул да юкка чыккан. Ә Иске Кәшер белән Анак авыллары арасындагы Кырык чишмә бүген дә челтерәп агып ята. Туган көннәр, туйлар, чыгарылыш кичәләре генә түгел, нефтьчеләр көне дә шунда үтә.

Анак дигәннән. Розаның рәссам булып эшләп йөргән чагы. Эшкә аларны вахта автобусы йөртә. Анак авылы янындагы тукталыштан автобуска көн дә бер егет утыра. Ә беркөнне аларның урыннары янәшә туры килә... Егет Инсаф исемле икән. Роза кебек үк, Җәлилдә үскән. «Ничек моңарчы бер-беребезне күрмәдек, белмәдек икән?» – дип, алар икесе дә гаҗәпләнә. «Әбием Анакта яши, мин аның янында торам», – ди Инсаф. Машинист егет белән танышуның ахыры ел ярымнан туй белән тәмамлана: «Җәлилнефть»тә тагын бер яңа нефтьчеләр гаиләсе барлыкка килә.

– Рәссам өчен иҗат – һәрвакыт беренче урында, – дип сүзен дәвам итә Роза. – Мин ул елларда үземне иҗаттан аерылмадым дип саныйм. Әйтик, цехка киләсең һәм иң элек аның бизәлешенә игътибар итәсең: һәркемнең фоны төрлечә иде ул елларда. Шулай башкаларныкын карыйсың, үзеңнеке белән чагыштырасың, аннан нәрсәнедер үзгәртәсең... «Ничек матур булган!» – дип, кешеләр сөенә... Административ биналарның бөтен бизәлеше синең кулда. Стендлар ясыйсың... Кайсы бригада нинди плакат сорый – шуны эшлисең. Яңа елга, 8 Мартка стена газеталары чыгарасың: кызык – бөтен цех белән бит! Кышлар шулай уза, ә җәен кырдан, басудан кайтып кермисең. Буяу гел кубып, искереп тора – аларны кабат яңарту өчен генә дә күпме вакыт кирәк. Ул да үзенчә дөньяны матурлау бит... Әйе, рәссамнарга эш җитәрлек иде бездә. Сигез елның узганын сизмәдем дә. Тик тормыш бер урында гына тормый бит – рәссамнарның барысын бергә берләштерделәр. Минем исә ияләшкән эш урынымнан, хезмәттәшләрем яныннан китәсем килмәде. Начальнигыбыз оператор булып калырга тәкъдим итте. Ризалаштым... Әмма ул шунда ук: «Укырга кирәк булачак», – диде.

Шулай итеп, 2001 елны Роза кабат студент эскәмиясенә утыра. Читтән торып укуның үз авырлыклары. Кулда бала да бар бит әле – олысы инде туган... «Иремә рәхмәт – баланы карады, – ди ул. – Мин сессиягә киткән чакларда аны әти-әниләргә дә илтмәде – гел икәү булдылар». Самара дәүләт техник университетын тәмамлап, алты елдан соң кулына инженер-технолог дипломы алып чыга.

Ундүрт ел технологик группада эшли. Нефть җитештерү тармагындагы җаваплы вазыйфаларның тагын берсе бу. Скважиналар гел күзәтүдә: алар җир маен суыртамы, әллә юкмы: юк икән, сәбәбе нәрсәдә – ремень өзелгәнме, двигателе ватылганмы... Туктап торамы, әллә фонтан булып ташыймы... Кара алтынны башкаларга караганда күбрәк суыртучы скважиналар – аерым игътибарда. Кайсылары бигрәк көйсез – атлаган саен ватылып тилмертә...

Гел күңелгә тынгылык бирми торган иҗатка тартылу да бар бит әле. Майлы буяулар белән ясалган картиналарны ул елларда күннән ясалганнары алыштыра. Розаның бөтен таныш-белеше үзләренең иске курткаларын, аяк киемнәрен аңа ташый – бераздан рәссам кулында алар йөзем тәлгәшләренә (күн аяк киеменнән йөзем тәлгәшләре матур килеп чыкканын белә идегезме?), роза чәчәкләренә әйләнә. Нинди төслесе кирәк – шунысына. Картиналар бик матур килеп чыга, әмма аны эшләү шулкадәр авыр икәнен күпләр күз алдына да китерми. Чәчәкләр күнне яндырып эшләнә – өйгә сөреме тарала: йә тәрәзәләрне ачарга кирәк, йә подъездга чыгарга. Куллар кара корымга чума... Бу техника белән эшләүдән соңгы вакыт туктаган, хәзер ул чигү белән мавыга – картиналарын сәйлән белән чигә. Аларда да һаман шул ук үзе яраткан төсләр – ак, кара, кызыл... Картина читендәге язу да үзгәрми: «М. Р.» Ягъни – Минаҗева Роза: рәссамнар фамилияләрен үзгәртмиләр.

Дүрт ел элек ул конторадан кабат кырга – установкага кире кайткан. 7 нче нефть промыселында нефть һәм газ табу операторы булып эшли. Нефтьне комплекслы әзерләү һәм кудыру цехы, Роза әйткәнчә, куркыныч производство объекты санала. Мондагы җаваплылык! Эш процессы күптән автоматлаштырылган, әмма аның бер өлешен барыбер кулдан башкарырга туры килә. Әйтик, установкадагы задвижкалар – эшермәләр кышкы суыкта катмасын дип, аларны гел боргалап торырга кирәк. Урамда салкынлык 10 градус тирәсе булса – ике сәгать, 20 градус булса – бер сәгать, ә 30 градус булса 15–30 минут саен! Салкын җил чыкса, хәлләр тагын да катлаулана: бу очракта торбалар катырга 9–10 градус та җитә. Иң авыры, әлбәттә, төнге сменалар. Син – шәһәрдән кырык чакрым читтә. Берүзең! Иртәнгә кадәр установканы кабат-кабат карап әйләнергә тиешсең. Өстә – махсус кием, аякта – кирза итекләр, башта – каска, противогаз... 15–20 метр биеклектәге резервуарларга, клапаннарны карарга дип, баскычтан бер смена эчендә генә дә ничә тапкыр менеп төшә икән алар?! Бер үк вакытта компьютер күрсәткечләрен дә гел күзәтеп торырга кирәк. Технологик параметрларны саклау, технологияне ритмик режимда тоту – аларның төп бурычы. Ниндидер тайпылышлар була икән, бу сыйфатка тәэсир итми калмый. Ә нефтьнең бәясе исә сыйфатка турыдан-туры бәйле.

– Иң авыры – иртәнге сәгатьләр. Йокының иң тәмле чагы бит... Ә син гел аяк өстендә, алай гына да түгел, игътибарыңны бер минутка да читкә юнәлтмәскә тиешсең. Басым аз гына артып китсә дә, биш минут эчендә резервуарларда барысы да үзгәрергә – андагы сыеклык күтәрелергә һәм ташырга мөмкин. Баштанаяк

дегеткә чумган чаклар бар, билгеле. Безнең киемсалымны юарга җыялар анысы, әмма мин бирмәскә тырышам – андагы химикатлар киемне тиз туздыра. Тозлы суның үз хикмәте: аның астында калсаң, кием тиз генә кипми, шакыраеп ката. Тозлы су буяуны да бик нык ашый, шуңа күрә установканы безгә кайчак хәтта кышын да буярга туры килә.

Иң авыры – иртәнге сәгатьләр, дигән идем, иң рәхәте дә – шушы вакыт. Бигрәк тә язын, җәй башында. Бөтен табигать уяна, кошлар сайрый... Тагын бер матур көн вәгъдә итеп кояш күтәрелә...

Розаның сөйләгәннәре матур бер картинага охшап китә, һәм безнең сүз инде ничәнче мәртәбә иҗатка әйләнеп кайта.

– Буяуларга соңгы вакыт тотына алган юк шул... Җыеп куйган килеш, мине көтәләр. Аның өчен вакыт кирәк, аннан бигрәк – илһам килүе кирәк. Ялгызың булуың кирәк – беркем комачауламасын, бүлдермәсен... Кулга кылкаләм алган чакларда исә бөтен нәрсәне онытасың – шул дөньяга кереп китәсең. Рәхәт!

Хәбибуллиннар Җәлилдән җиде генә чакрымдагы Урсалбаш авылында йорт җиткезеп яталар. Розаның әби-бабалары авылы бу. Әтисе белән әнисе дә шунда кайтып төпләнгән. Матурлык яраткан рәссам күңеле шул нигездә үзенә ял таба. Янәшәдә генә тау. Җиләкле тау! Роза анда җиләк җыярга ярата. Чиләк-чиләк!

«Кара май ак майны ашата», – диләр. Әйе, көч түкми, нефть чыкмый.

Үзенә, әнисенә, кайнанасына, әтисенең күзләре начар күргән апасына... Бакчасында чәчәкләр үстерү дә ошый аңа. Җәй буе, аннан көз буе чәчәк атучы цинниялары. Әйе, әйе, кызыл төсләләрен! Ямьле аларның бакчалары. Зур, иркен агач йортта иҗат белән шөгыльләнү өчен дә мөмкинлекләр зуррак булачак.

– Бака кабырчыкларыннан картиналар иҗат итәргә хыялланам. Дөресрәге, мин инде аны башладым да... Тагын бер тотынасы килгән эшем бар: кәгазь көпшәләр ясап, шулардан чайкалып утыра торган кәнәфи үрергә телим. Махсус шундый техника бар... Мин инде барысын да күз алдыма китерәм: аны нинди төсләргә буйыйсымны, ул кәнәфине өйнең кайсы почмагына куясымны...

Иҗатка күбрәк гомеремне багышлый алмавыма үкенәмме? Әгәр алай икән, тормышымны нефть тармагы белән бәйләүгә үкенү дә булыр иде ул. Юк, күңелемдә андый хис юк минем...

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

ТАРИХ

Җәлил... Республикабызның башка нефть шәһәрләре һәм бистәләреннән шактый аерыла ул. Аның тарихы үзгәрәк. Бистә буш җирдә, ялан кырда төзелә башлый, аны проектлаштыручылар әйтмешли – «чиста ак кәгазьдән».

Узган гасырның алтмышынчы еллары бу. Республикада нефть чыгару мәйданнары еллап түгел, айлап киңәя бара: скважиналар көн саен төньяк-көнчыгышка атлауларын дәвам итә. Нефтьчеләр айлар буе өйләренә кайта алмыйча буровойларда яши. Шуңа күрә алар өчен өр-яңа торак пункт – промышленность базасы төзү мәсьәләсе көн кадагына килеп баса. Бу урынның Сарман районында булырга тиешлеген барысы да аңлый, әмма тиз генә уртак фикергә килә алмыйлар. 1960 елның апрелендә Сарман, Әлмәт һәм Азнакай районы җитәкчеләре бистә буласы урында киңәшмәгә җыела. Хәзерге музыка мәктәбе янындагы аланда уза ул. Тирә-юнен урманнар әйләндереп алган бу урын барысына да ошый...

Яңа бистәгә урын шулай сайлана, һәм нефтьчеләр өчен «заманча шәһәр» төзү идеясе тормышка ашырыла башлый. Бараклар төзүдән шунда ук баш тарталар: монда, зур шәһәрләрдәге кебек, бөтен уңайлыклары булган йортлар салырга планлаштыралар. «Вакытлыча файдалану өчен бернәрсә дә корылырга тиеш түгел», – диләр.

Бистәгә исем кушу – үзе бер тарих. Башта: «Гагарин шәһәре булачак икән», – дигән сүз тарала. Аннан Маленков, диләр. Әмма озакламый Маленковка гаеп тагыла – сәяси сәхнәдән үзе белән бергә исеме дә җуела. Инде тирә-юнь авылларда: «Бездән ерак түгел Хрущев шәһәре төзиләр икән», – дип сөйли башлыйлар... Ниһаять, карлы кыр уртасында дүртәр катлы беренче биш-алты йорт төзелеп бетә. 1964 елның 11 гыйнварында фатирларның ишекләрен ачып керәләр, чөнки иртәгәсен кышкы каникулдан соң балалар яңа урында мәктәпкә укырга барырга тиеш...

Әле ут та, газ да, су да тоташтырылмаган. Суны бистәгә цистерналар белән китерәләр, промбаза ашханәсеннән термосларда аш, чәй алып кайталар. Әмма берәү дә зарланмый, һәркайсының кәефе күтәренке була. «Без – беренчеләр! Без – башлап йөрүчеләр!» – ди алар.

Яңа төзелеп ятучы бистәне «Яңа поселок» дип тә, «Нефтьчеләр поселогы» дип тә йөртәләр. 1964 елның 25 мартында исә Татарстан АССР Югары Советы Президиумының Указы нигезендә бистәгә «Җәлил поселогы» дигән исем бирелә. Указда исемнең герой-шагыйрь Муса Җәлил хөрмәтенә бирелүе турында бер сүз дә булмый, әмма халык моның шулай икәнен аңлый һәм аны хуплап каршы ала. Бик озак еллар бистәне кемдер «Муса» дип, кемдер «Муса Җәлил» дип йөртә. Җитмешенче еллардан соң гына Җәлил исеме ныклап урнаша.

Бүгенге Җәлил – шәһәр шау-шуы булмаган, әмма каладагы уңайлыклар белән яшәп ятучы шәһәр тибындагы бистә. Аны төзүгә, үстерүгә, матурлауга күпләрнең өлеше керган, шуңа да барысына да кадерле, якын ул. Монда гомер иткән һәркемнең тормышы күпмедер дәрәҗәдә нефть тармагы белән бәйләнгән.

«РЕТРО ҖЫРЛАРГА ГАШЫЙК БЕЗ»

Моңга гашыйк, татар ретро җырларын кабат популярлаштыруны максат итеп куйган, музыкаль белемле, милли җанлы, затлы җырчы пар – Алинә һәм Азат КӘРИМОВларны тамашачы аеруча үз итә. Алар, сәхнәдә җырлаудан кала, халыкның яраткан тапшыруы «Җырлыйк әле!»нең алып баручылары да. Бик тә җылы, гади, шат күңелле, бер-берсен тулыландырып торган күркәм гаилә белән сөйләшәбез.



Сез миңа бал кортларын хәтерләтәсез: һаман эштә, һаман каядыр ашыгасыз. Хәтта телефоннан сөйләшкәндә дә ашыгып-ашкынып яшәвегез сизелде. Килешәсезме?

Алинә: Дөрес уйлыйсыз, без һәрвакыт каядыр ашыгабыз. (*Көлә.*)

Азат: Тормыш ашыктыра! (*Бик җитди итеп.*) Бүгенге дөнья темпларында башкача яшәү мөмкин түгелдер дә ул: әз генә тукталып торсаң, хәзер тузан баса. Мин үзем ашыгучанрак шул. Гадәтем шундый. Аннан соң хәрәкәттә – бәрәкәт, диләр бит. Мөмкинлек булганда, тамашачыбыз хезмәтебезне югары бәяләгәндә, яшьлек дәрте барда милләтебезгә хезмәт итеп калырга кирәк. Һәрнәрсәнең үз вакыты...

Сез – ретро җырларга өстенлек бирүче җырчы пар. Әти-әниләребез мәҗлесләрдә җырлаган җырлар, ни генә дисәк тә, күңелгә якын шул...

Азат: Бәхетле чорга эләгеп калдык. Без үскәндә халык җырларын радиотелевидениедән күп яңгыраталар иде. Шуларны тыңлап һәм җырлап үстек. Ана сөте белән кергән инде ул. Шуңа күрәдер мелодик мәгънәсе булган җырлар ошый. Ретро җырлар – нәкъ әнә шундый. Бүгенге көндә иҗат ителгән күпчелек җырлар гармонияле түгел. Тирәнлек юк. Чыктым аша күпер, дип сөйләшкән кешеләрне тыңлыйсы килми бит, җыр дөньясында да шулайрак. Профессиональ белемебез ясалып бетмәгән җырларны кабул итәргә ирек бирми. Консерваториядә белем алуыбыз иҗатыбызга тәэсир итми калмый, билгеле. Югары сәнгатьнең түбән беләбез. Халык җырлары ата-бабаларыбызның безгә биргән вәгазе, тәрбиясе, тарихы.

Иҗат дөньясына кереп китәргә икегезгә дә әби-бабаларыгыз этәргеч биргән дип беләм.

Алинә: Мин Түбән Камада туганмын. Икенче класста укыган чакта әнинең туган ягына – Сарман районы Сарайлы авылына күченеп кайттык. Анда әби-бабай тәрбиясе инде. Безнең буын кешеләре күбесе шулай үскәндер. Кунаклар килгәндә әби мине урындыкка бастырып җырлата иде.

Азат: Бабай минем өчен бабай да, әти дә булды. Бик легендар кеше иде ул. Хәтта Минзәлә театрында да эшләгән. Ике тапкыр Ватан сугышына барып кайткан. Һөнәрле иде ул минем. Үзе скрипка ясап, уйнарга өйрәнгән, оста гармунчы, укытучы, умартачы. Мине кечкенә чакта ук көзге каршына утыртып, гармун уйнарга өйрәтте. Яшьлегендә җырлаган җырларны бик ярата иде. Шулар күңелгә кереп калган. Бабайның таланты әнигә күчкән. Әнием Мөслим районының танылган җырчысы иде. Сәхнәгә мәхәббәт әнинең карынында чакта ук тугандыр, мөгаен. Бергә җырлап йөргәнбез бит.

Сезне халык «Җырлыйк әле!» тапшыруы аша да белә. Яраталар! Бик җылы алып барасыз. Телевидениегә ничек килеп эләктегез?

Азат: Нәҗип абый Бәдретдинов белән электән үк таныш идек. Безнең белән сөйләшеп йөреп, дөньяга карашыбызны, татар җырына мөнәсәбәтебезне тоемлагандыр, күрәсең. Кастингка чакырды. «Алып бару осталыгы үзеннән-үзе килер, уенчылар белмәгән җырларны тере тавышка җырлап күрсәтү мөһим», – диде Нәҗип абый. Инде җиде ел әлеге проектта без. Чын халыкчан ул. Айдар абый Фәйзрахманов алып барган тапшыруны кабул итеп алу горурлык инде. Шуңа күрә бар җаныбыз белән эшлибез.

Алинә, тавышың Хәния Фәрхинекенә охшаган диләрме сиңа?

Инстаграмга берәр җыр куйсам, тавышың охшаган, дип, күп язалар. Мин моны комплимент итеп кабул итәм. Бөтенесе булмаса да, түбән ноталар охшагандыр. Хәния апа да түбән тавышлы иде. Тавышта охшашлык булу зур җаваплылык өсти, билгеле. Татар халкының сандугачы иде Хәния апа.

Көндәлек тормышта икәүләп җырлыйсызмы?

Алинә: Ике тональностьта җырлыйбыз. *(Көлә.)* Гадәттә, җырлый-җырлый ашарга пешерергә яратам. Шул вакытта Азат та миңа килеп кушыла.

Сез – тәүлек әйләнәсендә бергә. Бер-берегездән арымыйсызмы? Әле бит телегездә һаман «матурым» да, «җаным»...

Азат: Исем белән эндәшә башласак, бетте инде. Димәк, кемдер гаепле. *(Көлә.)*

Ә сәхнәдән ничек ял итәсез?

Табигатькә чыгарга яратабыз. Көч бирә ул безгә. Мин Мөслим районында Ык буенда үскән малай бит. Балык тотарга бик яратам. Бу шөгыльне Алинә дә үз итте. Бергәләп, палаткалар алып йөрибез. Балык тоту дөньяларны оныттыра ул.

Азат, син әле аранжировкалар остасы да, үз студияң бар. Киләчәктә үзегезне кем итеп күрәсез?

Азат: Кайчандыр татар эстрадасында яхшы җырлау да яраган булса, хәзерге сәхнә бар яктан да осталык, гыйлемле булуны таләп итә. Һәр инструментның яңгырашын белеп, заман таләпләренә туры китереп, безнең милләткә хас моңны югалтмыйча җырларны эшкәртү өчен аранжировка ясарга өйрәнергә булдым. Җыр гармонияле булсын ул. Шул вакытта гына тамашачы яшәтәчәк аны. Бик ләззәтләнеп өйрәнәм бу эшне. Үзебезнең иҗатыбызны тагын да үстерү өчен тырышам.

Алинә: Консерваториядә классик җырларны бик яратып башкарсам да, операда үземне әлегә күрмим. Белем бервакытта да комачауламый. Әгәр дә опера сәнгатендә күреп алучы булса, миңа ышаныч белдерсәләр, тырышып карыйсым килә, әлбәттә. Шулай да күңелемә милли, бормалы җырлар бик якын. Безнеке инде алар!



Текст: Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА.
Фото: Анна АРАХАМИЯ. Видео: Фәнис САДЫЙКОВ.
Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.


Фото: шәхси архивтан

Вәсилә
РӘХИМОВА

Аларга безгә караганда күпкә көчлерәк булырга туры килә. Язмыш җиле чит илләргә, чит халык арасына алып киткән татар кызларына… Якын кешеләре еракта, бөтен ышаныч – үз-үзләрендә һәм гаиләләрендә. Шуның өчен дә алар бер-берсен эзләп табалар, бергә булырга тырышалар. Алай гына да түгел, үзләренә зур максатлар куялар. Германиянең Франкфурт-на-Майне каласында татар хатын-кызларының «Ханым» халыкара берлеге оешуын ишетеп беләбез: хәбәрләр килеп тора. Әңгәмәдәшебез – шушы оешманың җитәкчесе, Европада татар халкын танытуга алынган Гөлнур ханым ДАУТОВА.

ТАТАРНЫ ЕВРОПАДА ТАНЫТАСЫМ КИЛӘ

Чит җирдә, чит-ят арасында башта үз урыныңны табу, аннан милләттәшләреңне барлау, табу, берлек итеп оештыру, ай-һай, җиңел булмагандыр, Гөлнур ханым...

– Бүгенге интеграция шартлары барыбызны да бөтереп кенә алды. Халык бер урында гына яшәми – миграция беребезне дә әйләнеп узмады. Мин дә шуның бер мисалы... Яшәү урыным итеп Германияне сайлавыма да инде 20 елдан артты. Германиядә, гомумән, Европада татарларның күплеген ишетеп белә идем. Аларны бер төркемгә туплау, үзебезнең барлыкны башкаларга да белгертү теләге күңелемдә күптәннән бөреләнде. Татарларны зур милләт буларак тирә-юнемдәгеләргә танытасы килү, башкалар арасында югалып калмаган, үзенең лаеклы урыны, тарихы булган халык итеп күрсәтү теләге көчле иде.

Күчеп килүчеләргә яңа урынга, бу илнең тәртипләренә ияләшү, урнашып китү, нәрсә генә дисәң дә, шома гына бармый. Бигрәк тә ирләр авыр кичерә. Ә хатын-кыз ничек итсә итә, әмма түзә, чыдый, җайлаша – кайда да активлыгы белән аерылып тора. Шулай да психологик яктан дисеңме, юридик, социаль яктанмы – сорау арты сорау чыгып кына тора. Барысы да таныш – башымнан узды... Шуңа күрә инде ныклап урнаштым, бу мәсьәләләрнең барысын җиңдем, яшәргә, укырга, эшләргә дип килүче милләттәшләремә хәзер үзем файдалы була алам бит дигән ният белән керештем әлеге эшкә. Авыр чакларында чыгу юлларын нигә күрсәтмәскә, нигә дөрес киңәш бирмәскә?

Бер-беребезне барлаудан, танышудан башладык эшне. Үзбәкстанда яки Казакъстанда, Удмуртиядә туып-үссә дә, татарлыкларын танып килүчеләр җыелды. «Ханым» берлегенең концепциясен булдырдык – очраша башладык. Үз телебездә иркенләп сөйләшүгә, күңелдәгесен уртаклашуга сусаганбыз. Җырлап-биеп, чәй эчүләргә генә кайтып калмады аралашулар. Күчеп килү, урнашу белән бәйле проблемаларны уртага салып аңлашу, сорауларга җавап табу белән үрелеп барды. Күз алдында сафларыбыз ишәйде: татар гаиләләре бер-берсеннән ишетеп килә башлады. Күңел кушуы буенча очрашкач, һәркайсының әйтер сүзе дә, җиткерер яңалыгы, тәкъдиме дә була.

Сер түгел, Ватанында яшәгәндә рухи-мәдәни мирас, тамырларың хакында әллә ни уйламыйсың. Ә чит җирдә көтмәгәндә татарлыгың уяна: үзең дә сизмәстән милләтең, гореф-гадәтләр, милли киенү, милли ризыклар хакында белгәннәреңне барлыйсың – үзеңне милләт вәкиле итеп тоясың, җаваплылык сизәсең.

«Ханым» берлеге милләтебез хакында бер-берсен кабатламаган, һәркемгә кызык, мәгълүматлы чаралар үткәрүе белән танылды.

– Кыска гына вакыт аралыгында һәр идеяне, һәр проектны азагынача җиткерә алырлык актив формалашты бездә. Һәр чара кемгәдер ошар, күрсәтер, хисап тоту өчен түгел, ә үзебез өчен оештырыла бит.

Нәүрүз дә, татар ашлары бәйрәме дә онытылмаслык булды. «Рәссамнар Әнвәр Назыров һәм Җәмилә Гергенредер күргәзмәсе. Буыннар һәм мәдәниятләр диалогы» дигән чара исә берьюлы берничә теманы күтәрде. Үзбәкстанда туып-үсеп, хәзер Германиядә яшәүче рәссам Җәмилә Әнвәр кызы әтисенең һәм үзенең картиналары белән таныштырды. Очрашуның музыкаль өлешен Казаннан махсус чакырылган кунак – Татарстанның атказанган артисты Марсель Вәгыйзов бизәде. Кичәгә килүчеләр барысы да милли киемнәрдән иде. Катнаш гаиләләрдә үсүче балалар татар музыкасын, гармун моңын тыңлап, биеп кинәнде. Өйдә пешереп алып килгән милли ризыклар тулы табын, елмаюлы йөзләр, татар рәссамнары иҗат иткән картиналар – барысы да татар рухына коендырды. Берлин татар яшьләре берлеге җитәкчесе Тимур Шәйхетдинов татар язмасы тарихы, Татарстанда яшьләр өчен чыгучы матбугат чаралары хакында чыгыш ясады, Илшат Шәрәфетдинов шигырьләр укыды, җырлады.

Кайда гына булсам да, үземне татар кызы дип, Урал якларында үстем дип таныштырам.

2019 елда «Ханым» Лейпцигта ике очрашу оештырды. Лейпциг университеты галимәсе, психология фәннәре докторы, халыкара аспирантлар оешмасы координаторы Асия Матушанская башка мәдәниятләр белән кызыксынучы, шул темага фәнни хезмәтләр язучы галимнәрне, төрле илләрдән җыелган аспирантларны «Татар теле, мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре» дигән кичәгә дәште. Университетта ул көнне татар шигърияте, музыкасы яңгырап торды. Өчпочмак пешерү, татарча бию буенча мастер-классларда катнашучылар күп булды. Ә июнь аенда милләттәшләр беренче тапкыр Лейпцигның үзәк ял паркына Сабантуйга җыелды. Бәйрәмдә Россиянең Германиядәге генераль консулы һәм Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге Дәүләт фольклор ансамбле катнашуы – барысы да горурлык хисләре уятты. Сабантуйны алып баручылар татар-рус-алман телләрендә гореф-гадәтләребез хакында сөйләп торды. Күпләр гаиләләре белән килде. Балалар өчен махсус уен почмагы да әзерләнде.

«Ширн» сәнгать галереясында «Музыка, поэзия һәм татарча «Мулла» фильмы» дигән сәнгать фестивале Германиядә яшәүче татарларны гына түгел, Брюссельдан, Казаннан да кунакларны үзенә җыйды. Музыка мәктәбе укучылары чыгышын, Тукай Хамш башкаруында Сара Садыйкова көйләрен, шигырьләр тыңлап, вакытның узуын сизмәдек тә.

Пандемия шартларында да эшне туктатмадык: аралашу җаен таптык. Сара Садыйкованың кызы Әлфия Айдарская 95 яшь тулу уңаеннан оештырылган флешмоб кысаларында «Беренче мәхәббәт» җырын башкарып, видеокотлау яздырдык. Тагын бер виртуаль проект – Европа илләрендә яшәүче татар балалары Казандагы татар җырчылары белән бергә «Матур булсын» җырын башкарып, видеоязма әзерләдек.

Күбебез катнаш никахларда булсак та, очрашуларга гаиләләребез белән киләбез. Шулай аралар да якыная. Проектларны татарча-русча-алманча алып баруыбыз да

Читтә үзеңне табу, тамырларыңнан аерылмыйча, асылыңны саклап калу җиңелләрдән түгел.



■ Без чараларны ирем белән икәү алып барабыз: ул – алманча, мин – татарча, русча.

■ Гаиләдә барысы да хатын-кызның үзеннән тора – милләтеңне хөрмәт иттерү дә.

моңа булыша. Нинди генә эшкә тотынсак та, ирләребез теләктәшлек күрсәтә.

Узган ел «Ханым» оешмасы татар бизәкләренә, халкыбызның милли нәкышенә багышлап 12 битлек календарь чыгарды. Һәр битенә милли орнаментлар төшкән һәм ай исемнәре иске татар телендә күрсәтелгән бу календарь күпләр өчен яңалык булды. Аны үзебез кебек диаспораларга таратуны, шушы юл аша татарның милли рәсем сәнгате белән таныштыруны максат иттек. Бик күпләрдә кызыксыну уятты ул.

2021 ел календарен «Европадагы татар ханымнары» темасына багышлап, милли киемнәребезне күрсәтүне кирәк таптык. Календарь өчен кызларыбыз милли кием элементлары кергән образлар әзерләде, кайберләре үз куллары белән чиккән, теккән, бизәгән аксессуарлардан фотога төште. Һәммәсе мавыгып алынды бу эшкә. Календарьда һәр ай аерым образга багышланды, һәр биттә татар халык



киеме элементлары турында сөйләнде һәм заманча милли бер музыкаль әсәргә сылтама – QR-код урнаштырылды. Милли киемнәргә мәхәббәт уяту, таныту нияте берочтан ханымнарыбызның сәләтләрен барлады, яңа мөмкинлекләргә юл ачты. Календарь өчен профессиональ фотосессия Германиянең Франкфурт-на-Майне шәһәрендә узды. «Ханым» оешмасы бу көнне – 27 сентябрьне «Татар киеме көне» дип игълан итте: ел саен бу көнне дөньяның төрле илләрендә яшәүче милләттәшләребезне милли кием яки берәр аксессуар киеп билгеләп үтәргә чакырабыз.

Киләчәктә татар милли гореф-гадәтләренә, фольклорга багышлап та календарьлар чыгару теләгебез бар. Зур эш булып күренмәсә дә, нәкъ менә шулар аша тирә-юнебездәгеләргә милли йөзебезне ачабыз. Календарь өчен кирәкле мәгълүматны җыю да кызлар өстендә. Бу да күпме белем, яңалык дигән сүз.

Шушы эшләрнең башында торган тынгысыз Гөлнур ханым Даутованың үзе, гаиләсе белән якыннан танышыр вакыт җитте кебек.

– Тумышым белән Башкортстаннан, авыл кызы. Мин кечкенә чакта ук гаиләбез белән Ишембай шәһәренә күчтек. Укырга керер вакыт җиткәч, русча бер авыз сүз белмәвем ачыкланды: мәктәпкә барганчы бер ел русча өйрәнергә туры килде. Карт әтием белән карт әнием – авыл мәктәбе укытучылары, зыялы, гыйлемле шәхесләр, затлы нәсел башында торучылар. Каникулларымны алар янында үткәрә идем – татар теленә, мәдәниятенә, гореф-гадәтләргә мәхәббәтне алар сеңдергәндер. Карт әтинең бик бай китапханәсе бар иде. Муса Җәлилнең шигырьләр җыентыгын үзем белән шәһәргә алып китүемне, әби-бабай җылысын шул рәвешле үземдә кадерләп саклавымны хәтерлим. Әнием һөнәре буенча табибә, әтием – мал табибы. Әти-әни ягыннан туганнарыбыз да заманына күрә югары белем алып, төрле тармакларда хезмәт куйган белгечләр. Халкыбызның тарихы, гореф-гадәтләре һәрчак кызык иде миңа, әмма үз илеңдә моңа гадәти яшәү рәвеше дип карыйсың – әллә ни игътибар итмисең. Ә менә Германиягә күчеп килгәч, татарлык үзеннән-үзе бәреп чыкты. Үзебезнең бар нәрсә дә якын, газиз икән бит миңа! Һәм елдан-ел күңелдә ул ихтыяҗ көчәйде генә. 2003–2005 елларда татарлар оештырган очрашуларны

калдырмаска тырыштым. Туган телемне кабаттан ныклап өйрәнә башладым.

Шушында кияүгә чыктым. Ирем Магнус Хамш – милләте белән алман. Ике улыбыз бар. Өйдә, әлбәттә, алман телендә аралашабыз. Олы улыбыз Тукай белән татар телен онлайн дәресләр аша өйрәнәбез. Һөнәрем буенча мин финансист, Россиядә дә, биредә килгәч тә шушы юнәлештә белем алдым. Әлегә эшләмим, кече улыбыз Рубин Рамайны үстерәм.

Миңа өйләнгәч, ирем үзенә яңа дөнья – татар дөньясын ачты: ул да тырышып татарча өйрәнә хәзер. Бөтен эшләремдә төп таянычым да, ярдәмчем дә – ул. Иремнең шундый мөнәсәбәтенә мин бик рәхмәтле. Бу очракта күп нәрсә безнең үзебездән – хатын-кыздан да тора: булачак ирең алдында үзеңне ничек тоту, милләтең белән горурлануыңны, дәрәҗәңне саклый белүең мөһим. Шул чакта гына үзара аңлашу, хөрмәт түргә уза.

«Ханым» уздырган чараларны мин – ана телемдә, ул алман телендә алып бара. Проектларның матди ягын да ирем кайгырта. Күп нәрсә үз көчебез белән оештырыла. Кайчагында кызлар да үз өлешләрен кертә. Ирем һөнәре буенча хокук белгече – адвокат: юридик мәсьәләләрне хәл иткәндә, ул бер карусыз безгә булыша, киңәшләрен бирә. «Ханым»ны рәсми рәвештә теркәүне дә кирәк таптык. Диаспора белән эшләгәндә, хакимият белән берлектә булу уңайрак – кайбер оештыру мәсьәләләрендә алар да ярдәм итә.

«Ханым» берлеге – Европаны яшәү урыны дип сайлаган ватандашларыбызга рухи терәк. Психологик яктан ярдәм күрсәтүне дә изге максатыбыз дип саныйбыз.

Ирегезгә генә түгел, сезнең өчен дә бу бит җәмәгать эше. Боларның берсе өчен дә хезмәт хакы түләнми...

– Нәрсәгә кирәк бу сезгә, дип сорарга телисез инде. (*Көлә.*) Кыскача әйткәндә, бу – минем миссиям! Аны бер сүз белән генә аңлатып та бетереп булмыйдыр. Күңел кушуы бу. Рәхәтлек, канәгатьләнү бирә аларны оештыру. Үзем тормышта билгеле бер юл үттем – тәҗрибә тупладым. Нигә әле шуны милләттәшләрем белән уртаклашмаска, кулдан килгәнчә аларга ярдәм итмәскә?! Кемнедер шатландыру, башкаларга кирәкле булу – күңел ихтыяҗым.

Майн елгасы буена урнашкан Франкфурт каласы – үзенчәлекле шәһәр. Халкының 80 проценты – башка илләрдән күчеп килүчеләр. Латин Америкасы, итальян, испан, төрек диаспоралары – иң эреләре. Ел да Европада шушы диаспоралар катнашында мәдәниятләр парады уза: халык урамга милли киемнәрдән чыга, милли музыкаларын яңгырата. «Ханым» берлегебез дә шулар арасында үз сүзен ишеттерергә, дөньяда татар дигән милләт барлыгын танытырга тырыша. Оешуыбызга ике генә ел булса да, алып барган эшләребез белән башкаларда кызыксыну уяттык. Язмышларын чит-ят җирләрдә тапкан милләттәшләремнең бер вәкиле булуымны онытмыйча, киләчәктә дә милләтемне шулай танытырга насыйп итсен. Иң зур теләгем – шул. Бу урында мәгърифәтче, казыя Мөхлисә Бубый сүзләрен искә төшерү урынлы булыр: «Хатын-кызлар татар җанлы булса, милләтебез беркайчан да югалмас!»

«Үз телеңне үзең кадерләмәсәң, аны кем кадерләр? Татар теленең үз даирәсе булырга тиеш! 2021 елның төп рухи проектларын барласак, ул – Туган телләр елы булыр иде.



Ркаил ЗӘЙДУЛЛА, Татарстанның халык язучысы, Республиканың М. Җәлил, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе әгъзасы, Татарстан Язучылар берлеге рәисе

Ел ахырында артка борылып карау – гадәти хәл. Ел ничек үткән? Нинди уңышлар булган, нинди югалтулар? Әлбәттә, ковид зәхмәте ел тәртибенә үз төзәтмәләрен кертте: халык белән аралашу да азайды, зур залларда әдәби-музыкаль кичәләр дә үтми башлады. Хәер, без барыбер күренекле язучыларыбызның юбилейларын туган якларында гына булса да үткәрергә тырыштык. Әлбәттә, Мөслимдә, Баулыда узган шундый кичәләр истә калырлык булды.

Татарстан Республикасы Президенты хозурындагы татар телен саклау һәм үстерү комиссиясенең эшчәнлеге дә ел дәвамында иҗтимагый тормышыбызда, мәдәни яшәешебездә әһәмиятле роль уйнады. Бүгенге катлаулы вазгыятьтә, мәктәпләрдә татар мәгариф системасы кысрыкланган заманда, телебезнең җәмгыятьтәге ролен, дәүләт теле статусын саклау бик кыен. Ләкин күп нәрсә үзебездән дә тора. Комиссиянең төп миссиясе шунда. Һәм аның җитәкчесе Марат Әхмәтов әлеге хакыйкатьне төптән аңлап эш итә. Төрле иҗади ярышлар уздыру, җитәкчеләрнең дәүләт телен белүләренә даими игътибар бирү шул хакыйкатьне истә тотып эшләнә. Мәктәпләрдә дәрестән тыш чараларның татар телендә узуы да бу җәһәттән бик мөһим. Бер төркем язучылар күптән түгел Алабуганың «Адымнар» мәктәбендә булып кайтты. Тел комиссиясе белән Язучылар берлеге иңгә-иң куеп эшли, мәсләгебез бер. Әлбәттә, кимчелекләребез дә бардыр, кайчакта гаярьлек, уртак эшебездә активлык та җитенкерәмидер. Әмма ниятебез изге. Ә ният изге булганда юл да, ел да, гадәттә, бәрәкәтле, игелекле була.



УҢЫШЫМ – ШӘКЕРТЛӘРЕМ



Эльмира ЗАКИРОВА

Яхшылык, гадилек, тыйнаклык, ихласлык үрнәге ул! Төп эшлеклелек сыйфатын да тикмәгә генә итагатьлелек дип билгеләмәгәннәрдер. Дөнья бәясе ипле, җайлы кеше! Аның белән аралашу рәхәт! Студентлары, коллегалары – бөтен университет яратадыр аны! Барлык студентларын исемләп белүче, аларның һәркайсының хәленә керүче, шәкертләре белән горурланып йөрүче (ә алар күп журналистикада!) Васил Заһид улы – кайда да үз кеше. Татар группасы студентлары өчен исә бөтенләй якын – «Васил абый» ул. Шулай булмыйча! Яшь журналистларның «Алтын каләм» республика фестивальләре аша ук таныш бит инде ул аларга! Баянда уйнап җырлата да, фестиваль гимнының көен дә яза, журналистика жанрлары турында кызыклы мастер-класслар да алып бара, төне буе бала-чага белән газеталар да чыгарыша... Җор телле, шаян, беркемгә каты бәрелмәс, һәркемгә күңелен күтәрердәй сүзләрен табар... Әле бит тагын журналистларның төрледән-төрле бәйгеләре, «Бәллүр каләм» конкурслары, фәнни конференцияләр, кызыклы һәм тирән эчтәлекле лекцияләр, милли журналистика өчен җан атып йөрүләр бар. Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбендә милли һәм глобаль медиа чаралары кафедрасы мөдире Васил ГАРИФУЛЛИН – чын мәгънәсендә Татарстан журналистикасы капитаны. Мәктәпне – алтын медальгә, университетны кызыл дипломга тәмамлаган, газета-журналлар, телевидение мәктәбен узган, 36 яшендә докторлык диссертациясен яклаган. Галим, филология фәннәре докторы, профессор Васил Гарифуллинның тормышы да, уй-хыяллары да үзе кебек якты, мәгънәле.



ТАМЫРЛАР «Татарстан» журналында эшләгәндә, журналист мандатыннан файдаланып, КГБдан бабайның «Дело»сын ала алдым. Бабай – репрессия корбаны булган кеше. Әти ягыннан да, әни ягыннан да шулай... Әни кечкенә чакта, кулак гаиләсе дип, аларны Магнитогорск якларына сөрәләр. Әти-әниләре менә шул шәһәрне төзүдә катнашкан, баракларда яшәгәннәр... Тугыз балалары арасыннан бер әни генә исән калган, бөтенесе дә тифтан, салкын тиюдән үлгән. Әти-әнисе белән кире Татарстанга әйләнеп кайта алган әни. Аларны кулак дип әйтерлек тә булмаган югыйсә. Көнчелек белән – яла ягып сөргәннәр. Ә әти ягыннан Гарифулла бабай, бик яшьли Беренче бөтендөнья сугышына китеп, 1915 елда әсирлеккә эләгә. Бер җир биләүче аны үзенә эшкә ала. Бабай «нимесчә» иген үстерү, терлек карау серләренә төшенә. Әсирлектән кайтып, үз тормышын корып җибәрә. Урта хәлле крестьян була. Ә инде Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк бабайны, «немец шпионы» дип, кулга алалар. «Гаепләре» дә бар икән: тиз генә колхозга кермичә йөргән, «Анда крестьяннар ак күмәч ашый», – дип, әзрәк Германияне дә макташтырып сөйләгән... Югыйсә ике улы да фронтта була: әтием Заһид та, укытучы булган абыйсы Хәниф тә... Ул «Дело»дан сорау алу беркетмәләрен укыдым мин. Башта бабай бөтен гаепләрне кире кагып бара: «Юк, мин Советны һәрвакыт якладым, улларымны да совет властен яклар өчен фронтка озаттым», – ди. Азакка таба инде аны сындырганнар, күрәсең. Үзен гаепле танып, беркетмәләргә кул куйган. Бабамны атып үтергәннәр. Архангел зиратында, үзе кебек репрессия корбаннары белән бергә туганнар каберлегендә җирләнгән ул. Җәмгыять нахакка рәнҗетүен таныды: хәзер биредә аларның исем-фамилияләре язылган зур мемориал такта ачылды... Ике яктан да безнекеләр менә шулай бер гаепсезгә совет власте тарафыннан газапларга дучар ителгәннәр. Әти-әни барыбер коммунистик идеология нигезендә үстерде безне. Әти бик ватанпәрвәр кеше, патриот иде. Иртә үлде. Сугышта алган яралары борчыды, тәнендә снаряд кыйпылчыгын йөртте ул.

Күренекле шәхесләр дә биргән безнең авыл. Атаклы Максудовлар әнә барысы да Кышкар мәдрәсәсендә укыган. Мәхмүт Максуд – язучы, Гаяс Максудов – «Мәгариф» журналының беренче редакторы булган... Ачыклый башлагач, туган да булып чыкты әле ул. Композитор Фәрит абый Хатипов та безнең авылныкы, әти ягыннан без – туганнар.



БАЛАЧАК Әнием Рабига мәктәптә хисапчы да, интернатта тәрбияче дә иде, сугыш инвалиды әтием Заһид мәктәпнең хуҗалык эшләрен алып барды. Абыйларым Илдар, Илфат, Наил дә шушы мәктәптә укыды. Ярыша-ярыша стена газеталары чыгарабыз, үзебез редактор да, рәссам да. Беркөнне мине мәктәп директоры Хәниф Мансурович бүлмәсенә чакыралар. Куркып кына кердем. Бүлмәдә ят, әмма бик таныш йөзле абый утыра. «Менә син чакырган язучы абыең кунакка кайткан», – диде директор абыебыз. Каушап та, аптырап та калдым. Телевизор экраннарыннан балаларга әкиятләр сөйләүче Роберт Батуллинга – хәзер Рабит Батулла – хат язганым исемә төште. Туган авылым, үзебез укыган мәктәп, укытучыларыбыз турында язган идем. Хатның азагында мондый юллар бар: «Роберт абый, безнең авылны күрәсең килсә, кунакка кайт. Без Казаннан ерак түгел. Автовокзалга барып, Теләчегә кадәр 1 сум 18 тиенгә автобус билеты алырга кирәк. Теләчегә кайткач, Арча юлы буйлап унике чакрым җәяү кайтасы була. Машина очраса, утырып кайтасың». 3 нче сыйныф малае сүзенә колак салган бит Роберт абый! Нәкъ шулай эшләгән. Колхозның мал ташый торган машина әрҗәсенә утырып, шунда бөтен киеме саламга батып, безнең авылга кайтып кергән. Мәктәптә язучы абый әкиятләрен укыды, матур итеп тальян гармунында, курайда уйнады, кич белән клубта олылар белән очрашты. Төнге 12 гә кадәр аны көтеп утырганым, төне буе сөйләшеп чыгуыбыз хәтердә. Һәм ул минем язмаларны, шигырьләрне алып китте үзе белән. Батулла абыйның җиңел кулы белән шулар «Яшь ленинчы»да чыга башлады. Шуннан башланды инде... Күп яза идем. Берзаман 8 нче класста укыганда директор чакыра мине. Кабинетында бер абый утыра. «Бу абыең район газетасы редакторы», – ди. Хөснулла Шәфигуллин дип укып беләм инде. «Сине эшкә алып китәргә килгән», димәсенме! «Интернатта яшәрсең. 9–10 ны Сабада укып, редакциядә дә эшләрсең!» – дип, и кызыктыралар мине. Китәм дип йөри башладым! Ә рус теле укытучыбыз Равил абый Галәвиев: «Син нәрсә?! Укырга да укырга әле сиңа», – дип, тиз суытты. Ул мине иҗатка алып кергән кеше. Мин язам, ул укый, редакцияли, машинкада үзе үк бастырып та бирә. Язмаларыбыз белән конкурсларда катнаша идек. «Социалистик Татарстан» газетасында авылыбыз бригадиры турында «Тубал» дигән зур очеркым чыкты.



УКУ Университетта укыганда Сабага – редакциягә практика узарга кайта идем. Әйбәт остазлар туры килде. Җаваплы секретарь Газиз абый Нәбиуллин материалны тәмам «сөреп» чыга. Кызык итеп, көлә-көлә тәнкыйтьләп тә ташлый... «Комбайнчылар җир читенә чыгып әбәт ашарга утырдылар», дип язгансың. Җирнең чите буламыни аның, Җир түгәрәк бит ул!» – ди. Менә шундый шәп мәктәп уздым мин. Үземне гел газета журналисты дип санап йөри идем, укып бетергәч тә телевидениегә китәргә туры килде. Декан Флорид Әгъзамов: «Тәҗрибә туплагач, син барыбер университетка әйләнеп кайтырга тиеш», – диде. Аның принциплары шундый иде: журналистларны укытучы кеше журналистика мәктәбен узган булырга тиеш. Өч елдан соң университетка аспирантурага әйләнеп кайттым. Аспирантурага керер өчен чит телдән имтихан тапшырырга кирәк. Студент чакта гарәп теле өйрәндек, ләкин аспирантурага дәгъва итүчеләргә Европа телен белү кирәк икән. Мәктәптә укыганда ук чит телләрне өйрәнергә теләгем зур иде. Өстәвенә, ГДР балалары белән хатлар алыша идек. Хәтта немецча язарга тырышам хатларны. Китап кибетеннән дәреслекләр, сүзлекләр алып, үзлегемнән өйрәнеп... Һәм аспирантурага керер өчен яңадан немец теле өйрәнә башлагач, кызык хәлләргә дә тап булдым. Телевидениедә эшләгән чак. Әз генә буш ара эләксә, немец телен шомартам. Өстәлемдә – сүзлекләр, немец телендә китаплар... Үзем юкта берсе шул китапларны күреп алган да директорга менеп киткән!

Фото: Анна Арахамия

Пошаманга төшкәннәр инде. Чит илгә качарга җыенамы әллә дип, тәмам шиккә калганнар. «Аспирантурага керәсем килә, чит телдән имтихан тапшырасым бар», – дип аңлатырга туры килде үзләренә. Журналистика буенча аспирантура юк иде университетта. Флорид Әгъзамов мине татар теле кафедрасы мөдире, профессор Диләрә Тумашева янына алып кереп китте. Диләрә Гарифовна: «Фәнни темаң журналистика белән бәйле булсын. Матбугатның телен өйрәник», – диде. Ул вакытта үсеп кенә килә торган өлкә – текст теориясе буенча эшли башладым. Шул юнәлештә кандидатлык диссертациясе якладым. Аны тагын да киңәйтеп, тарих белән дә бәйләп, элеккеге газеталарны, аерым алганда, татар миллионерлары Рәмиевләр чыгарган «Вакыт» газетасын өйрәнеп, докторлык диссертациясенә килдем. Текст теориясе яссылыгында матбугатны өйрәнгән беренче эш булды ул... Бу чорда татар телен интенсив укыту буенча китаплар да чыгардык, рус мәктәпләре өчен татар теле дәреслекләре яза башладык.

Телевидение дә зур мәктәп булды минем өчен. Үзгәртеп кору чоры иде ул. Мәскәүдә «Останкино»да журналистларны әзерли торган курсларда укып кайттым. Моңарчы тапшыруларны диктор гына алып барса, үзгәртеп кору чорында безнең дә тавышлар кадр артында яңгырый башлады. Журналистлар тулаем үзләре алып бара торган программалар да барлыкка килде. Бу инде телевизион журналистикада революция иде. Университетка килгәч тә, бу кызык чор дәвам итте. Милли күтәрелеш еллары бит. Университетта «Ленинец» дигән русча газета чыга, ә татар телендә – юк. Ул вакытта проректор милләтпәрвәр Миркасыйм Госманов иде. Татарча газета чыгарырга фатиханы ул бирде. Шулай итеп, «Ленинчы» газетасын чыгара башладык. Аспирантурада укучы Рифат Фәттахов редактор булды. Ләкин Рифатның энергиясе белән алай гына кала алмый! Ул аны төрле югары уку йортларында укучы студентлар басмасына әйләндерү турында хыялланып йөри башлады. «Мәгърифәт» газетасы әнә шулай туды. Җиде еллап шул газетада да эшләдем, университетта да укыттым. Рифат, «Татарстан» журналына баш редактор итеп билгеләнгәч, барыбызны да шунда алып китте. 2003 елда декан булып сайландым. Эшем тыгыз, фәнне дә алып барырга кирәк. «Егетләр, китим инде», – дип редакциядән киттем. Университетта укыту әнә шулай практика белән үрелеп барды. Студентларны өйрәтер өчен практик журналист булу кирәк иде шул.



УҢЫШ Кафедра утырышларының берсендә: сиңа ял бирәбез, дәресләрдән азат итәбез, ләкин ике елдан соң докторлык диссертациясен өлгертәсең, диделәр. 1995 ел иде. Хезмәт хакым саклана, газетада да эшләп йөрим, дәресләремне кафедрада үзара бүлештеләр. Әгәр диссертацияне язып якламасаң, ни йөзең белән әйләнеп кайтасың монда?! Шулай итеп, 1998 елда докторлыкны якладым. Уңыш дигәннән, докторлыкны яклау үзенә күрә бер трамплин шикелле: ул сине гел өскә таба күтәреп тора икән. Шул ук 1998 елда мине кафедра мөдире итеп сайладылар. Шул чорда без аерым факультет булып оештык. Кафедра мөдирлеге өстенә мине декан итеп тә сайлап куйдылар. Флорид Әхмәтович башта кафедраны, аннан деканлыкны миңа тапшырды шулай. Авырый башлаган иде инде ул... 2018 елда мине кафедра мөдире итеп бишенче срокка сайладылар. Риза булдым. Чөнки милли журналистика мәнфәгатьләре турында уйладым. Кафедра зур, студентлар күп безнең. Татар өлеше исә саны буенча бик аз. Әйтик, быел гына да мин җитәкләгән медиа чаралары кафедрасына 125 ләп студентны бакалавриатка һәм магистратурага кабул иттек. 90 проценттан артыгы рус группаларында укучылар, барысы да түләүле белем ала. Ә булган бюджет урыннарын без тулаем татар журналистлары өчен генә файдаландык. Татарча бакалавриатта укучылар да, магистратурада да – берсе дә кесәсеннән акча чыгарып укымый. Нәтиҗәдә, татар журналистикасы бүлеге федераль бюджет хисабына элеккечә тотрыклы эшләп килә. Кафедра мөдире булгач, шулай милли кадрлар әзерләү юнәлешенә өстенлек бирә алам, шөкер. Бу – минем зур уңышым дип саныйм! Минем төп уңышым да, горурлыгым да – үземдә укып чыккан шәкертләрем! Республика басмаларында, радиода, телевидениедә, район редакцияләрендә, матбугат үзәкләрендә – кайда да бездә укып чыккан студентлар. Флорид Әгъзамовтан башлап, мин дәвам иткән укучыларыбыз! Татарстан журналистикасын әйдәп баручылар алар, безнең горурлыгыбыз. Аларның иҗади конкурсларда, бәйгеләрдә җиңеп баруларына аеруча сөенәм.



МӘХӘББӘТ Тирә-як авыллардан бик күп балалар безнең Югары Кибәхуҗа мәктәбенә йөреп укый иде. Безнең 9 «А» белән параллель «Б» классына күрше Олы Кибәхуҗадан дүрт кыз килеп укый башлады. Сыйныфыбызда егетләр унсигез идек. Шул дүрт кызга унсигезебез дә гашыйк булдык. Сентябрьнең беренче көннәрендә үк 3-4 чакрымдагы күрше авылга алар янына төшәргә булдык. Әле юл буе үзебезчә кызларны бүлешәбез. Сыйныфташым Рифат сөйләп бара: «Мәдинә исемлесе бигрәк сөйкемле! Миңа шул кыз ошый!» – ди. «Мәдинә миңа да ошый ул... Карарбыз әле, кемгә булыр!» – дип куям эчтән генә. Без әле кызлар озатуның ни икәнен дә рәтләп белмибез. Күрше авыл клуб төбендә туңып тору да рәхәт түгел бит. Алай да төшәбез инде шул авылга. Кызларга ияреп, капка төпләренә кадәр кайткан булабыз. Качып кереп китәләр... Тора-бара кара күзләр, яңгырлар китте, малайлар кимегәннән-кими барды. Кыш җитте. Бер мин калдым күрше авылга йөри торган. Мәктәптә укыганда шулай Мәдинә белән дус булып йөрдек, аннары Казанга укырга киттек. Мин – университетка, Мәдинә – пединститутка. Дуслыгыбыз алты елга якын дәвам итте. Әнием, авылдагы өйне сатып, Казанда Брикетный бистәсендә агач өй сатып алган иде. Торыр урыныбыз да булды – апрель аенда өйләнештек. Бер елдан, мин бишенче курста укыганда, хәрби сборга җыенган вакытта, улыбыз Илназ туды. Гаиләмне сагынып, Лаеш урманындагы казармадан көн саен диярлек качып кайта идем... Ә Мәдинә гомере буе Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясендә эшләде, Татарстанның атказанган укытучысы дигән мактаулы исемгә лаек булды. Тормыш корып җибәрүебезгә киләсе апрельдә 40 ел тула, Алла боерса. Шөкер, беренче мәхәббәтебез әнә шулай озын гомерле булды безнең.



ДУСЛАР Дуслар күп минем, Аллага шөкер. Һәрбере ниндидер чор белән бәйле. Мәсәлән, университетның «Каз канаты» бию ансамбленә йөргән чордагы дуслар. Вилсор Камильянов, Заһир Исрафилов... Алар хәзер дә бик якын миңа, инде гомер буе гаиләләр белән аралашабыз. Группадашлар... Миңназыйм Сәфәров белән бергә укыдык, бергә фикерләшеп, ярдәмләшеп гомер кичердек. Назыйм Чуаштаннан бит, беренче курста колхозга бәрәңгегә баргач мине чуашча җырларга өйрәтте. Очрашкан саен шул җырны җырлыйбыз без: «Шанкрав кураке», ягъни «Кыңгырау чәчәге» безнеңчә. Быел институтта минем юбилейга җыелган халыкка шул турыда сөйләдем дә, Назыймга: «Әйдә, җырлыйк әле шуны», – дидем. Чыгып басты уртага, исенә төшерә алмый гына бит – үзе өйрәткән җырны оныткан! «Эс четретени, эс йеретени? Ма салхулла сан йал куллу?..» – дип җырлап җибәргән идем, бөтен халык егылышып көлде инде... Яшь чакларыбызда Рифат Фәттахов белән бергә эшләдек. Дуслыгыбыз бүген дә саклана: Рифат белән даими аралашып, фикерләшеп яшибез. Өлкән абзыйлар... минем өчен остаз гына түгел, дус та алар. Флорид Әгъзамов, Фәрит Йосыпов, Тәлгат Галиуллин, Хатип Миңнегуловлар... Флорид абый студентларына гел хәерхаһлы булды, һәрберсен якын күрде. Үзем дә нәкъ шулай студентлар белән дустанә мөнәсәбәтләр сакларга тырышам. Фәрит абый фольклор экспедициясенә мине баянчы буларак алып бара иде. Себердәге татар авылларында концертлар куйдык. Хатип абый белән дә экспедицияләргә чыккаладым. Дус абзыйларым белән гел шалтыратышып торабыз.



АКЧА «Менә тиздән, коммунизм җиткәч, акчаның бөтенләй кирәге калмаячак. Кибеткә керәсең дә үзеңә кирәк әйберне сайлап аласың», – дип үстерделәр безне. Чынлап та, бу фараз күпмедер дәрәҗәдә тормышка ашты бугай: нәрсәдер алыр өчен реаль акча кирәк тә түгел, виртуаль акча белән эш итәбез күбрәк. Ләкин икенче мәсьәлә: ул виртуаль акчаны эшләп алу елдан-ел авырлаша... «Акча күпме булса да җитми, акчага кызыкмагыз», – дип әйтә иде әти-әни. Әмма инде шул акчаның җитмәгән чаклары күп булды, яшь чакта бигрәк тә. Гаилә корып яши башлаганда икебез дә студентлар идек бит. Ярый әле әти-әниләр булыша иде. Бәрәңгесен, итен җибәреп тордылар. Җитмәүчелек булганын бәрәкәтле итеп тотарга, акчаның кадерен белергә өйрәтте. Ә инде бик күп акчам булса, татар зыялыларының күптәнге хыялын тормышка ашырып, милли университет ачу өчен тотар идем. Бәлки, дәүләт хисабына булмаса да, иганәчеләр исәбенә гамәлгә куелыр ул. Элек безнең татар байлары тоткан зурзур мәдрәсәләр кебек, милли университетны да шәхси иганәчеләр исәбенә ачарга мөмкинлек булыр иде. Югары уку йортларында татар теле укытучысы яисә татар журналисты әзерләү белән генә милләтне үстереп булмый. Милләтнең үсеше өчен кайда да телне белә торган кешеләр эшләргә тиеш. Хокук, икътисад өлкәсендә дә, табигать фәннәре, төгәл фәннәр буенча да... Алар татар мохите булган, татарча укытыла торган югары уку йортларында әзерләнергә тиеш. Татарның зыялы катламы, милләтнең киләчәге милли университетта гына тәрбияләнә ала дип саныйм мин.



МАВЫГУ Мәктәптән үк үзешчән сәнгатьтә катнашып килгән кешеләр без. Шуңа күрә төп мавыгуым ул үзешчән сәнгать булды. Баянда уйнадым, җырлаттым, концертлар куеп йөрдек, университеттагы «Каз канаты» ансамблендә 15 еллап биедем. Өстәвенә, университетның татар хорында баянда да уйный идем әле. Хор җитәкчесе Ирнис Рәхимуллин сәхнәгә чыга иде дә: «Баянда – профессор Васил Гарифуллин!» – дип, шул сүзләрдән үзе үк рәхәтлек алып игълан итә иде. Яшь чакта ансамбль белән йөрмәгән җир калмады! Ул безнең өчен зур мәктәп булды! Студентларга еш әйтәм: «Өстәмә шөгылегез булсын. Вакытны рациональ файдаланырга мөмкинлек бирә ул», – дим. Безнең ансамбльдән бик күп күренекле кешеләр чыкты. Милли сәнгать белән шөгыльләнү милли үзаңны да үстерә бит әле! Биюгә йөрү вакытны дөрес бүләргә дә өйрәтте, формада да тотты. Атнага өч тапкыр өчәр сәгать биеп кара! Репетиция тәмамланганда, киемнәр инде сыгып алырлык була иде. Безнең өчен спорт шул бию иде инде. Анда бит әле башта тәнне кыздырасың, йөгерәсең, сикерәсең... Үзенә күрә гимнастика. Тәмам кызгач кына бию күнекмәләре башлана. Аннары икенче сулыш ачыла! Менә шул вакытта сәхнәгә чыгып биергә дә була!



БАЛАЛАР Илназыбыз студент чагыбызда туган булса, икенче улыбыз Илгиз аспирантурада укыганда туды. Икенчесе кыз булыр дип, исемен дә алдан ук уйлап куйган идем. Гөлназ исемен ошатып йөрим. Туганнар, дуслар кыз алып кайта да Гөлназ дип исем куша. Абыем Илдар да, Мәдинәнең энесе Наил дә, Миңназыйм дустым да... Ә безнең тагын малай туды, Илгиз дип исем куштык. Илназ да, Илгиз дә 2 нче татар гимназиясендә укыганда ук параллель рәвештә музыка мәктәбендә дә белем алдылар. Бу минем тормышка ашмаган хыялым иде. Авылда музыка мәктәбе булмагач, музыкаль белем ала алмадым. Ә минем бик тә музыкант буласым килә иде. Шушы хыялны инде улларым тормышка ашырды. Башта музыка мәктәбендә укыдылар, аннары музыка училищесы, консерватория... Илназ зур сәхнәдә дә уйнады: Салават, Рөстәм Закиров, Вил Усманов төркемнәрендә эшләде. Бүген ул музыка мәктәбендә балалар укыта. Илгиз университетта да укыды. Бүген үз эше белән шөгыльләнә. Өч оныгыбыз бар: Зилә, Зәйнәб, Динә. Без гаиләдә дүрт егет үстек, үземнең дә малайлар гына туды. Бөтенләй икенче икән ул кыз бала! Гаҗәпләнеп тә, сөенеп тә, шулкадәр яратып та аралашам алар белән. Киленебез Гүзәл исемле, Балтачтан, Пыжмара авылы кызы. Заманында беренче курста укыганда группабыз белән бәрәңге алырга барган авыл ул. 40 елдан соң кода булып өйләнеп кайтырга туры килде Пыжмарага.



КУРКУ Югалтулар булмасын. Бу чорда бигрәк тә куркыта. Дуслар, туганнар исән-сау булсын, чирләр алып китә күрмәсен якыннарны, дим. Үзең өчен курыкмыйсың, хәзер балалар өчен куркасың икән ул. Әз генә берәр нәрсә булса, хафага төшәбез, яннарына йөгереп барабыз. Бала кайгылары күрергә язмасын берүк! Бүгенге хәвефләрдән тизрәк арынып, барыбызга да исән-сау булырга язсын!



Тулысынча укыгыз »






ҮЗ ЮЛЫМ БЕЛӘН БАРАМ...

Алсу
ШАКИРОВА

«Тормышта көч бирүче чыганагым – ялгызлыктыр, мөгаен. Миңа күп вакытны ялгызым кырда, урманда, табигатьтә уздырырга кирәк. Мине шул гына тота. Бу – метафора түгел. Тоемлап кына була торган ниндидер бер энергия миңа шундый шартларда гына килә», – ди София Гобәйдулина. Дөньякүләм танылган, дистәләгән исемнәргә, дәрәҗәгә, шул исәптән, «Сөембикә беләзеге»нә лаек ватандашыбыз быел үзенең 90 яшьлек юбилеен билгеләп үтте.

Бөек композитор София Гобәйдулина – солистлар, хорлар, оркестр, инструменталь ансамбльләр өчен йөздән артык әсәр авторы, кино һәм мультфильмнар өчен музыка язучы. РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, 24 тапкыр төрле премияләр лауреаты, ике «Дуслык» ордены, Гете медаленә ия шәхес (бу медаль белән Чарльз Дарвин, Джузеппе Верди, Роберт Кох, Альберт Эйнштейн, Рихард Штраус бүләкләнгән). Аның әсәрләрен Россиянең һәм чит илнең иң танылган башкаручылары яңгырата. «Тыелган» композиторлар исемлегенә кертелгән елларны да язмышның бормалы юлларында югалып калмыйча, үз исемен дөньяга танытырлык көч тапкан шәхес ул. Каян килгән шулкадәр көч, ныклык, уңыш, сәләт?! Тамырлардан, һичшиксез... Тирән җәелгән нык тамырлардан гына иң күркәм агачлар үсеп чыга!

90 еллык гомере дәверендә гениаль музыкант София Әсгать кызы турында бик күп язылды. Әйе, дөньякүләм танылган шәхесне юбилейга бәйләп кенә түгел, даими рәвештә искә алып торырлык вакыйгалары күп булган тормышында: күтәрелү, хәтта тыелу заманнары, чит илгә китеп, яңа яссылыкта популярлыкның биегрәк баскычына менүе, исемен таныту... Ләкин мондый биеклектәге шәхеснең нәсел агачы тамырлары кая барып тоташканы бик аз кешегә мәгълүм. Юкса халкыбыз тарихында тирән эз калдырган династияләр, нәселләр арасында бертуган Рәмиевләр, Хөсәеновлар, Акчуриннар, Апанаевлар белән беррәттән, София ханымның бабалары – Гобәйдуллиннар династиясе дә лаеклы урын алып тора.

«Минем апам һәм аның кызы хәзер безнең нәселне барлау белән шөгыльләнәләр. Мин – мулла оныгы. Бабам мин туганчы вафат булу сәбәпле, аны күрмәдем. Ләкин аның алдынгы карашлы мөселман булганын беләм. Ул хәтта танылган рус дәүләт эшлеклесе Сергей Витте белән дә аралашкан. Үзенең улын – минем әтине мәктәпкә укырга биргән, фән, техника юнәлеше буенча белемле итәргә тырышкан», – дип искә ала София ханым бу хакта.

Бәйрәкә авылы Казан губерниясенең көньяк-көнчыгышында 1580 елларда барлыкка килә. Нәсел башы Ибраһим хәзрәткә барып тоташа. Ул Бәйрәкә авылында мәдрәсә ача, анда хәзрәтнең улы Гобәйдулла укыта башлый. 29 ел дәвамында белем биргәннән соң, Гобәйдулланың эшен улы Габделгали дәвам итә. 60 еллык хезмәт юлында меңләгән укучы-шәкертләргә белем бирә ул. Габделвәли хәзрәт үлгәннән соң, улы Мәсгуд Гобәйдуллин Бәйрәкә авылының имамы һәм мәдрәсәдә мөдәррис итеп билгеләнә. Аңа кадәр Мәсгуд Чистай мәдрәсәсендә белем алып, аннары Бохарада укып кайта.

Бохарада укыган вакытта Мәсгуд хәрби хезмәткә алына. Татар һәм рус телләреннән кала, тагын кайбер шәрык телләре белү сәбәпле, Туркестан генерал-губернаторының тылмач вазыйфасын да башкара. Хәрби хезмәт Мәсгудтән яңача фикер йөртә торган алдынгы карашлы кеше тәрбияли.

Бәйрәкәдә имам итеп билгеләнгәннән соң, Мәсгуд Гобәйдуллин конфессиональ мәдрәсәдән яңа метод белән белем бирүче җәдидче мәдрәсә булдыру буенча үзгәртеп

СОФИЯ ГОБӘЙДУЛИНА ИСТӘЛЕКЛӘРЕННӘН

■ «Минем әтием – татар, әнием – рус кызы. Араларын бернәрсә белән дә аерып булмаслык нык пар иде алар. Бу – гомерлек мәхәббәт үрнәге».

■ «Казанда яшәгән елларның иң истәлекле вакыйгалары хакында сорыйсыз. Ачлык. Мин ачлыкны яхшы хәтерлим. 1939 елдан кала... Ул елны алмалар бик күп булды. Һәм сөт... Бернинди авырлыкларга карамастан, без сеңлем белән музыка мәктәбендә укуны дәвам иттек. Рухи тормыш көндәлек мәшәкатьләрдән өстенрәк иде. Мин тулысынча үземне музыка сәнгатен өйрәнүгә юнәлттем...»

■ «Казанда яшәгәндә китапханәгә йөрергә ярата идем. Әле дә хәтерлим: ул Чернышевский урамында урнашкан иде. Анда китапларны көне буе укып утырырга рөхсәт итәләр иде. Тагын Кремльдә урнашкан Сөембикә манарасы күңелемә бик якын. Кремль диварларының өстеннән йөрергә була иде минем балачакта».

■ «Бәләкәй чактан биергә яраттым. Әнә шул биюгә карата мәхәббәт мине музыкага алып килде дә инде. Без яшәгән Тельман урамы ишегалдында шизофрения белән авыручы малай да яши иде. Ул искиткеч итеп гармунда уйный! Шунда, ишегалдында, концерт оештырабыз: шул малай гармунда уйный, мин биим. Мине музыка укытучысы күреп алган. Аның чакыруы буенча, апа белән мине музыка мәктәбенә алып килделәр». Софиянең апасы Ида ул көнне болай искә ала: «Тыңлатып карар өчен безне музыка мәктәбе директорына алып керделәр. Мине ул ошатты. Ә Софияне алырга теләмәде, үссен бераз, диде. София, директорның чалбарына ябышып, аны да алуларын үтенде... Аннары әти безгә «Слесарь» роялен алып бирде. Бу – безнең өчен искиткеч вакыйга булды».

■ «Мин яшәгән йортка реставрация ясаучылар табылганга бик куандым. Мин анда үземне, дөньяны, күкне беренче тапкыр ишеттем. Шул тыйнак кына йортта үз талантларын, музыкальлекләрен күрсәтергә җыелган кешеләр өчен сөенәм. Минем йорттан Заманча музыка үзәге ясаган кешеләргә чиксез рәхмәтлемен».

■ «2001 ел башында мине күрергә дип, Казанның ул вакыттагы мэры Камил Исхаков Германиягә килде. Аның күңелендә Казанга карата никадәр чиксез мәхәббәт барын күреп сокландым. Казан ул вакытта чәчәк ата башлаган иде генә әле. Камил әфәнде шуның белән бик горурланды. Соңрак, мин Казанга килгәч, ул мине кичке Казан буйлап йөртте. Төрле утларга күмелгән шәһәр әкияттәге кебек ачылды миңа. Аның белән очрашуым әле дә күңелемнең кыйммәтле истәлеге булып саклана».

корулар башлый. Яңа фәннәр буенча белем бирелә, санитария һәм гигиена таләпләренә җавап бирүче, кирпечтән мәдрәсәнең яңа биналары төзелә. Шулай ук тирә-якта барлыкка килүче күпсанлы яңа татар мәктәпләре өчен укытучы кадрларны әзерләү курслары булдырыла. Шушы вакыттан башлап авылның иҗтимагый һәм икътисадый тормышы өчен заманына күрә колачлы үзгәрешләр кертелә.

Мәсгуд Гобәйдуллин абыйлары, шулай ук указлы муллалар белән «Прогрессист мөселманнар оешмасы» булдыралар. Әлеге оешма Бәйрәкә тормышына гына түгел, Бөгелмә һәм тагын берничә өяз тормышына да уңай йогынты ясый. «Гобәйдия» мәдрәсәсе каршында рус класслары, һөнәрчелек мәктәбе, китапханә ачыла. Ул – «Мөхәммәдия»дән кала, икенче урынны алып торучы танылган мәдрәсә булып оеша. Гобәйдуллиннар ярдәме белән Бәйрәкә авылы гасырдан артык вакыт дәвамында төбәкнең рухи үзәге булып тора. Ул, дини агарту эшләре белән генә шөгыльләнмичә, чит ил авыл хуҗалыгы машиналары сату белән дә эш иткән.

Бабалары Мәсгуд Гобәйдуллин турында София Гобәйдулина белән апасы Ида 90 нчы елларда гына беләләр. Сәбәбе аңлашыла... Күренекле дин һәм җәмәгать эшлеклесе Мәсгуд Гобәйдуллин үлгәннән соң, аның гаиләсенә – хатыны һәм өч баласына Арал диңгезе буенда сөргендә яшәргә туры килә...

София Әсгать кызы: «Үземнең Гобәйдуллиннар нәселе дәвамчысы булуымны белеп тору минем өчен бик мөһим. Психологик яктан бик мөһим», – ди. Әлеге сүзләр дөньякүләм танылган композиторны тагын да бөегрәк итеп күрсәтә сыман. Ерак бабалары кебек, ул да алдынгы фикер йөртүче бөек нәселнең зыялы, зәвыклы бер кызы: «Мин гомер буе шул бер үк җырны иҗат итәм кебек... Бу – бертуктаусыз процесс. Кырга чыксам, мин һәр агачның, һәр куакның, һәр чәчәкнең, һәр җан иясенең аһәңен ишетәм сыман. Үземнең аһәңне дә ишетәм. Әнә шул үзеңне, дөньяны ишетергә теләп, нидер тудырырга тырышу өчен үз күзаллавыма кереп китәм. Мин һәрвакыт җанымның иң тирән почмакларына, төбенә төшәргә тырышам. Башка беркемнекенә дә түгел, нәкъ менә үземнекенә. Композитор Дмитрий Шостаковичның теләге минем өчен бик мөһим иде. «Һәрвакыт үзең булып, «дөрес булмаган» үз юлың белән бар», – диде ул миңа. Беркем дә үз җаным тирәнлегенә төшүгә комачауламаска тиеш: җәмәгатьчелек тә, дуслар да, күршеләр дә, укытучылар да». Гениаль композиторның гасырлар аша буыннан-буынга күчеп килгән бу фикеренә кайчандыр аның бабасы Мәсгуд Гобәйдуллин да тугры булып яшәгән. Үз заманының барлык чикләүләренә, тотрыклы законнарына каршы килеп, үз кулы, үз зиһене, алдынгы карашы белән башка дөнья, башка тормыш барлыкка китергән шәхес булган ул. Башкалар өчен дөрес тоелмаган юлы белән баручы шәхес...

Материаллар һәм фотолар өчен София Гобәйдулинаның Заманча музыка үзәгенә рәхмәтебезне белдерәбез.

«Икенче ел рәттән бөтен Җир шары өчен авыр ел килсә дә, шатланырлык вакыйгалар да җитәрлек. Минем өчен 2021 елда иң кадерлесе: барлык туган-тумачам исән-сау, Аллага шөкер.



Илгиз ЗӘЙНИЕВ, язучы, драматург, Татар дәүләт «Әкият» курчак театрының баш режиссёры

Быелгы ел һөнәри шатлыкларга бай булды. Драматург буларак та, режиссёр буларак та шактый премьераларым булып үтте. Шулар арасында Мәскәүдә «Милләтләр театры»нда «Хуҗа Насретдин» спектакле (Россия режиссёры Тимур Бекмамбетов белән берлектә язылды) чыкты. Зур кинода дебютым булды. Берничә автор белән берлектә Тимур Бекмамбетовның «Девятаев» фильмына сценарий яздык. Моңарчы Минзәлә театры белән хезмәттәшлек иткәнем юк иде. Бу елны анда үземнең «Ситсы туй» комедиясен чыгардым. Минзәлә артистларына гашыйк булып, яңа дуслар табып кайттым. Шулай ук Чаллы курчак театрында Достоевскийның «Кроткая» әсәре буенча спектакль эшләдек. Әлеге спектакль Владимир шәһәрендә үткән фестивальдә «Иң яхшы спектакль» һәм «Иң яхшы режиссёр» номинацияләрендә җиңү яулады. Үзем җитәкләгән Татар дәүләт «Әкият» курчак театрында да эшләр гөрләп бара. Артистларыбыз Юрий Чуктиев һәм Дилүс Хуҗиәхмәтов «Тантана» премиясендә «Әлдермештән Әлмәндәр» спектаклендәге рольләре өчен «Иң яхшы курчак театры» артисты номинациясендә җиңү яуладылар. Театр артистлары республикабызның төрле дәрәҗәдәге мактаулы исемнәренә лаек булды, бу – барыбыз өчен дә зур шатлык. Аерым бәхетем: Г. Ибраһимовның «Адәмнәр» повесте буенча күптәннән хыялланып йөргән спектакль эшләдек. Шул спектакль белән Россиянең «Алтын битлек» театраль фестиваль-премиясендә биш номинациядә җиңүгә дәгъва кылабыз. Яз көне Мәскәүдә уйнап, инде нәтиҗәләрне дә белеп кайтачакбыз. Иң мөһиме – эшләргә мөмкинлек бар, театрыбызга тамашачы йөри, иҗатыбызны яраталар.

Зур шатлыкларымның берсе – якын дустым, композитор Эльмир Низамов Россия Президентының яшь иҗатчылар өчен булдырылган Дәүләт премиясенә лаек булды. Тинчурин театрына яңа баш режиссёр – Туфан Имаметдинов билгеләнде: ниһаять, театр билгесезлектән чыгып, тарихының яңа битләрен яза башлый.

Булганына шөкер кылып, киләчәккә өмет белән яшибез.

18 ДЕКАБРЬ
17.00



«КАЗАН ЭКСПО» ХКҮ

И. ШАКИРОВ ИС. КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

КЕРҮ QR-КОД БЕЛӘН

САЛАВАТ
ГҮЗӘЛ УРАЗОВА – ИЛДАР ХӘКИМОВ
АЙДАР ГАЛИМОВ
ИРКӘ
ӘНВӘР НУРГАЛИЕВ
РИШАТ ТӨХВӘТУЛЛИН
ЗӘЙНӘБ ФӘРХЕТДИНОВА
РИФАТ ЗАРИПОВ
ФИЛҮС КАҺИРОВ
ДАНИР САБИРОВ
ЭЛЬМИРА КӘЛИМУЛЛИНА
РИШАТ ФАЗЛЫЙӘХМӘТОВ

АЛЫП БАРУЧЫЛАР:
ГӨЛНАЗ СӘФӘРОВА
ИСКӘНДӘР ХӘЙРУЛЛИН

22 ТАТАР ҖЫРЫ



БӨТЕН ТАТАР ЭСТРАДАСЫ

ТАТАРЖЫРЫ.РФ

ВСЕ БИЛЕТЫ KASSIR.RU

260-72-72

6+

ООО «КАССИР.РУ ПОВОЛЖЬЕ», ОГРН

Шигърият бите бүген яңа исем белән ачыла. Игътибарыгызга Рөстәм Сафин шигырьләрен тәкъдим итәбез. Күпләр аны җыр сүзләрен иҗат итүче автор буларак беләдер. Гөлшат Имамиева, Вәис Бәйрәмов белән иҗади дуслыкта яши ул. Чыгышы белән Яшел Үзән районы Уразлы авылы егете. Кырык елдан артык инде Казанның Оргсинтез заводында эшли. Кешеләрне яратуы, тормыштан матурлык эзләве, хатын-кызларга соклануы, бу дөньяны башкалар күрмәгән төсләрдә кабул итүе сизгер күңеле аша үтә дә, ак кәгазьгә төшә. Әнә шулай шигырь туа, җыр туа...

Рөстәм САФИН

ҖАНЫМ СИНА ЯРАСА...

Кояш нурым

Һәр көн иртән уянуга, керфек кагып,
Тәрәзәдән күзәтәсең таң нурларын.
Безнең өйдә болыт булмый,
йә тор инде!
Күрәсем килә кояшымның
син булганын.

Кояш кебек елмаясың нурлар сибеп,
Наз бирәсең күңелемә кояш кебек.
Кара төннәр яктыргандай булыр иде,
Йолдызларга карап торсаң әгәр көлеп.

Көнем туса – кояшым син,
күңел җылым,
Айга тиңлим йөзең нурын,
кичем җитсә.
Тормышымны яктыртырлык
маяк булып,
Син бирәсең көчләр миңа,
хәлем бетсә.

Бездән соң да кояш җиргә
нурын сибәр,
Сокланырлар бездән соң
да ай туганга.
Исән генә бул – теләгем шул,
кояш нурым,
Күңелемдә болыт булмас,
син булганга.

* * *

Җәй җилләре инде назламыйлар...
Көз килергә әле иртәрәк.
Кырау төшкән күңелем яраларын
Кем дәвалар икән иркәләп?!

Җәй җилләре инде назламыйлар...
Табигатьтә көзләр сулышы.
Сөю көткән күңелем ярсуларын
Басар микән көзләр сагышы?!

Җәй җилләре инде назламыйлар...
Сары төсләр илен көткәндә.
Бар назымны сиңа бирер идем,
Моңсу гына көзләр җиткәндә.

Сагышланма, җәем үтте, диеп,
Сары көзләр сине иркәләр.
Чәчәк ата күңел салкында да –
Парлы булып туса иртәләр.

* * *

Вакыт җитеп, кояш бездән
Кайтмас өчен киткән кебек,
Бушлык тоям, иртән миңа
Күренмәсәң көн дә көлеп.

Ай, йолдызлар сүнгән кебек,
Күңелдән ямь китә элек.
Бер генә көн җир йөзендә
Күренмәсәң миңа көлеп.

* * *

Бер сулыш ул, бер мизгел ул,
Искән җил ул – кеше гомере.
Янып беткән бер шәмгә тиң,
Ятмаса да пыскып күмере.

Кыр да түгел, юл да түгел,
Бер кунак ул – кеше гомере.
Килгән юлын гына белми,
Китәре дә Ходай әмере.

Томан арты хисләре

Исендәме, ул Казанның
Җәйге җылы төннәре?!
Таңын эзләгән сәгатьнең,
Гел ашыккан телләре?

Исендәме, сирәк утлар
Киң урамлы йортларда?
Синең сулышың бәхете
Ай болытлар йотканда.

Исендәме, еллар аша
Яшьлек күптән үткәндә,
Ул чагында әйткән сүзләр
Чәчләреңнән үпкәндә?

Юктыр инде, ашыгасың,
Тукта бераз, кичектер!
Миңа алар бер төш кебек,
Сиңа, белмим, ничектер?

Ул калдырган көйдән

Белмим инде нидән –
Талы башын игән...
Ник тилертә мине
Бу сандугач дигән?

Талы башын игән,
Суга кадәр тигән.
Таң кошчыгын көтеп,
Яз күлмәген кигән.

Белмим инде нидән –
Томан китсә җирдән,
Җырлары да китә,
Хәбәр булса җилдән.

Белмим инде нидән –
Таңга чыксам өйдән,
Шул моңнарны эзлим
Ул калдырган көйдән.

* * *

Сагынам шул, бик тә сагынам,
Сагынуларым өстен барыннан.
Кар суыннан тулган елгалар
Ярсып аккан кебек ярыннан.

Сагынам шул, бик нык сагынам!

Шул ярамны һаман саркытып,
Дәва югын белеп сагынам.
Канатлары сынган кошмы әллә мин?
Очмасам да, җилгә кагынам.

Сагынам шул, бик нык сагынам...

Иң яраткан гөлемә

Бер син минем якыным,
Иң кадерле кешем дә.
Иртән чыккан кояшым,
Көн дә күргән төшем дә.

Төштәгесе – өнемдә,
Өндәгесе – көнемдә.
Чәчәк булып атар идем
Иң яраткан гөлеңдә.

Терәгем син – таяныч,
Хыялым син – юаныч.
Иң караңгы төннәремдә
Язмыш биргән куаныч.

Әгәр аны тиңләп булса,
Гөл мин синең кулыңда.
Иртәнге чык, кичке томан,
Чәчәк – йөргән юлыңда.

* * *

Киңлектерме минем күңел,
Таулар кебек биектерме?
Тал эзләгән сандугачмы,
Яу эзләгән киектерме?

Синең күңел белән куйсаң,
Тау итәге – кырларыдыр.
Кырдан тауга үрелсәм дә,
Буй җитмәслек югарыдыр.

Менәр идем үрләренә,
Кайдан алыйм баскычларын?
Ялгыш бикләп күңелемне
Ялгыш җуйдым ачкычларын...

* * *

Миңа берни дә кирәкми –
Тынычлыктан сине аермам.
Эчтән бикле язмыш ишекләрен
Тик торганда килеп каермам.

Миңа берни дә кирәкми –
Матур шәүләң килсә еракта,
Эзләреңә басып бара алсам,
Киенгәндә кышын җир актан.

Миңа берни дә кирәкми –
Син бул гына минем хакыма.
Өмет саклый язмыш ишекләрен:
Үткәндә кер – ачык, шакыма!

* * *

Күл буеның талы моңсу,
Агым суы булмагач.
Каян килсен миңа ул моң,
Яшь күңелем тулмагач.

Суга тисә яфрак яра
Кышын сынган таллары.
Сине үпсәм ачы булыр
Бар дөньяның баллары.

Җил югында су тибрәтә
Күл буе камышларын.
Сулар алса, салыр идем
Яшьлегем ялгышларын.

Аккошлары кайтыр микән,
Төнбоеклар үсмәгәч?
Бу сөюең сөюмени,
Җаным сиңа күчмәгәч.

Аяз кичтә ай бизәнә,
Күл суына караса!
Үземнекен бирер идем,
Җаным сиңа яраса.

* * *

Минем хисләр әле һаман да
Керәләрме кичен адашып?
Сыенырга урын тапмагач,
Йөриләрме сиңа ярашып?

Китәр алар, юкка борчымас,
Иртәләрең керфек ачканда.
Көн дә төштә күргән хыяллар,
Таң атуга сине кочканда.

Зинһар өчен, кума, үтенәм,
Моңсу миңа алар китүдән.
Килер идем үзем адашып –
Туктый алсам сәбәп көтүдән.

* * *

Төнге күктә утлар сүнеп,
Зөһрә йолдыз калгач ялгызы;
Янәшәдә, күзен йомып ай
Яшергәндә җирдән Зөһрә кызны;
Төнге концерт куеп сандугач,
Йоклаткачтын бөтен халыкны;
Җир белән күк очрашканда,
Буяр өчен ерак офыкны;
Төнге урам тылсымнарын
Күрсәткәндә азлап кына –
Таң җилләре юрган яба
Сөйгәнемә назлап кына.

* * *

Кайвакыт!
Үксим җиргә ятып,
Җир тоядыр минем хәлемне.
Кайвакыт!
Юатырга салып,
Алыр кебек хәлсез тәнемне.

Кайвакыт!
Кояш җиргә ятып
Дәшә сыман офык артына.
Кайвакыт!
Үзем караш атып,
Китәр идем дөнья чатына.

Кайвакыт!
Тамчы җиргә ятып,
Юа алмый еллар тузанын.
Кайвакыт!
Дәва булган вакыт
Аңлый алмый гомер узганын.

Кайвакыт!





Кыш. Ак карлар. Буран. Яңа ел маҗаралары... Тормыш ничек кенә үзгәрмәсен, болар бөтенесе ниндидер бер могҗизага төренеп, гел кабатлана, ел саен ниндидер сихри көче белән ымсындырып тора. Гөлнур Сафиуллина «Буран» хикәясе белән безне әнә шул серле дөньяга алып кереп китә.

Гөлнур
САФИУЛЛИНА

БУРАН

(хикәя)

– Алия, син түгелме соң?!

Тагын бер минут! Нибары бер минут! Һәм алар очрашмаячаклар, бер чиратта басып торганнарын белмәячәкләр иде. Гомердә дә!

Беренче тапкырдан нигәдер акчасын түли алмады Алия. Банк белән элемтә булмый тордымы соң...

– Гафу итегез, карточкагызны тагын бер куеп алыгыз инде...

Сатучы хатынның тавышы бик күңелсез ишетелде. Күңелендә Яңа ел рухы булмаганнар бер Алия генә түгел бугай бу шәһәрдә. Хәер, бәйрәм кичендә дә касса артында утырырга мәҗбүр булган кешегә кәеф кайдан килсен инде...

– Булдымы?

Һәм шул мизгелдә кемдер аның аркасына кагылды.

– Алия?! Син түгелме соң?

Аяк астында кинәт җир убылгандай булды... Бу тавышны меңнәр арасыннан да таныр иде ул... Тик... менә хәзер, бүген, шушы минутта аның белән очрашу һич кирәкми иде бит. Буянмаган, ясанмаган, ярты көн елап күзләре кызарып, шешенеп беткән килеш... Алия сөт шешәсен кулындагы пакетка салды да, чыгу ягына ашыкты. Тизрәк урамга, караңгыга атларга, югалырга, күрмәскә, ишетмәскә...

Ир аны кибет ишегеннән чыгуга куып тотты.

– Алия! Син бит бу! Каян килеп чыктың? Нигә бер сүз дәшми китеп бардың? Нишлисең монда? Күземә күренәсең дип торам! Тукта инде, ашыкма... Мин бит бу, Алмаз!

– Таныдым...

– Алайса нигә качасың? Нишлисең син бу шәһәрдә? Яңа ел кичендә сине очрату могҗиза кебек булды бит әле бу... Артыңда ук басып торганмын бит, ярый сатучыга эндәштең. Һаман ышана алмыйм! Котларга да онытып торам, бәйрәм белән сине!

– Сине дә...

– Карале, нигә сөйләшмисең соң? Бер сүз дәшмисең... Кайлардан килеп чыктың бу якларга?

Көне буе дулаган буран кичкә таба, ниһаять, басылган, урамда тын гына күбәләк-күбәләк булып кар ява. Багана башларыннан төшкән утлардан ераграк китәсе иде тизрәк. Йөзне генә күрмәсен... Аннары туктап аз гына сөйләшеп торса да була. Тик йөрәгенең күкрәгеннән атылып чыгардай булып тибүе аңа ишетелмәсме икән?

– Эндәшергә дә ирек бирмисең бит әле... Сорау тезәсең дә сорау тезәсең. Командировкага килгән идем, буран чыкты да кайта алмый калдым менә...

– Ә кайда тукталдың? Кунакханәдәме? Еракмы? Әйдә, озатып куям. Мин машина белән.

Никләр дип кенә чыкты соң шушы кибеткә? Бер кич сөтле чәйсез дә тора алган булыр иде бит... Нинди көн булды соң бүген?

– Юк, юк, кирәкми! Кунакханәм ерак түгел, күрше урамда гына... Мин китим инде... Сине дә өйдә көтәләрдер. Ә алган әйберләрең кайда соң синең?

Ир кулларын җәеп җибәрде:

– Алмадым! Барысы да кассада калды. Артыңнан куып җитә алмам дип курыктым. Чит кеше кебек киттең дә бардың бит. Исәнләшмәдең дә...

Алия аны бүлдерде:

– Ашыгам мин, Алмаз... Киттем...

– Алия!..

Борылып кына карамаска! Бер адым, ике, өч... Ун! Аяклар алга атлый, күңел исә ашыкмаска куша. «Син бит аңа туйганчы карамадың да. Нинди карау, күзеңне дә күтәрмәдең... Үзгәргәнме ул, юкмы, анысын да күрмәдең», – ди. Озаграк сөйләшеп торсалар, телennән: «Сагындым...» – дигән сүз ычкыныр дип курыкты шул Алия. Бүгенгә кадәр аңа карата күңелендә үпкә, хәтта рәнҗү генә бардыр дип уйлый иде. Берсе дә юк икән – сагыну гына калган. Моны ул аның тавышын ишетүгә аңлады...

Бүген башка еламыйм дип, үз-үзенә сүз биргән иде.

Кунакханәнең өченче катына күтәрелгәнче күзен тагын яшь пәрдәсе каплады. Ярый әле беркем очрамады. Хәер, кем очрасын, Яңа ел төнен бу салкын кунакханәдә каршыларга җүләрләр бармыни? Коридор буп-буш, тып-тын, кай якка карасаң да – ялгызлык. Алмаз артымнан килер, тагын куып тотар, урам чатында басып калмас дип уйлаган иде, ялгышты. Хәтта саубуллашмадылар да. Барысы да кабатлана...

Номерның ишеген ачып керде дә, ут та кабызмыйча тәрәзә янына килеп басты Алия. Каршыдагы йортның аңа карап торган бар тәрәзәләрендә дә ут балкый. Кешеләр бәйрәмгә әзерләнә. Табын коралардыр...

...Ире шулкадәр теләми озаткан иде аны командировкага. «Йөрмә, бәйрәмнән соң барырсың, эш качмый!» – дип, бер түгел, йөз әйтте. Үпкәләшеп беттеләр... «Яңа елга тыныч күңел белән керәсем килә, – дип үҗәтләнде шул Алия. – Кире кайтырга билет инде алып куйдым. 31 декабрь көнне кичке бишләрдә өйдә булачакмын. Яңа ел каршылаганчы хәтта ял итәргә дә өлгерәм әле. Бәйрәмгә бит әнкәйләр чакырды, ул барыбер табынны үзе әзерләргә ярата – мине көтми. Бүләкләрем инде алынган. Аларга да, балаларга да...»

Эше буенча юлы уңды аның – анысына сүз әйтер хәле юк. Ярый әле бәйрәмгә кадәр килгәнмен дип сөенде, югыйсә бөтен яллар буенча шул хакта гына уйлаячак иде бит. Әйе, эше уңды, тик менә кире кайтулар гына... Кичә төнлә буран купты, иртәнгә ул көчәйде генә. Автовокзалга да көчкә барып җитте Алия. Таксист егет аның бертуктамый сәгатькә каравын күреп: «Соңга калам дип борчылмагыз да... Мондый буранда автобуслар барыбер юлга чыкмаячак», – диде. Үзенчә тынычландыруы иде бугай... Башта бер сәгатькә тоткарлана, диделәр, аннан – ике сәгатькә. Янә бер сәгатькә... Ут өстендә утырган кебек утырды ул. Әмма соңлап булса да бәйрәмгә үз өенә кайтып җитәчәгенә өмете бар иде әле. Аннан: «Көтмәгез, автобуслар бүген юлга чыкмый», – диделәр...

Аптырап өенә шалтыратты.

Ире күтәрелеп бәрелде:

– Ә мин сиңа нәрсә әйттем?! Тыңламадың! Үзең гаепле! Утыр хәзер шул автовокзалыңда!

Һәм трубканы куйды.

Болай да тулган күңелгә шул җитә калды.

Кире кунакханәгә әйләнеп кайтып, номерга урнашканчы гына түзде дә, берүзе калгач, рәхәтләнеп елады. Куркыныч төш кебек иде бит бу: Яңа ел төнендә чит шәһәрдә, бер танышың булмаган җирдә ялгызың кал әле. Елый-елый йоклап кителгән... Уянганда бүлмәгә караңгы иңгән иде инде. Куе сөтле чәй эчәсе килә... Әйе, сөт алып керәм дип чыккан иде супермаркетка. Көзгедәге кыяфәтенә күз генә салды да, тукталып тормады: өйдә булса, бу килеш бусагадан да атламас иде, ә монда аны кем белә...

Шулай дип уйлаган иде...

Бу көтелмәгән очрашу да көндезге төшнең дәвамы бугай. Тик матуррак өлеше. Дөресрәге, моңсурак өлеше... Аның бу шәһәрдә яшәп ятканын Алия бит белми дә иде.

Телефонга тагын кемнәндер хәбәр килде бугай. Яңа ел белән котлыйлардыр инде. Берсен дә ачып укыйсы, җавап бирәсе килми. Ә ире кабат шалтыратмады. Бәлки, ачуы узгандыр инде...

– Без әниләрдә... Әйе, апалар да монда... Кызлар уйныйлар... Бүләкләрне бирдем... Рәхмәт...

Котламады! «Сине дә бәйрәм белән!» – димәде. «Хәлең ничек? Син кайда?» – дип тә сорамады...

Алия телефонын сүндереп үк куйды. Алар инде табын янына утырырга әзерләнәләрдер.

Сөтле чәй дә эчәсе килми икән инде...

Телевизорны кабызды. Әйдә, сөйләп торсын әле, бер иптәш булыр. Елны ничек башлыйсың, шулай дәвам итә, диләр – киләсе ел аның өчен нинди булыр икән инде?

Алмаз өендәдер... Хатынына табын әзерләшәдер, мөгаен. Ул да бүгенге очрашу турында уйлыймы икән?

Кинәт ишек шакыдылар. Сискәнеп китте... Ресепшенда утыручы хатын: «Номер салкынча, тагын бер җылы юрган кертербез», – дип калган иде, шулдыр. Сорамыйча да ишекне ачып җибәрде...

– Таптым бит! Барыбер таптым! Яңа фамилияңне белмәгәч, авыррак булды, билгеле. Кечкенә каланың уңай яклары да бар аның – бездә бит кунакханәләр адым саен түгел. Җыен, Алия, мин сиңа шәһәрне күрсәтәм! Яңа ел җиткәнче өлгерәбез әле!

Алмаз «Юк!» дип әйтергә урын калдырмады. Үзе элгечтән алып тунын кидерде, башлыгын, перчаткасын кулына тоттырды һәм җитәкләп диярлек алып чыгып китте. Машинага кереп утыргач кына Алия аңа күтәрелеп карады.

– Алмаз, бүген бәйрәм бит... Өеңдә ни диярләр?

– Борчылма! Минем белән Яңа ел каршыларга теләгән кеше юк анда...

Бер мизгелгә генә күзләре очрашты. Шулкадәр якын итеп карыйлар...

– Киттекме? Хәзер мин сиңа үзем укыган институтны күрсәтәм... Аннан эшләгән җиремне. И-и, яз булсын иде



хәзер! Сиңа шәһәрне гел язын күрсәтергә хыяллана идем... Сиреньгә күмелә ул! Нинди генә төсле сирень үсми монда! Шаккатыр идең...

Алмаз сөйләде дә сөйләде, Алия аны тыңлап кына барды.

– Менә шушында укыдым инде мин... Әтинең бер группадашы эшли иде монда, шуңа бирегә килеп эләктем инде. Классташ малайлар кебек Казанга гына керсәм дә була иде дә бит... И-и, сагына идем инде! Бигрәк тә сине... Күрәсеңме, институт артында зур гына парк бар. Синнән килгән хатларны шул паркта укырга ярата идем. Аулак бер почмакта, үзем генә... Елга бер тапкыр булса да шушы паркка килеп утырып, аларны тагын бер кат укып чыгам...

– Саклыйсыңмыни?

Бу сорауны биргәнен үзе дә сизми калды Алия.

– Саклыйм... Эшемдәге сейфта яталар. Барысы да... Ә мин сиңа бүләк иткән пластинканы саклыйсыңмы соң?

Алия башта «Әйе» дип әйтергә теләгән иде, аннан кире уйлады.

– Юк... Юк шул... Күченгәндә югалттым...

Алмаз бер сүз дә дәшмәде.

София Ротаруның бердәнбер җыры язылган иде ул пластинкада. Алия аны болай да хәтерли: кайда гына ишетсә дә, бу җыр аны гел үткән көннәргә алып китә:

Я назову планету именем твоим!
И будет мир принадлежать всегда лишь нам, двоим...

Машина биш катлы кирпеч йорт каршына килеп туктады.

– Без кая килдек? Эш урының дисәм...

– Уң якка кара әле, өченче катка. Әйе, шул тәрәзәләр... Мин шунда яшим инде.

Өченче катта – бары Алмаз күрсәткән тәрәзәләрдә генә ут янмый иде.

– Без синең белән хәтта керә дә алабыз... Өйдә кеше юк. Ул Яңа елны дус хатынында каршылый. Кызым – бабулясында. Каникул бит...

– Китик, Алмаз...

Бик озак кына дәшми бардылар.

– Алия, ә менә бу теге кинотеатр бинасы! Без синең белән икәү киногa йөргән! Хәзер аны сәүдә үзәге итеп үзгәрттеләр... Киногa барган саен минем ике билет сатып алуымнан группадашлар башта көләләр иде. Аннан ияләштеләр. Билет тикшерүче әбиләр дә... «Сез тагын үзегезнең кызыгыз беләнме?» – диләр иде елмаеп. Берүземә нигә ике билет алуым аларга да сер түгел иде... Янымдагы сиңа дигән урынга беркайчан берәүне дә утыртмадым.

Алия елмаеп куйды.

Алмаз хатларында гел шулай язгач, аның үзенең дә ялгызы гына кинотеатрга барып, ике билет сатып алып киногa кергәне булды. Аннан алдагы рәттә бер егет белән бер кыз утырды. Алар кинoның башыннан ахырына кадәр үбештеләр дә үбештеләр... Алия кинодан бик күңелсезләнеп, моңсуланып чыкты. Янында буш утыргыч. Яраткан кешең бар да, юк та... Алмазның атна саен диярлек: «Ә мин тагын синең белән кино карап кайттым әле!» – дип язуын бик аңлап бетермәде ул.

Машина, шәһәрне чыгып, олы юлга борылды.

– Без кая барабыз, Алмаз?

– Әллә куркасыңмы? Мин янында булганда берни дән дә курыкма! Хәзер, аз гына сабыр ит, килеп җитәбез... Сине очратуыма һаман ышанып бетмим әле, Алия! Быелгы Яңа ел кичennән мондый бүләк көтмәгән идем.

Алия дә нәкъ шул хакта уйлап бара иде. Әле кичен, кунакханә тәрәзәсеннән урамга карап торганда да үз-үзенә: «Бу – гомеремдәге иң күңелсез Яңа ел булачак», – дигән иде бит.

Озак бармадылар, олы юлдан читкә китеп, үр кебек җиргә күтәрелделәр дә туктадылар.

– Килеп җиттек, Алия! Әйдә, машинадан чыгыйк әле.

Ишекне ачып җиргә аяк басуга Алмазның үзен нигә бирегә алып килүен шунда ук аңлады Алия. Алда – караңгы кыр, ә артта... Артта – уч төбендәге кебек шәһәр җәйрәп ята! Утлары белән балкып. Шундый матур!

– Ошыймы? Яратам шушы күренешне... Ерак түгел бакча безнең монда. Җәен эштән соңрак үзем генә кайтырга туры килсә, гел шушы урында туктыйм. Чыгам да басып карап торам... Сиңа да шундый күрсәтәсем килә иде шәһәрне биредән. Кайчан да булса шушында икәү басып торырбыз дип уйламадым да... Юлны буран баскандыр, кереп булмас дип курыккан идем – ачканнар икән. Бакчадагы йортларда Яңа ел каршылаучылар бар, күрәсең...

Алмаз машинаның арткы утыргычыннан плед алып: «Туңа күрмә!» – дип, Алиянең иңнәренә япты. Аннан ике термос тотып килде.

– Без хәзер синең белән Яңа ел каршылыйбыз, Алия! Мә, тот әле. Сөтле чәй бу. Син яратканча куе итеп ясадым! Хәтерлим... Ә үземә мәтрүшкә салдым. Теләсәң, монысын да эчеп карарсың... Үзебезнең якның мәтрүшкәсе – кайткач алып килгән идем.

Чәй тәмле иде.

Моңарчы гел сөйләп торган Алмаз нигәдер тынып калды. Аның янәшәсендә сөйләшмичә генә басып тору да рәхәт иде.

– Алия... Бер сорау бирсәм ярыймы?

Ирнең тавышы карлыккан кебек тонык чыкты.

– Сора, Алмаз...

– Син теге вакыт: «Бала көтәм», – дип нигә әйтә алмадың?

Теләсәң-теләмәсәң дә бүген үткәннәргә кагылмыйча булмыйдыр инде...

– Мин бу сорауга җавапны ул чакта ук биргән идем бит, Алмаз. Син генә нигәдер ишетмәдең. Тагын кабатлыйм – әнине хәсрәткә саласым килмәде...

...Алмаз белән алар унынчыга күчкән елны очраша башладылар. Алияне клубтан кем озата кайтуын белүгә, әнисе: «Вакытыңны бушка уздырма, кызым. Алмаз – әйбәт егет, сүзем юк. Холкы белән әтисенә охшаган ул. Әмма әнисе... Мәрьям апаң гомердә дә безне үзләренә тиң күрмәячәк», – диде. Бер колактан керде бу сүзләр – икенчесеннән чыкты. Икенче тапкыр әнисе Алияне язга чыккач, каршысына утыртып сөйләште.


Рәсем: Наталья Васильева

– Мәрьям апаңның сүзе килеп иреште дә менә. Әйткән идем бит – безне тиң күрмәячәк ул... Хуҗалык рәисе хатыны фермадагы терлекче белән бер өстәл артына утыра аламыни инде?! «Исерек Саматның кызын бусагадан үткәрәсем юк», – дигән. Аралар якынайган саен, аерылышу авыррак була ул, кызым. Өзәргә тырыш әле... Менә хәзер икегез дә мәктәпне тәмамлыйсыз, шәһәргә китәрсез. Үз тиңеңне очратмый калмассың. Синең өчен борчылам бит, кызым, җаныңны яралар дип куркам... Әтиең ишетсә дулар инде. Кабып кайткан чагы да булса, бигрәк тә... Болай да атлаган саен: «Кызларыңны тәрбияли белмисең», – ди. Сезнең хакта начар сүз чыкса, күземне дә ачырмаячак, беләсең...

Алиянең эченә пошаман керде. Кичне көчкә көтеп җиткерде: Алмаз ни дияр икән?

– Әни нигәдер каршы шул... Тик син борчылма! – дип кызны юатты ул. – Мин аның юлын барыбер табам. Без бергә булачакбыз!

Дүртенче курста укыганда, Яңа елга кайткач, өйләнешү хакында сүз кузгатты егет. «Китеп, ике ай узсын да, әнигә: «Без бала көтәбез!» – дип шалтыратып әйтәчәкмен. Бала дигәч, күрерсең, ризалашмый чаралары калмаячак. 8 Мартта никах укытырбыз!» Алиягә аның бу планы башта ук ошамады. «Зинһар, әйтмә, мине генә оятка калдырырсың, тагын бераз сабыр итеп карыйк», – дип каршы төште. Уртак бер фикергә килә алмыйча, аерылыштылар.

Ә Алмаз әнисенә, чыннан да, шалтыраткан булып чыкты.

Ул атнаны Алия ишектән кайтып керүгә, әнисе елый башлады:

– Хур иттең! Хурлар гына иттең... Капка ачып урамга чыгарлыгымны калдырмадың! Ничекләр кеше күзенә күренним хәзер?! Атаң авыз да ачтырмый: «Синең кызларың! Син аларны шундый итеп үстердең!» – ди. Йә, нишләмәкче буласың инде хәзер?! Бала тотып каласың бит... Капкадан да уздырмаячаклар алар сине. Атаң да бала белән өйгә кертмәячәк – уйлама да...

Алдагы көнне әнисе кибеттә Мәрьям апа белән очрашкан икән. Кибет тулы халык алданда: «Кызың бала белән улымны үзенә бәйләп куймакчыдыр. Өметләнмәсен! – дигән Алмазның әнисе. – Әле башта ачыклыйсы бар – ул бала безнең малайданмы, әллә түгелме? Әйт кызыңа, соң булмаса – төшертсен!» Урамда очратып үзенә генә әйтсә – бер хәл, кибет уртасына басып, бөтен кеше ишетерлек итеп кычкыра-кычкыра сөйләгән...

Алиянең: «Әни, ышан, бер гөнаһым юк!» – диюенә әнисе кул гына селтәде. Авылда чыбыксыз телефон яхшы эшли, хәбәр инде кичә кич үк килеп ирешкән: «Алмаз, өйләренә шалтыратып, үзе шулай дигән».



– Төшерт дияргә телем әйләнми... Үзең хәл ит... Атаң аңа кадәр мине бәреп үтермәсә, булышу җаен ничек тә табармын. Бала тугач дим... Әлегә авылга кайтып күренеп йөрмә. Бар, кит инде син... Күз көеге булып каршымда басып торма! Көтмәгән идем синнән моны...

Нахак бәладән авыры юк икән.

Алмазның көн аралаш килгән хатларын укымыйча да чүп чиләгенә салды Алия. Егет әллә ничә тапкыр телефоннан сөйләшергә чакырып карады – бармады. Хатлар килү сирәгәйде, аннан бөтенләй туктады.

...Алмаз аны бүлдермичә тыңлады.

– Мин авылга җәйге каникулга гына кайттым. Халык тагын бер гөжләп алды. «Баласын төшерткән икән», – дип сөйләделәр. Беләм, өйдәгеләр дә шулай уйлады. Хәер, әни хәзер дә шулай дип белә. Акланмадым... Акланырга көчем калмаган иде инде. Кайтуга әни синең өйләнгәнеңне әйтте...

Сүзсез генә, үрелеп, Алмаз аның кулындагы термосны алды. Аларны машинага куйгач, кире борылып килде дә, шәһәр утларын каплап, Алиянең алдына чыгып басты.

– Син бүген кунакханәгә кайтмасаң буламы?

– Юктыр... Юк, Алмаз!

Машинага кереп утырдылар. Әмма Алмаз кузгалып китәргә ашыкмады – кулларын руль өстенә салып, йөзе белән шунда капланды.

– Әнигә үч итеп өйләндем мин, Алия... «Яраткан кешем белән бергә булырга рөхсәт бирмисез икән, марҗа киленгә ризалашырга туры килер», – дидем... Ярсуым бераз сүрелгәндә соң иде инде. Хатын балага узды... Башта бала туганчы гына торырмын дип уйладым, аннан кызымны ятим итәргә көчем җитмәде. Яшибез инде... Әни бик үкенә хәзер, тик терсәк якын да, тешләп булмый шул... Авылга парлап кайткан да юк. Аның белән кайтасым да килми... Тормышым барып чыкмаганга мин бит күңелемнән гел сине гаепләдем... Ул чакта сине нинди хәлдә калдырганымны белмәдем... Бөтенләй белмәдем! «Бала көтәм», – дип әйтмәгәч, мине инде яратмыйсың дип уйладым... «Әти-әниеңнең фатихасыннан башка кавыша алмыйбыз», – диюең сәбәп кенә булгандыр, дидем... Бүген кич буе сине кочагыма кысып-кысып ярату турында гына хыялланган идем. Менә яңа аңладым – сиңа кагыла алмыйм икән. Хакым юк!..

Алмаз машина тәрәзәсе артындагы караңгылыкка төбәлде.

– Телефон номерыңны гына бир, Алия! Бик сирәк шалтыратырмын... Башкача түзә алмаганда гына... Әмма теләсә кайсы мизгелдә тавышыңны ишетә алам дигән уй миңа яшәргә булышыр...

...Ишекне ачып керүгә, батареяларны тотып карады Алия. Юк, һаман шул килеш икән. Әмма кунакханә бүлмәсе көндезгегә караганда күпкә җылырак кебек тоела. Ятарга кирәк, иртәгә иртүк юлга... Сискәндереп, телефонына хәбәр килеп төште. Тагын берәрсе котлыймы икән соң? Ниндидер таныш түгел номер. «Мин сине гафу иттем, син дә мине кичер...» Аңардан!

Соңгы еллардагы иң рәхәт Яңа ел киче иде бу. Сагынуга түзеп була ул, күңелдәге үпкә белән яшәүләре авыр...

«2021 ел минем өчен көтелмәгән үзгәрешләр елы булды. Әйне алыштыру тулаем дөньяга караш үзгәрү, офыклар киңәюгә бәрабәр икән...




Гүзәл СӘГЫЙТОВА, Казан башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, «Калеб» иҗат берләшмәсенә нигез салучыларның берсе

Социаль өлкәне җитәкләүче кеше буларак, ниндидер идея өчен чын күңелдән янучыларның шактый булуын тойдым. Әнә шул ачыш күңелне җылыта...

Елның иң якты мизгелләре дә, моңсу вакытлары да Габдулла Кариев исемендәге Татар яшь тамашачы театры белән бәйледер. Мин анда ике ел ярым гына эшләргә өлгердем. Труппа белән саубуллашканда, аягүрә торып кул чабулары, күз яшьләре – беркайчан да онытылмый торган мизгелләр... Саубуллашу һәрберебез өчен көтелмәгәнчә тиз булды, шуңа да ул вакытларны искә алганда, күзләргә әле дә яшь килә...

Шулай ук 2021 елны мин гаиләгә тагын да якынаю елы дияр идем. Кызым Асылъяр белән без бергә үсәбез, үзгәрәбез. Элек миңа ял өчен күп нәрсәләр кирәк кебек тоела иде, хәзер исә гаилә белән ял итү, кичләрен вакытны бергә үткәрү, табигатькә чыгу тынычлык, рәхәтлек бирә.

Ә инде шәһәрдә татар телле проектларны тормышка ашыра алу – үзе бер бәхет. Татар теле курслары, укытучылар өчен семинарлар, татар балалар бакчалары һәм мәктәпләренә мониторинг, «Саумы, Казан» хикәяләр конкурсы, балконнардагы «Казан тавышлары», Сәйдәш үзәгендә «Сөйли торган материя» исемле шигъри-музыкаль кичәләр, татар теленә өйрәтүче видеороликлар, метрода поездны милли бизәү һәм башка идеяләрне гамәлдә күрү күңелгә канәгатьлек бирә.



ХЫЯЛЛАР ЧЫРШЫСЫ

Алсу ШАКИРОВА

Яңа елга шәһәрне ноябрь аенда ук бизи башлыйлар. Бик дөрес, шулай кирәк дип саный Марат. Бәйрәм рухын мөмкин кадәр алдан тудырырга кирәк. Бәйрәм узгач, урам тулы төрле төстәге ут утлар, инде бар да узганны хәтерләтеп, моңсулык кына биреп торачак. Ә болай ике ай алдан могҗиза көтә башлыйсың... Яңа елда бар да яхшыга өметләнә, нииндидер үзгәрешләр көтә...

Балалар йортыннан чыкканнан бирле Яңа елны мөмкин кадәр матуррак итеп уздырырга тырыша Марат. Балачактан хыяллана иде ул бу турыда: үз гаиләсе, үз йорты булгач, аның өендә чыршыны ноябрь аенда ук куячаклар! Балалары бүләк сорап Кыш бабайга берне түгел, ун хат язачак! Һәм аның барлык теләкләрне дә тормышка ашырырга, балаларын сөендерергә акчасы булачак...

Тормыш кына балачак хыялларыннан шактый аерыла икән... Ярый, алай да зарланмый Марат. Балалар йортыннан киткәч тә аңа барысын да яңадан башларга кирәк иде бит. Алдан әзерләп торучысы юк... Бүгенге тормышы белән беркемгә дә бурычлы түгел ул. Барына да үзе иреште. Хатыны Алия белән алган өч бүлмәле фатирларының ипотекасыннан да котылалар инде менә бәйрәм алдыннан. Яңа елдан бер әҗәтсез яши башлый гаилә ниһаять!

Өйдә чыршы бизәделәр инде. Беренче кар төшүен көтеп кенә торган балалар, ясалма чыршыны балконнан алып кереп, аңа төрле төстәге уенчыклар, мишура элделәр. Җем-җем итеп торган утларын куярга гадәттәгечә әтиләре булыша. Улы Рәсим шул ук көнне Кыш бабайга хат язарга утырды. Барысы да йоклап беткәч, «Кыш бабай» ул хатны суыткычтан алып укыды. 4 яшьлек малай машина да, уенчык та сорамаган – телефон кирәк икән аңа. Әһә, бар нәрсәне дә апасы кебек эшләргә яратучы Рәсим аның да серен чиште болай булгач – кызы яңа телефон көтә Кыш бабайдан. Юк, ун хат ук яздырып булмый балалардан: үземнекеләргә бөтен сораган әйберләрен алып бирәм дип хыялланган иде, тик хәзерге балаларга акча җиткерү җиңел түгел икән.

Премия акчасын алуга, шәһәрнең сәүдә үзәгенә юл тотты ул. Кызы Рәмзия нинди телефон турында хыялланганын белә: хәзер үк алып куйса, Яңа ел алдыннан башкалар кебек ыгы-зыгыда бүләк эзләп интегергә туры килмәячәк. Сәүдә үзәгенең бер читендә ел саен чыршы бизиләр. Ләкин уенчыклар урынына анда хатлар элеләр. Марат ул чыршыны ел саен күрә. Ләкин якынрак барып карарга йөрәге җитми. Эштәге дусларыннан ишетеп белә: бу чыршыга балалар йортларында, ишле гаиләләрдә, начар шартларда яшәүче балаларның Кыш бабайга язган хатларын элеләр икән. Теләге булган һәр кеше, шул чыршыдагы берәр хатны алып, баланың хыялын тормышка ашыра ала.

Хыяллар чыршысы, димәк... Андагы һәр хатның эчендә Маратка таныш хисләр, таныш хыяллар, өметләр язылган кебек тоела. Бик теләсә дә, моңарчы берсен дә ачып укырга йөрәге җитмәде ирнең. Балалар йортында тәрбияләнүче сабыйларның иң зур теләге нинди булуын аннан да яхшы белүче юк. Алар барысы да гаилә, әти-әни назы турында хыяллана. Кыш бабайдан да шуны көтә.

Быел бу чыршыны да иртәрәк бизәгәннәр. Күтәрелеп карамаска тырышып, Марат аның яныннан тиз-тиз генә узып китте. Кирәкле кибеттән кызына бүләк алганнан соң, кайту ягына борылды. Ләкин баскычка җиткәч кинәт туктап калды. «Күпме куркып йөрергә була инде? Ал да укы хатларның берсен. Ичмасам, бер сабыйны уенчыклы итәрсең. Үзеңне искә төшер: шоколад бирүче булса да ничек шатлана идең, аның кәгазен матрас астында саклап, төннәрен татлы исен иснәп ята идең...» Әнә шулай, үз-үзен битәрли-битәрли, чыршы янына кире әйләнеп килде дә, буе җиткән кадәр сузылып, иң өстәге хатны тартып алды. Шунда ук укырга йөрәге җитмәде. Йөрәге дөп-дөп тибә... Кем язды икән? Малаймы, кызмы? Гаиләдә яшәүче бала гына булса ярар иде. Балалар йортындагы ятим булса, бигрәк кызганыч булачак... Машина эченә кереп утыру белән хатны ачты Марат.

«Исәнме, Кыш бабай! Ел саен мин синнән бер үк әйбер сорыйм, ачуланма. Тик ул хыялымны хәтта сиңа да тормышка ашыру авыр, ахрысы. Энем Хәлим белән икебез дә синең килүеңне түземсезлек белән көтәбез. Хәлим бигрәк тә көтә. Шуңа күрә миңа бүләк алмасаң да ярый, миңа дигәнен дә Хәлимгә алып кил. Берсен мин аңа Яңа ел бүләге итеп бирермен, икенчесен туган көненә бүләк итәрмен. Тиздән туган көне җитә аның. Кочаклап йоклый торган аюы тузып, сүтелеп бетте, эчендәге мамыклары да төшеп калган. Аңа икенче йомшак уенчык алып кил әле, Кыш бабай. Ат булса бигрәк сөенер иде. Мондагы уенчыклар арасында бер ат та юк, атны рәсемнәрдә генә күргәне бар. Ә икенче уенчыгы машина булсын. Артык зур кирәкми. Кочаклап, култык астына кыстырып йөртерлек булса, әйбәтрәк. Алайса ул аны башка малайлардан саклап кала алмас.

Ә теге теләгемне тагын бер кат искә төшерәм, Кыш бабай. Бәлки, кемгәдер кыз белән малай кирәктер? Шуларга безнең турында әйтеп кара әле. Тәртипле алар, диген. Мин бик матур итеп кар бөртекләре ясарга өйрәндем. Яңа елга үзебезнең өй тәрәзәсен шулар белән бизәр идем. Дуслык урамы, 17 нче йорт, Балалар йорты, Зәринә, 9 яшь».

Хатны укып бетергәндә Маратның бите буйлап туктаусыз күз яше ага иде. Балалар йорты коридоры буйлап йөгереп йөрүче Хәлим, аның моңсу апасы Зәринә күз алдына килде. Башкалар кыерсыткан вакытта энесен якларга мәҗбүр булган, энесе өчен борчылган, аны бәхетле итәргә тырышкан кызны бигрәк кызганды. Быел чыршыларны ни өчен шулай иртә бизәгәннәрен аңлады Марат. Ул өлгерсен өчен шулай кирәк булган бит. Зәринә белән Хәлимгә дигән бүләкне бүген үк әзерли башларга тиеш Марат. Ашыкмый ярамый! Яңа елга нибары ай ярым вакыт калды...

– Әти, әти, кар ява! Ә син быел Яңа ел карсыз була, ахрысы, дигән идең. Ява бит, әнә! Кар бабай ясарга чыгабызмы иртәгә, әти? Йоклап торгач та чыгабыз, яме! – дип, улы Рәсим тәрәзә төбенә менеп үк утырды. Аның тавышын ишетеп Рәмзия дә йөгереп керде. Көтелгән кар шул бу. Өйдә утны сүндереп, яхшырак күренсен өчен дүртесе дә тәрәзәгә капландылар. Ябалак кар ява. Кар бөртекләре шулкадәр эре, аларның бизәкләрен күрергә була хәтта. Марат тәрәзәне ачып, урамга кулын сузды. Шул арада уч төбенә әллә ничә кар бөртеге төшеп кунды. Җыелган карны, йөзенә якынрак куеп, игътибар белән карый башлады Марат. Шулкадәр матурлар! Нәкъ менә Маратларның тәрәзәсенә ябыштырган кар бөртекләре кебек. Зәринә ясаган кар бөртекләре...

Хәлим белән икесен өч тапкыр кунакка алып кайттылар инде Марат белән Алия. Зәринә аларның барысын да кар бөртекләре ясарга өйрәтте. Фатирдагы өч тәрәзәне дә шул кар бөртекләре белән бизәделәр. Кәгазь эшләр – документ җыюлар тәмамланып килә инде. Бүлмәдәге шкафта кызларга дигән ике телефон, малайларга дигән пультлы машиналарны Алия белән икәүләп ике атна элек үк матур тартмаларга салып, әзерләп куйдылар инде.



Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Укытучыларымның якты сурәтләре менә бүген дә кино челтәрендәге матур хатирәләр сыман бер-бер артлы күз алдыма килә.

Ул вакытта без генә түгел, авыл халкы да укытучыны ихтирам итә белә иде. Әйе, мәктәбем, барлык укытучыларым турында күп итеп, берсен дә калдырмыйча, бәйнә-бәйнә итеп язасы килә! Кино челтәрендәге сыман булса да, безне укыткан укытучыларым турында тезеп чыгасы иде. Барысы да олы ихтирамга лаек шәхесләр иде бит. Аларның шактые бу дөньда юк инде...

Канатлы ак алъяпкычлар киеп, очып китәргә әзерләнгән кош кебек, талпынып, 1 сентябрь иртәсендә мәктәбемә килүгә мине елмаеп каршы алган беренче укытучым Мәхтүрә Латыйп кызы Мусина булды. Күпме наз, җылылык, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек чагыла иде аның йөзендә! «Балалар! Сезне үзем белгәннең барысына да өйрәтермен», – диде ул. Бу чакта безнең өчен Мәхтүрә ападан да акыллырак, белемлерәк, матуррак беркем дә юк кебек тоелды. Без аңа беренче көннән үк үзебезчә, якын итеп: «Апа!» – дип дәшә идек.

«Укытучы апа – мәктәптәге әни» дигән төшенчә шул заманнан ук каныма сеңеп калган. Мәхтүрә апаның җылы, кайгыртучан карашын, безгә булган мөнәсәбәтен шулай тиеш дип кабул итә идек ул чакта. Кара күзле, зифа буйлы апабыз матур, пөхтә итеп киенә, тигез, чиста тавыш белән сөйли, моңлы итеп җырлый... Кап-кара чәчләрен җыеп, артка өеп куюына, хәтта салмак йөрешенә дә соклана идек ул чакта. Укытучыбызны ихтирам иткәнгә, яратканга күрәдер, һәрчак тырышып укырга омтыла идек... Билгеле, кирәк вакытта таләпчән дә булды. Ул безне бик ярата иде, үз балаларыдай якын күрде. Әгәр безгә Мәхтүрә апабызның җылы карашы булмаса, ихтимал, бездә уку кайгысы да булмас иде. Өстәлдә – каләм сөрткече, кесәдә – чиста кульяулык, чиста ак яка, колак, кул, муен, куллар чиста, тырнаклар киселгән. Көн саен дәрескә кадәр вожатый апалар тикшереп чыгалар



иде. Иң күңеллесе – дежур тору булып истә калган: ручкалар, кара савытын тарату, дәфтәрләр өләшү, такта сөрткечен әзерләү, бүлмәне тәртиптә тоту.

Беренче укытучымның яшьлеге авыр елларга туры килсә дә, тырышлыгы аркасында педагогик белем алып, 42 ел гомерен яшь буынга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган. 1949 елда «Аеруча хезмәт күрсәткәне өчен» медале белән бүләкләнгән. Мәхтүрә апабыз Мусина авылыбызда йөзләгән балага белем һәм тәрбия биреп, һәркайда да җитешкән. Партия оешмасында да торган, белем җәмгыятен дә җитәкләгән, актив лектор да, хатын-кызлар советы рәисе дә булган. Бәйрәмнәр җитсә, сценарий язучы да ул булган. Төп рольләрне дә үзе башкарган. Концертларда моңлы тавышы белән авыл халкын да сөендергән... Ә Мәхтүрә апамның үз балаларына килсәк, аларны кемнәр генә белми?! Авылыбызның ихтирамын казанган мөхтәрәм кешеләре Әхмәт абый белән Мәхтүрә апа гаиләсендә үскән өрлектәй дүрт ир-егетнең даны күптән инде Татарстан чикләрен үтте. Бертуган Роберт, Инсаф, Илфак, Атлас Исламовлар, аларның хәләл җефетләре, балалары, җырлы-моңлы гаилә булып күпләрнең күңелен яулады. Югары белемле дәрәҗәле кеше-

Фото: Анна Арахамия

ләр булып, Мәхтүрә апабызны да 82 яшенә кадәр тәрбияләп, кадер-хөрмәттә соңгы юлга озаттылар.

Беренче укытучым... Бар күңелең белән яраткан укытучыңнан аерылмыйсың икән ул. 3 нче класста укыганда «Кем булырга?» дигән темага инша язып килергә кушкач, һич икеләнмичә: «Мәхтүрә апам кебек булам!» – дип язган идем. Яраткан укытучымнан үрнәк алып, башлангыч класс укытучысы һөнәрен сайладым. Аның белән һәр очрашу җанга рәхәт иде.

Гаҗәеп кеше иде инде ул: аның өчен бар да туган, бар да дус, һәркемнең хәленә керә, җылы сүзен таба. Укытучы гомер буе укытучы булып кала икән шул!

Тәкъсимә ГАРИПОВА.
Азнакай.

Бу тормышта бик күп мактаулы хезмәт ияләре бар. Шуларның берсе – игенче.

Авылыбызның яшь механизаторы Фирзәр Шәфыйков Тукай районы Калмия авылында туып-үсә. Кечкенәдән техника «җене» кагылган аңа: урта белем алгач, Сарман аграр колледжына укырга керә Фирзәр. Тракторист-машинист һөнәрен үзләштереп, туган авылына кайта. Бөтен эшен җиренә җиткереп башкара ул. Тырмалау, туфрак эшкәртү, чәчү кебек кыр эшләрендә катнаша башлый. Җәен – тракторда, көзен – комбайнда. Кыш көннәрендә трактор паркында токарь булып хезмәт итә.

Быел корылык булса да, комбайнда бик яратып эшләде Фирзәр. «Вакытның кадерен белеп эшләсәң генә бар да яхшы була. Ашлыкларны җыеп бетереп амбарларга тутыргач, күңел тынычлана, өмет өстәлә. Таңның үзе белән уянып, тәмле хуш исле басуларны иңләп йөрү – үзе зур бәхет, үзе бер матурлык», – ди игенче егетебез.

Уңган ир, тырыш механизатор ул. Техниканы яхшы белә, бернидән дә курыкмый. Тормыш иптәше Рәлия белән ике ул тәрбияләп үстерәләр. Беренче улларына 9 яшь, икенчесенә әле 2 генә яшь. Әниләре белән бик тату яшиләр. Рәзинә апа да балалары өчен сөенеп туя алмый. Бу матур, булган гаиләгә киләчәктә сәламәтлек, зур уңышлар телибез. Мондый егетләр булганда игеннәр дә уңар, уңышлар да мул булыр. Киләчәктә дә мактаулы хезмәтендә зурдан-зур уңышлар, гаиләсенә һәм үзенә ныклы сәламәтлек, имин көннәр насыйп булсын.

Энҗе ГАЛИӘХМӘТОВА.
Тукай районы.

Революциягә кадәр туган әти-әнием институтларда югары белем алмасалар да, безгә нинди яхшы тәрбия биргәннәр. Шул хакта уйланып йөрим.

Максим Горький әйтмешли, «тормыш университетлары»н әти-әнидә үттем мин. Укытучыларым да, тәрбиячеләрем дә булды алар. 1,8 метрлы әти метр ярымлы кечкенә генә әнине ничек хөрмәт итеп яшәгәнен күреп үстем. Безнең алда алар беркайчан да ачуланышмадылар.

Әни мине мәктәпкә бирмәде. Үзем гарәпчә укытам, диде. 1946 елда әти япон сугышыннан кайткач, Европаны иңләп-буйлап йөреп чыккан кеше буларак, беренче эш итеп мине җитәкләп мәктәпкә илтте. Җиденче сыйныфтан соң, җәяүләп, Алабуга мәдәни-агарту мәктәбенә имтихан тапшырырга киттем. Мәктәпкә керсәм, идәнгә паласлар җәелгән. Озын ефәк күлмәк кигән кыз пианинода уйный. Ә минем баян да күргәнем юк... Җитмәсә, имтихан да рус телендә. Хәлемә кереп, укытучылар имтиханнарны язмача бирергә рөхсәт иттеләр, барысын да «биш»легә яздым. Укырга керүчеләр исемлегендә мин булмасам да (анда музыка мәктәбендә укыганнарны гына алганнар), директор каршында укытучылар мине якладылар, укырга алдылар. Шул вакытта рус телен өйрәнәм дип ант иткән идем, өйрәндем. Әтинең сүзләре исемнән чыкмады: «Татарча да, русча да, чит телне дә белергә кирәк. Моны үз җилкәмдә татыдым», – дигән иде ул.

Әтинең сугыштан кайткан көнен әле дә хәтерлим, аркасына аскан капчыктан нәрсә чыгарыр икән дип көтәбез: күлмәкме, конфетмы? Берничә консерва банкасы, сохари чыгарды әти. Аннары безгә – балаларга дәфтәрләр, рәсем китаплары, гомеребездә күрмәгән карандашлар, ручкалар чыкты. Ул вакытта иске китап битләренә яза идек. Карандашларны урталай бүлеп, мәктәптә укучыларга да өләште әти. Ул гадәт миндә дә саклана: бары – бергә, югы – уртак. Әти гомер буе кешеләргә ярдәм итәргә тырышты. Без дә аннан күреп, ярдәмчел булып үстек.

1947 ел булгандыр, безнең авылга нефтьчеләр килде. Аларны өйләргә фатирга кертәләр иде. Бораулаучы мастер Вилдан абый Гәрәев гаиләсен безгә урнаштырдылар. Вилдан абыйның хатыны Минҗиһан апа сугышта булган кеше. Сугыштан кайткач, клубка чыгарга җыена икән бер кичне. Әнисе кулына табагач алып: «Мөселман кызына клубка барырга ярамый, җибәрмим!» – дип, ишеккә аркылы баскан. «Әнинең табагачын дошман мылтыгын каерып алган кебек тартып алдым да клубка киттем», – дип сөйләп көлдерә иде безне. Вилдан абый да сугышта булган, бик сабыр, акыллы кеше иде. Өйдә кайчак басып торыр урын да юк – алар бишәү, без дүртәү... Бишкә – бишле кечкенә генә өебез. Без, биш бала, өстәл астында уйныйбыз, үзебез бишек тирбәтәбез. Өйнең күп өлешен мич алып тора, ипине шунда пешерәләр, учак ягып аш өлгертәләр. Авылда зуррак өйләр дә булгандыр. Әмма Вилдан абый белән Минҗиһан апа әти белән әнине сайлаганнар һәм дөрес эшләгәннәр. Әлмәт нефтьчеләре турындагы китаптан Вилдан Гәрәев турындагы язманы табып укыдым. Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелгән аңа.

Ике гаилә бик тату яшәдек без. Күбәү булсак та, бер кычкырып сөйләшкән кешене дә хәтерләмим. Әти белән әнинең күңелләре киң булган дип сокланам. Аларның әнә шундый күркәм үрнәгендә тәрбияләнеп үскән балалар без.

Саимә МОРАТОВА.
Чирмешән районы.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA

МОГҖИЗА



Фото: Анна Арахамия



Фәгыйлә
ШАКИРОВА

Гөлназ белән без университетта бергә укыдык. Тулай торакның бер бүлмәсендә бергә яшәдек. Ашаган ризыкларыбыз гына түгел, кигән киемнәребез дә уртак иде. Стипендия 45 сум гына, аңа гына яшәргә, әлбәттә, авыр. Җитмәсә, башкалар кебек атна саен өйгә дә кайтып йөри алмыйбыз – авылларыбыз ерак. Мин – Әлмәт ягыннан, Гөлназ – Башкортстаннан. Студентлар өчен бирелгән талоннарны тотып, кибеттә чират торабыз. Хәзерге кебек кием сайлау мөмкинлеге дә юк, ә матур киенәсе килә. Әти-әниләр җибәргән акчаны җыеп, базарга барып, пардан «Мальвина» джинсы чалбары алып кигәнебез бүген дә хәтердә. Аерылмас дуслар идек!

Бишенче курста укыганда Гөлназ бер егет белән танышты. Айрат – Чаллыдан, университетның юридик факультетында белем ала иде. Алар озак очрашмадылар: Айрат берничә айдан соң ук Гөлназга тәкъдим ясады. Туйлары бик гади узды. Кияү белән кәләш загска барып язылышып кайттылар, мине шаһит итеп чакырдылар. Язылышкан җирдә Айратның берничә дусты гына бар иде. Ә кич белән тулай торак бүлмәсендә кечкенә генә туй мәҗлесе узды.

Туйдан соң Гөлназ ире белән фатирга күченделәр. Соңгы тапкыр дустымны диплом алу тантанасында күрдем. Шуннан аралар өзелде. Ире Чаллы шәһәрендә эшкә урнашкан дип сөйләделәр.

Егерме ел буе Гөлназдан бер хәбәр дә алмадым. Интернет барлыкка килгәч, эзләп тә карадым югыйсә. «Одноклассники»дан, «ВКонтакте»дан, аннан «Инстаграм»нан... Социаль челтәрләрнең берсеннән дә аны тапмадым. Группадашлар очрашуына да Гөлназдан кала, барыбыз да килгән иде. Кемдер аны ире белән Себер якларына китеп барган дип сөйләде.

Инде Гөлназны оныта да башлаган идем. Беркөнне таныш булмаган номердан шалтыраттылар. Дөресен әйткәндә, билгесез номерлардан шалтыратучыларга бик җавап та бирмим. Ә бу юлы нигәдер телефонны алырга булдым. «Сәлам, дускаем, хәлләрең ничек?» – дип эндәште таныш булмаган хатын-кыз. Кемдер ялгыш эләкте бугай дип уйларга гына өлгердем, телефонның теге башындагы тавыш дәвам итте: «Бу мин – Гөлназ! Тулай торакта бергә яшәгән дустың! Номерыңны озак эзләдем, көчкә таптым менә. Мин Казанда, бер атналык командировкада. Очрашасым килә синең белән. Вакытың бармы?»

Сөенечемнән югалып калдым – кулымнан телефоным төшеп китә язды. Кичке сәгать биштә, студент вакытта яратып йөргән Черек күл буенда очрашырга сүз куештык.

Гөлназны күргәч танымадым башта. Кыска чәчле, ябык гәүдәле группадашым тулы гәүдәле ханымга әверелгән. Башында зәвык белән мөселманча бәйләнгән ак яулык, озын күлмәк. Ә йөзе бер тамчы да үзгәрмәгән кебек. Күзләре зәп-зәңгәр – студент елларындагы кебек балкып торалар.

Кочаклашып күрештек. Минем хәтта күзләремнән яшь тамчылары тәгәрәде. «Дускаем, кайларда югалдың син? Мин бит сине бик озак эзләдем!» – беренче сүзем шул булды.

Гөлназыбыз, чынлап та, ун ел Төмән шәһәрендә яшәгән икән. Ирен бер нефть оешмасына өлкән юрист итеп чакырган булганнар. Ул да ире эшләгән оешмада хезмәт куйган. Аннары Чаллыга күчеп кайтканнар. Бизнес ачканнар – алтын кибетләре тоталар икән.

Гөлназ белән сөйләшеп сүзләребез бетмәде. Черек күлне кат-кат урагач, кафега кереп утырырга булдык. Дустым хәләл ризыклар белән генә туклана икән. Әмма андый урынны табу проблема булмады – хәзер бит хәләл кафелар адым саен диярлек.

Хәләл ризыкка бәйләп, сүз аның дингә килү тарихына күчте. Гыйбрәтле булганга күрә, бу тарихны Гөлназ сөйләгәнчә бәян итәм. Әлбәттә, аның үзенең ризалыгы белән.

– Айрат белән бик матур яшәдек, – дип сөйләп китте ул. – Тормышыбыз бөтен, мул, акчага тилмермәдек. Ләкин дөнья бар яктан да түгәрәк булмый икән шул. Балага уза алмадым... Мәскәүгә генә түгел, Германия табибларына кадәр күренеп карадык, әмма файдасы булмады. Өч тапкыр ЭКО ясаттым, тик барысы да уңышсыз. Яшем кырыкка җиткәндә ана булу хыялына нокта куйдым. Ирем дә килеште... Үзебез өчен яшәргә булдык. Нихәл итәсең, Аллаһы Тәгалә бөтен кешегә дә бала бирми бит.

Ә аннан сукыр Гөлчирә әби турында ишеттем. Аның янына балага уза алмаучылар киләләр һәм шифасын күрәләр икән. Күңелдә кабат өмет уянды. Батып баручы саламга ябыша дигәндәй, мин дә шул әби янына барып карарга булдым.

Гөлчирә әби яшәгән авылны эзләп, ике сәгать адашып йөрдем. Әмма барыбер таптым! Кызы белән авыл читендәге кечкенә генә өйдә яши икән. Күчтәнәчләр салган пакетларымны күтәреп килеп кердем аларга. Ак яулык бәйләгән 80 яшьләрдәге карчык, дисбесен тартып, караватта утыра. Мин ишектән килеп кергәч, ят кеше икәнен шунда ук сизде, башы белән ымлап, янындагы урындыкка күрсәтте. Алып килгән күчтәнәчләремә озак итеп дога кылды, рәхмәтләр әйтте. Елый-елый, балага уза алмавымны, табибларда дәвалануымның файдасызлыгын сөйләдем.

Әби дәшмичә генә тыңлады, аннары уң кулымны кытыршы бармаклары белән сыйпап учына кысты. «Намаз укып, Аллаһы Тәгаләдән сора, балам», – диде.

Миңа бу сүзләрдән соң эссе бәргән кебек булды – кан басымым күтәрелде. Ике сәгать буе юлда азапланып, мондый сүзне ишетермен дип килгән идеммени мин?! Ачуым чыгып әбинең учыннан кулымны тартып алдым. Вәт җүләр мин, менә сиңа имче, менә сиңа өшкерүче... Алайга китсә, бөтен кеше намаз укып кына сорар иде дә, балага узар иде дип уйладым һәм чыгып китәргә дип торып бастым. «Сүземне тыңла, балам. Горурлыгың, минминлегең юлыңны каплый. Үзеңне башкалардан өстен куясың. Горурлыгыңны җиңсәң, Аллаһ ризалыгы белән балага узарсың», – диде әби тыныч кына кыланмышларыма игътибар да итмичә. «Мин 20 кешелек коллектив белән идарә итәм. Усал булмасаң, башыңа басалар», – дидем ачуымны көчкә тыеп. «Мәчеткә идән юарга кер, «лентяйка» белән түгел, бөгелеп ю. Горурлыгың бетәр, иншаллаһ...» – диде әби мине ишетмәгәндәй. Аннан көйликөйли дога укырга керешге.

Авыр хисләр белән ак төстәге «Ауди»ыма чыгып утырдым.

Шәһәрнең иң затлы кибетләрендә генә киенүче, матурлык салоннарыннан кайтып кермәүче Гөлназ Гаффаровна иелә-бөгелә мәчет идәнен юа... Шушы күренеш юл буе күз алдымнан китмәде. Көләсем дә, елыйсым да килде. Өйгә кайткач, кая барганымны, нишләп йөргәнемне иремә сөйләмәдем. Кычкырып көләр дип курыктым.

Авыр уйлар белән йокларга яттым. Шул төнне төш күрәм. Кулымда сабый бала, имеш. Ир бала! Минем балам! Имезәм, имеш... Ана булу рәхәтенең сүз белән әйтеп, аңлатып та булмаганын тойдым шул вакытта. Балам... Ап-ак битле, сусыл иренле улым... Үзем сабыемны имезәм, үзем кабатлыйм: «Минеке! Минем улым... Йөрәк җимешем, балакаем...» Уянып киттем. Аһ, төш кенә булган бит ул! Йөрәк әрнеп кысылды... Балам, дип, мендәр кочаклап ятам икән. Каткан җанымнан таш эретердәй кайнар яшем мендәргә тамды...

Иртә белән сәгать уннарда машинама утырып якындагы мәчеткә юнәлдем. Без яшәгән коттеджлар бистәсендә мәчет юк. Иң якындагысы – шәһәр читендәге кечкенәрәк кенә, ак кирпечтән төзелгәне. Бу мәчеткә соңгы тапкыр ураза вакытында – ишек янындагы тартмага акча салырга дип туктаган идем.

Мин барып кергәндә мәчет эчендә кеше юк иде. Үзем белән алып килгән ак яулыгымны чөеп кенә бәйләдем дә, түргә уздым. Ир-атлар намаз укый торган зур залга ук кердем. Хозурланып, башны әйләндерерлек түшәмнәрне карый башладым. Күңелгә ниндидер тынычлык, рәхәтлек инде... Шул вакыт тәрәзә төпләрендәге гөлләргә су сибеп йөрүче ак сакаллы, бәләкәй буйлы бабайга күзем төште. Мин монда үзем генә түгел икән... Ул мине күреп алды да, сулы савытын читкә куеп, яныма килде. «Әссәламегаләйкем, кызым. Әйдә, түрдән уз, балакаем. Дога кылдырырга килдеңме?» – диде ул. Ни дияргә белмичә аптырап калдым. Нәрсәгә килгәнемне белми идем әле... Сумкамны ачып, акча янчыгымны эзләп таптым. Анда берничә банк картасы гына – акчам да юк икән...

Бабай дога кылдырырга керүчеләр өчен куелган махсус өстәл янына барып утырды.

«Юк, бабай, кызыксынып кына кердем, янымда акчам юк», – дидем оятымнан кызарып. Аның исе дә китмәде: «Ярар, балакаем, гаеп эш түгел. Килеп дөрес эшләгәнсең. Шөкер, мәчетләргә яшьләр дә тартыла хәзер. Октябрьдән Коръән уку курслары да башланачак. Әле июль генә бит, мәчетебездә шуңа халык аз. Кем авылда, кем дачада... Җыештыручы остабикәбез авырып киткән менә. Инде өч атна мәчет идәннәре юылмаган, тузан басты. Хәзрәт кеше эзли инде. Хезмәт хакы да түли ул, аена биш мең. Мәчет җыештыруның савабы зур бит, аны язып та, сөйләп тә бетергесез. Аякларым авыртмаса, үзем дә рәхәтләнеп юар идем идәнне...»

Күкләрдән иңгән бер билге иде бу! Күз алдымнан соңгы тәүлектә булган вакыйгалар бер-бер артлы тезелеп узды: сукыр әби, төшемдә күргән сабыем... Ә хәзер ак сакаллы бабай мәчеткә җыештыручы эзләүләрен сөйли! Мин бит акылсыз хатын түгел – Аллаһы Тәгалә бирегә мине үзе китергәнен генә аңлыйм. Димәк, бу аның тагын бер мөмкинлек юллавы!

– Бабай, кайда чиләкләр? Үзем юам! Швабра да кирәк түгел, тезләнеп кенә юам. Зинһар, каршы килмәгез!

Бабай минем затлы ап-ак костюмыма, кып-кызыл итеп буялган тырнакларыма сәерсенеп карады: «Кызым, Алланың рәхмәтләре яусын! Тик ак киемнәрең пычраныр бит, өйгә кайтып алыштырып килмисеңме соң?»

Минем һаман тораташ кебек катып басып торуымны күреп, бабай тәһарәт бүлмәсендәге шкафның ишеген ачты. «И-и балакаем, җыештыручының эш киеме монда икән бит. Менә моны кия аласың», – дип, ул миңа еш юудан төсләре уңып беткән халат сузды. Ак костюмым өстеннән шул халатны киеп тә куйдым. Ул арада бабай краннан чиләккә су агызды.

Ике теземә тезләнгән килеш мәчетнең идәннәрен, баскычларын юып чыгардым. Тәрәзә төпләрен, шкаф өсләрен сөрттем. Тәһарәт бүлмәсе идәнен ышкый-ышкый юганда ай буе үстергән тырнагым шартлап сынып чыкты. Нигәдер борчылмадым...

Өйдә юып алып килермен дип, мәчеттәге барлык сөлгеләрне җыеп алдым. Арыган, әмма әйтеп булмаслык шатлыклы хисләр белән өйгә кайтырга чыктым. Күңелемдә ниндидер гаҗәеп җиңеллек тойдым. Бабай миңа зур рәхмәтләр әйтеп озатып калды.

Шул көннән башлап атна саен мәчеткә йөри торган булдым. Тәрәзә пәрдәләрен алмаштырдым, яңа сөлгеләр элдем. Мәчеткә бару минем өчен зур юаныч, күңел бушлыгыннан бер дәва иде.

Октябрь башында исә Коръән уку курсларына язылдым. Дини кешеләр белән аралашу мине шактый үзгәртте. Дөньяга башка күзлектән карый башладым димме... Ирем боларның берсенә дә каршы килмәде. Шулай итеп, әкренләп намазга бастым. Мәчетнең чыгымнарын да үз кулыма алдым: утка-суга бурычлары булган икән – аларны түләдем.

Әйе, ислам дине кешене үзгәртә. Дөньяга карашларны гына түгел. Гардеробымны да тулысы белән алмаштырдым. Озын тырнаклар да йөртмим, буямыйм да. Миндә булган үзгәрешләрне, әлбәттә, якын-тирәдәгеләр дә сизде. Башта гаҗәпләнеп карадылар, аннан ияләштеләр. Ә ана булу теләге мине ташламады. Иртәнге, төнге намазларны укыганда елый-елый гел бала сорадым.

Дингә килүемә ике ел дигәндә булды ул могҗиза! Беркөнне иртән уянып киткәч күңел болгануын сиздем. Күпме генә уйласам да, сәбәбен тапмадым. Бу хәл берничә көн дәвам итте. Аннан хәлсезлек чолгап алды: гел ятасым, йоклыйсым гына килә. Авырып киттем дип уйладым... Ирем иртән дә, кич тә өзми-куймый: «Болай булмый. Сузма, табибка бар!» – дип кабатлады.

– Котларгамы соң сезне, әллә җәлләргәме? Балага узгансыз! – диде миңа табиб.

Ул минуттагы халәтемне сөйләп тә, аңлатып та бетереп булмас... «Котларга! Котларга!» – дип табибны кочаклап ук алдым, ә битем буйлап шатлык яшьләре акты да акты...

Улым дөньяга сау-сәламәт булып туды. Исемен Ислам дип куштык. Сабый безнең гаилә тормышыбызга чын-чынлап олы бәхет алып килде. Хәзер улыбызга 5 яшь. Аны ислам кануннары буенча тәрбияләргә тырышабыз. Инде безгә ияреп намаз укыган була, кайбер догаларны яттан белә...

«Максатым – теләсә кайсы халыкара ярышларда ышанычлы, лаеклы чыгыш ясау. Минем Россия данын яклыйсы килә. Иң мөһиме – программаны чиста башкарып чыгу. Калганы хөкемдарлар эше, алар билге куя.



Камила ВӘЛИЕВА, Россия фигуристкасы, юниорлар арасында Дөнья чемпионы, Сочида дөнья рекорды куеп алтын медаль яулаган 15 яшьлек Казан кызы

Шуганда мин баллар турында уйламыйм, программаны ничек тә яхшы башкарасым гына килә. Халыкара ярышларны мин өч сүз белән аңлатыр идем: курку, дулкынлану һәм шатлык.

Финляндиянең Эспоо шәһәрендә узган Finlandia Trophy 2021 «челленджер» сериясе турнирында ике дөнья рекорды куйгач, журналистлар миннән: «Канәгатьме син?» – дип сорады. «Минем үсәр өчен мөмкинлекләрем бар әле», – дип җавап бирдем.

Сочиның «Айсберг» Боз сараендагы кыска программам Кирилл Рихтерның In Memoriam композициясе буенча иде. Үзем йөгерә-сикерә куып тотып, ахырда барыбер ireккә очырган Күбәләк турында ул. Композитор Рихтерның шундый сүзләре бар: «Бу музыка – һәлак булганнар истәлегенә». Мин дә бу программамны үземнең яраткан әбиемә багышладым. 2019 елда арабыздан китте ул...

Юк, юк, мин йолдызлы статуста түгел! Ярышлар – яхшы, әлбәттә. Камилләшергә мөмкинлек бирә алар. Ләкин миңа эшләргә дә эшләргә әле. Ял итәргә вакыт та юк. Ял итәсем килгән чакларда да шөгыльләнергә кирәк. Этем Лева белән уйнарга, биергә яратам. Буш вакыт эләксә менә – рәсем ясар идем! Мин – төрле. Бик шат та була алам. Кайбер көннәрдә алай ук булып чыкмый... Кайчандыр психолог булырга укырмын дип йөри идем. Берара тимераякта узышучыларның Халыкара судьясы буласым килде... Тәүге тапкыр тимераякка баскач беренче әйткән сүзем нинди иде, беләсезме? «Олимпия чемпионы буласым килә!» – дидем мин! *(Көлеп җибәрә.)* **Һәм шуннан бирле инде бернәрсә дә үзгәрмәде.**

Камила Вәлиеваның төрле чыганаклардагы җаваплары файдаланылды.
Фото: @kamilavalieva.team

НИКАХ



Илнар хәзрәт
ЗИННӘТУЛЛИН,
«Туган авылым»
мәчете
имам-хатыйбы

? Мәһәр бирелмәгән булса, никах дөрес дип саналамы?

– Никахның үзенең шартлары бар. Аның төп шарты – ике якның шушы никахка риза булуы. Кыз да, егет тә риза булса гына никах дөрес дип санала. Динебез белән якыннан таныш булмаган кешеләрдә: «Исламда кызның ризалыгыннан башка да кияүгә бирү бар», – дигән бер хорафат яши. Алар тирәнтен ялгыша. Шәригать буенча, кыз ризалыгыннан башка укылган никах берничек тә дөрес саналмый. Егет моңа каршы булса – шулай ук. Кызның әтисе генә риза булып, кыз үзе каршы төшсә дә, Аллаһы Тәгалә каршында бу никах шулай ук дөрес дип саналмый. Әйткәнемчә, никахның төп шарты – ризалык. Шушы ризалыкка өстәлә торган кайбер шартлар да бар, шуларның берсе – мәһәр бирү. Мәһәр – кыз ягыннан, аның әтисе тарафыннан алдан сөйләшенеп билгеләнгән кыйммәтле бер бүләк. Матди кыйммәте булган, сатып алына торган әйбер турында сүз бара. Бу – акча да булырга мөмкин, ювелир эшләнмәләр дә, затлы кием-салым да... Аның уртача бәясе шәригать буенча 500–600 мең тирәсе килеп чыга. Пәйгамбәребез вакытындагы акчалар белән исәпләгәндә бу. Шуңа күрә бүгенге кияүләр кәләшләренә бирә торган мәһәр бик кечкенә ул. 10–15 мең сумга алган бүләк – символик бер бүләк кенә. Ләкин шулай булса да, ул мәһәрлек төшенчәсенә туры килә.

Мәһәрнең иң кечкенәсе – тимер йөзек булырга мөмкин. Әгәр бәясе аннан да кимрәк икән, ул инде мәһәр дип саналмый. Ләкин элек тимер йөзек тә кыйммәт йөргән – бүгенге акча белән 4–5 мең тирәсе торган. Бүген бездә дә, шәригать буенча, мәһәр кимендә шул бәя булырга тиеш дип билгеләнгән. Уртачасы, әйткәнемчә, 500–600 мең тирәсе тора. Максималь бәясенең исә чиге юк: кыз никадәр сорый – шуның кадәр була ала. Һәм егет, мөмкинлеге бар икән, ризалашып, моны бирергә тиеш. Риза булмаса: «Бу кадәр мәһәрне түли алмыйм, әйдә, кимет», – дип әйтергә мөмкин. Кыз ягы киметергә ризалашмаса, егет өйләнә алмый. Егет: «Мин сиңа соңрак бирәм», – дип әйтә ала: мәһәрне берьюлы түгел, ә тора-бара, әкренләп – аз-азлап түләргә дә тәкъдим итүе мөмкин. Бер ел, ике ел яки ун ел эчендә. Бу очракта әлеге шартка, ягъни рассрочкага инде кызның әтисенең ризалыгы кирәк булачак.

Әгәр дә өйләнешкән вакытта мәһәр билгеләнмәгән булса, кыз соңыннан: «Син миңа мәһәр бир», – дип, үзе әйтергә мөмкин. Бу вакытта уртача мәһәр генә бирелергә тиеш. Монда инде кыз: «Миңа шуның кадәр мәһәр бир», – дип билгели алмый. Әгәр совет чорында – мәһәрнең ни икәнен дә белмәгән заманда өйләнешкән парлар булса, ир кеше аны хәзер булса да бирергә тиеш. Мәһәр – аның өстендәге бурыч булып санала. Әгәр ир кеше мәһәрне бирмичә үлеп китсә, аның малыннан башта шушы мәһәр түләнә. Аннан соң гына аның мирас малы туганнар, якыннар арасында бүленә.

? Хисләрне яңарту өчен генә кабат никах укыту ярыймы?

– Никах – ул искерә торган әйбер түгел. Никах яңарту дигән әйбер шәригатьтә, гомумән, юк. Ләкин кайбер парлар никахларын яңарталар. Никах укытуның бернинди зыяны юк. Гөнаһысы да юк. Бу очракта мәһәр бирү мәҗбүри була алмый. Ул – символик рәвештә генә уза торган чара. Шуңа күрә ир кеше теләсә – бүләк бирә, теләмәсә – юк: монда инде барысы да аның үзеннән генә тора.

? Ир-ат исерек килеш хатынына «талак» дисә, ә соңыннан моны үзе хәтерләмәсә, аларның никахы юкка чыккан дип саналамы?

– Аллаһы Тәгалә үзе рөхсәт иткән гамәлләрнең иң яратмаганы – талак мәсьәләсе. Ул – аерылышу дигәнне аңлата. Гаилә бәхетле булсын өчен мәхәббәт һәм бер-береңә ихтирам кирәк, ә аларны саклау ир белән хатынның үз кулында.

Гадәттә, исерек кешенең әйткән сүзләре, төзегән килешүләре шәригать буенча дөрес дип саналмый. Монда барысы да казыйдан тора – ул ничек хәл итә. Әгәр ир-ат бик еш эчеп йөрсә һәм эчкән саен бу сүзләрне кабатлый торган булса, казый аларны аерылу сүзе итеп тә танырга мөмкин. Әмма ир әллә нигә бер генә исергән, һәм шул вакыт аның теленнән бу сүзләр ычкынган икән, казый аларны игътибарга алмаска да мөмкин. «Талак» сүзен ачу килгәндә генә түгел, уйнап-шаярып та әйтергә ярамый. Хәрефләрне бутап, әйтик, «калак» урынына «талак» дигән очракта та ир белән хатын инде аерылган булып санала. Син инде хатыныңны тәүбә итеп тә, сәдака биреп тә кире кайтарып ала алмыйсың. Ул хәзер чит-ят иргә кияүгә чыгарга тиеш һәм аннан аерылып кайтса гына, аңа кире өйләнергә мөмкин.

Шәригать буенча, шушы сүзне әйтеп булганын туксанынчы елларда күп кенә ирләр белеп алды бездә. «Карале, шушылай дип әйтсәң, хатын аерылган дип санала икән бит», – дип, уйнап кына хатыннарына бу сүзне әйттеләр дә. Алар инде Аллаһы Тәгалә каршында ир белән хатын түгел. Кайчак мәчеткә киләләр дә: «Ачулы чагым иде, хатынга өч тапкыр «талак», дип әйттем, хәзер нишләргә?» – диләр. Менә ни өчен ачу чыкканда да дәшми тору хәерлерәк. Ачу узар ул, ә аралар инде өзелгән булыр... Шайтан коткысына бирелеп, «талак» дигән хәтәр сүзне кабатламаска гына тырышырга кирәк.

PRESSA



АРКАИМ КОЯШЫ



Гөлүсә ЗАКИРОВА

Аркаим турында ишеткән бар иде. Моннан берничә ел элек шагыйрә Луиза Янсуар Аркаимга барып кайтуы турында «Ялкын» журналында шактый кимәлле язма бастырды. Луизаның шагыйранә теленә, фәлсәфи чагыштыруларына, эзотерик һәм мистик фикерләренә сокланып, бу географик ноктаны күңелгә салып куйганым хәтердә... Ничә елдан соң, дусларның Аркаимга барыйк дигән тәкъдимен ишетүгә үк, капылт Луиза язмасы искә төште. Үзенә шалтыратып төпченәм: «Әйт әле, барырлыкмы?» Телефонның аргы очыннан: «Һичшиксез!» – дигән җавап ишетәм. Озак та үтми без инде машинада. Биштәрдә иң кирәкле дип тапкан әйберләрдән: плед, термос белән үлән чәе һәм... яхшы кәеф. Тәгәрмәчләрнең ташка кагылып киткән тавышын көй итеп, «Мураками»га кушылабыз: бу – безнең ноленче километр, хисап Казаннан башлана...

Яраткан сатиригым Михаил Задорнов Аркаимны: **«Кояш сагында торучылар иле», –** дип атаган иде.

1200 чакрым уй

Юлның ерак булуы куркытмый. Кызык чакрымнар: Башкортстанның Урал тауларына сәлам биреп, Уфа һәм Магнитогорск калаларына да сугылырга була. Беренче тукталышта ук шаккатмалы хәл: юл читендә «Верь в себя!» – «Үзеңә ышан!» дигән язу күреп, «аһ» итәбез. Мистика!

Ә күңел барыбер күбрәк уйларга бирелә. Әллә кая – тамырларга сөйрәп төшә... Матур гына тау югыйсә, ә юк – барыбер эчтән кино кебек кадрлар алмашына: репрессия елларында атып үтерелгән бабамның сөргенгә җибәрелгән дәвамчылары шушы таулар аша узгандыр, юлда вафат булган нәни баласын менә бу далада җирләгәндер... Менә шушы очсыз-кырыйсыз далада тир түккәндер, шушындый эсселектә, әлсерәп, яшәү өчен көрәшкәндер... Фәүзия Бәйрәмованың «Кырык сырт» әсәре күңелдә яңара. Уйлар йөгәнен бушатып, меңнән артык чакрымны узу сизелми дә калган. Әйе, Чиләбе өлкәсенең Кизил районына кергән Аркаимга бару рәхәт бер сәяхәт кенә инде ул хәзер. Ара-тирә ат көтүләре очрап куя. Атлар яратуымны үзләре дә белә, ахры, курыкмыйлар: юл читендә кайберләре белән «селфи» ясарга да өлгердек.

«Бу бит – Аркаим!»

Бу төбәкләрдә «аһ» итәрлек биек таулар да, фотога төшәрлек супер фоннар да күренми. Гадәти дала, аның таулары да Азнакайның Чатыр тавыннан биегрәк түгел. Тик кеше өзелми Аркаимнан. Без очраткан бер пар Якутиядән хәтле килгән. Һәркемнең үз максаты, үз кызыксынуы...

Мин үзем тау башына менеп, вак ташлардан кемнәрдер тезгән спираль буенча йөри торганнар рәтендә түгел. Әйе, чит-ят җир сулышын тою кызык, яшәү рәвешләрен барлау, тарихы белән кызыксыну да бар. Монда энергетика башка. Килеп җитүгә үк, алдан заказ биреп куелган йорт ачкычын алырга иде исәп. Дөрес, бушлай палатка корып та, символик бәягә иске вагоннарда яшәп тә була. Лакшери яшәү фанаты булганнарга нарат бүрәнәләрдән күтәрелгән балконлы агач йортлар, шундый ук мунча да бар. Ә безгә Караганка елгасы ярындагы теремок-йорт та ярап куйды. (Зуррак төркем белән килгән булсак, һичшиксез, янәшәдәге киез тирмәне сайлаган булыр идек. Ә палаткадан шикләндек, чөнки еланнардан куркам – Аркаимда алар җитәрлек, диделәр...) Йорт ачкычын бирүче егет, башка урыннардагы кебек, ул ярамый, бу ярамый, дип аңлатып тормады. Бәдрәф урамда, диде. Безнең авылның югары очыннан түбән очына төшкән хәтле генә икән дип, кул хәрәкәтләрен күзәтеп тордык. Юынгычлар да урамда: әнә теге Караганка елгасы ярында. Бәхеткә, суы чишмәдән икән, чәй эчәргә дә шуннан аласы, имеш... Машинада бер савыт су бар иде, моңа да һич тә пошынмадык. Ә ачкычны ничек кайтарасы, дибез, ике көннән иртәнге кояш чыкканчы ук китәсебезне искә төшереп. Ә ул елмая... «Ишектә калсын», – ди. Аннан безнең күзләребез маңгайга менә башлаганны сизеп, болай дип өсти: «Бу бит – Аркаим!»

«Бу бит – Аркаим!» төшенчәсен бер генә ишетмәдек. Лагерь биләмәсендә, елга ярларында кечерәк кенә киоск сыман сату нокталары тезелешкән. Кайсына кермә: тематик сату әйберләре. Кайдадыр ташлар саталар, кайдадыр – кулоннар, кул эшләнмәләре, китаплар, махсус чигүле киемнәр (мин дә башыма яулык алып яптым, озын күлмәк кидем. Хатын-кыз озын күлмәк кияргә тиеш: җир энергиясе аның хатын-кызлыгын исенә төшерә. Югыйсә без ирләр булып беттек: өйдә дә, эштә дә кайчак ирләр тарта алмастай йөк тартабыз). Менә шул кибетләрнең күбесендә сатучыларның һәр тауарга ябышып ятмаганын күреп тә сокландык. Кеше әйберенә тию – гөнаһ, бу бит – Аркаим!

Кояш сагында

Иртән таң сызыгы беленгәнче үк без инде аякта: кояш нурларын каршы алырга исәп. Безнең ише хыялыйлар җитәрлек: кемдер ташлардан ясалган спираль буенча яланаяк йөри, кемдер намаз укый, кемдер – тирән медитациядә, кемдер төньяк халыкларының музыка коралын – варганны чиртә...

Тирә-якта – иксез-чиксез дала. Тау башыннан аеруча ачык күренә – офыкта берәр машина (йә турист инде ул, йә күрше авылда гомер кичерүче казакъ агае) килүен тузан өере буенча чамаларга мөмкин. Дөрес, бу якларда ком бураннары да еш кунак. Аеруча ниндидер фестиваль үткәрергә җыелышсалар, берничә көннән өермә күтәрелә дә эзләрне юып ала ди... Быелгы кояш торгынлыгыннан соң да булган. (Ә ул көнгә илнең кайсы гына почмагыннан килми дзынь ноктасы эзләп йөрүчеләр?!) Хәер, пандемия дә үз төзәтмәләрен керткән: алдагы еллардагы кебек, шаулап-гөрләп фестиваль, җыеннар үткәрүләр биредә дә кимегән.

Туристлар исә берничә төргә бүленә: турагентлыклар аша автобуска төяләп килүчеләр – боларның «продвинутый» гидлары була, аның артыннан бер таудан икенчесенә күчеп, ул күрсәткән гамәлләрне үтәп (кәгазьдән ниндидер «мантра»лар, догалар уку, медитация ясау), ашханәдә әзерне ашап, алдан түләп куелган мастер-классларда катнашып йөрүчеләр. Икенчеләре – ялгызлар. Алар бөтенләй диярлек үз дөньяларында: башкаларны күрми дә, ишетми дә. Авыз эченнән дога, «мантра» кабатлап, башкалар аңламаган сәер киемнән булырлар... Өченчеләре – галим-голәмәләр. Аларны бу төбәкнең тарихы җәлеп итсә, безнең ише каләм ияләренә археология генә түгел, килгән-киткәннәр, бүген барган вакыйгалар да кызык.

Әнә кояш күренде... Офык пәрдәсен нәфис нурлары белән генә

> Хатын-кыз озын күлмәк кияргә тиеш: җир энергиясе аның хатын-кызлыгын исенә төшерә.



■ Аркаим спиральләре. Алар буйлап яланаяк узсаң, үз нәсел агачың белән берләшергә, гөнаһлардан арынырга була дип санала.



ачты да безне сәламләде. Үзен зарыгып көткәнне чамалап, бәясен белгән артист сыман... Кояш белән тәнгә җылы йөгерде. Пледка уралып, салкын һаваны үләнле чәй йотымы белән генә җылыту түгел инде бу. Яраткан сатиригым Михаил Задорнов төшергән фильм искә төшә, Аркаимны ул: «Кояш сагында торучылар иле», – дип атаган иде. (Интернетта бар, сезгә дә карарга киңәш итәм.)

Стоунхенджмы, Мисырмы?

Ә бит әле утыз ел элек кенә бу тирәдәге болыннарда көтү көткәннәр. Очсыз-кырыйсыз дала һәм анда-санда – совет чорында чирәм җирләрен торгызырга килгән казакъ, башкорт, татар авыллары... (Тамырлар дәшә дигәнем юктан гына түгел: заманында Чиләбе өлкәсендә минем әти дә чирәм җирләре күтәрүдә катнашкан.)

Туксанынчы елларда хөкүмәт, Зур Караганка елгасын буып, авыл хуҗалыгы өчен бик тә кирәкле булган сусаклагыч төзү турында карар кабул итә. Хәстәренә дә керешәләр, зур-зур тракторлар килеп, буасын күтәреп тә куя. Ләкин закон буенча, иң элек галимнәр су астында каласы җирләрне тикшерергә тиеш була: файдалы казылмалар калмыймы? Кирәк бит: Чиләбе институты укытучыларына ияреп килгән берничә студент һәм мәктәп укучысы – экспедиция урнашкан лагерьдан бер-ике чакрым ераклыкта гына батынкы җирләре булган кызыклы урынга тап була. Шуннан – шул: сусаклагыч төзү эшен туктатып, бу урынны өйрәнү өчен археологларга бер ел вакыт бирәләр. Бәхеткә, дөньякүләм ачыш булырлык табышларга юлыгалар: биредә моннан 4800 ел элек Синташта культурасына караган халык яшәгән икән бит! Бу цивилизацияне борынгы арийлар белән бәйләп аңлатучылар да, Англиядәге мәгълүм Стоунхендж белән уртаклык табучылар да, борынгы Мисыр фәлсәфәсенә туры килә диючеләр дә була. Якындагы тау исеменнән чыгып, бу географик ноктаны Аркаим дип атый башлыйлар. Хәзерге вакытта ул – берничә гектар мәйданга сузылган тыюлык.

Уникенче ДНК

Гид кыз Юлияга ияреп, археологик казылмалар барган урынга атлыйбыз. Экскурсиянең төгәл вакыты юк, биш-алты кешелек төркем җыелуга, җәяү юлга кузгаласың. Бер кешегә 400 сум, шул ике-өч сәгать эчендә әлеге цивилизация, аларның яшәү рәвешләре, бу төбәктә яшәгән җан ияләре, климат үзенчәлекләре турында саллы гына мәгълүмат алырга була. Гомумән, тыюлыкта эшләүчеләр мистикага ышанмый, «көч алу урыны» дип килүчеләргә битараф һәм... бәхеткә, тарихны ярыйсы гына белә булып чыкты. Юлия да галимнәрнең тикшеренү эшләрен үз күзе белән күргән, кайберсендә хәтта катнашканда. Казыну эшләре барган урында ниләр табылуы хакында да, географик урнашуын да тәфсилләп сөйләде, күрсәтте. Мандала формасында булуын үзебез дә күреп ышандык. Вертолеттан ул бигрәк тә төгәл күренеп тора икән. Остазым – археолог Петр Старостин, рухы шат булсын, дәресләрендә биргән гыйлемнәрне ярап куйды.

Аркаим цивилизациясенең үзенчәлеге шунда: нибары ике йөз ел гына яшәгән халык, барлык сугыш кораллары булуга карамастан, бер тапкыр да сугышта катнашмый. Металл кою технологиясен дә белә! Савыт-сабалар да ясый. Гыйлем ияләре санала: язма мирас булмаган дәвердә дә сөйләм культурасы аша аң-белемгә ирешәләр. Аларның йорт-җирләрен кору технологиясе буенча да Галәм системасын укырга була... Ике йөз еллап гомер иткәннән соң, алар бу җирләрне яндырып, Алтайга юл тота. Бүген Аркаимны өйрәнүче галимнәр төркеме дә бар: аларның ачышлары күпләрне таң калдыра. Әле монда өйрәнәсе мәгълүмат җир асты тулы. Чөнки археологлар җирнең бер өлешен генә ачкан, кагыйдәләр буенча, бер кагылган урынга кабат


күрәк төртергә ярамый, шуңа да киләсе буынга казыну урыннары җитәрлек... Археологик табылдыклар да җирле музейның бер бүлмәсен алып тора: аларны өйрәнеп, һәркайсына номер куярга гына да берничә ел кирәк булачак!

Ләкин сусаклагыч төзергә алынучылар да бирешергә уйламый: авыл хуҗалыгы өчен су сугару кирәк! Ул чакта Чиләбе дәүләт университетының тарих һәм этнография кафедрасы җитәкчесе Геннадий Зданов Мәскәүгә юл тота. Авыр сәфәр: дәүләт сәясәтенә тыкшынган өчен эшеннән дә алып ташларга мөмкиннәр. Галимне Эрмитаж музее директоры Михаил Пиатровский яклап чыга. Аркаимга алар астролог Тамара Глоба белән кайтып төшәләр. Глоба гадәти булмаган урын икәнен әйтә. Шаманнар чакыралар, уфологлар... Барысы да Аркаимның энергетик нокта икәнен раслый. Урманында кәтүе белән өрәкләр йөри, төнлә керсәң, башың китүе дә мөмкин, ди... Тау башына НЛО да төшә икән әле. Тауларның берсендә уникенче ДНК тәртипкә салына, ә икенчесендә өченче күз ачыла икән... Ничек кенә булмасын, нәтиҗәсе шул: күп миллионлы сусаклагыч төзелешен фән өчен туктаталар! Галимнәребезнең зирәклегенә шаккатмалы!

Синташта культурасына караган бөек цивилизация өйрәнелергә һәм гыйбрәт булырлык тарихы белән горурлык казанырга тиеш!



■ Теләкләр агачы. Төсле чүпрәкләрдә төрле илләрдән килгән төрле теләкләр җилферди.



■ Рәссам Юлия Выголованың кыйммәтле картиналарының берсе.



■ Шаман Андрей Сереба.

Шаманнар да – кеше

Хәзер инде Аркаимны эзотериклар да үз иткән. Агачларга төсле тасмалар тагып китүчеләр дә, Караганка күлендә су коенып, яңадан «туучылар» да, тау башында кара тавык суючылар да бар. Сату-алу нокталары арасында тирмә-клуб та эшли. 300–400 сумга тамаша да карарга була (фестиваль-бәйрәм вакытларында мондый чаралар урамда бушлай үтә, билгеле). Безгә Казаннан (!) килгән Ильясның (исеме генә татар инде аның, сакал баскан чыраена карасаң, Һиндстаннан килгән буддист дип уйларсың) чәшкеләрдә һәм варганда уйнавын тыңларга насыйп булды. Тирмәдә акустика искиткеч! Караңгыда шәм утлары гына янып тора, ә без идәнгә сузылып ятып, гадәти булмаган уен кораллары яңгырашын тыңлап рухланабыз. Уралдан килгән шаман Андрей Сереба белән дә күрештек, озак кына сөйләшеп утырдык. Шөлдерле барабанын каккалап, шаман йолалары да үткәрде, алары да күрше малайның кәстрүл кагып йөргәненнән артык булмады. Шаманнар да гадәти кеше икән...

Инстаграмда инде күптән дуслашкан рәссам Юлия Выголова остаханәсенә дә сугылдык. (Тагын бер Юля: мистика бу!) Ул җәйне биредә үткәрә, мастер-класслар уздыра, картиналар ясый һәм аларны яхшы гына бәядән сатып та җибәрә. 25–40 мең сумга бәяләнгән картиналары да бар иде аның. Һәрберсе үз ияләрен таба тора тагын. Чөнки Юлиянең картиналары үзенчәлекле: Аркаим һәм аның рухлары белән бәйле әсәрләр иҗат итә ул. Инде Таро карталары да ясый башлаган. Анысын да алалар! Юлия миңа да бер открыткасын бүләк итте, бергәләп фотога төштек. Үз урынын һәм бизнесын тапкан кызга сокландым. Аның кебекләр шактый монда: кемдер аураны фотога төшерә, кемдер ташлардан амулетлар ясап сата, кемдер борынгы арийлар киемнәрен тегә: чигешләре күз явын алырлык, чын сәнгать әсәре! Борынгылыкны яңарту йолалары да бар, галимнәр белән бергә борынгы дәверләрдәге кебек, металл коеп караучылар да җитәрлек...

Теге чакта сусаклагыч булдырырга теләгән казакълар белән очраштык. Көтү-көтү малларыннан баш тартканнар (тыюлыкта көтү көтәргә ярамый!), әмма беркая да күченеп китмәгән үзләре, җайлашканнар гына. Аттан машинага төшеп утырганнар. Хәзер аларның казакъча итеп эшләнгән ашханәләре әйбәт кенә табыш китерә. Ничә чакрымны җилдертеп кенә кымызын да алып киләләр, казакъча итеп шурпалар да пешерәләр. Суган пирожкиен без дә авыз итеп карадык, авызда эри дә китә. Менә шулай: бүреләр дә тук, сарыклар да исән...

Аркаим минем өчен дә ачыш булды. Мин аны үземчә ачтым бугай...

«АНСЫЗ МИН ЯШИ АЛМЫЙМ ИКӘН...»



Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк Галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

Гамил ӘСХӘДУЛЛА, артист, «Мунча ташы» татар эстрадасы театрының сәнгать җитәкчесе, Татарстанның халык артисты; гаилә стажы – 19 ел; дүрт бала әтисе.

1 Иң элек хатын-кызның сез нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Яшь чакта нәкъ менә шушыларга – тышкы кыяфәткә игътибар ителгәндер. 22 яшь иде беренче тапкыр өйләнгәндә. Ул чакта кеше башкача уйлый иде әле. Армиядән кайтуга, әниләр: «Кайчан өйләнәсең?» – диделәр. Шулай тиеш кебек иде. Йөргән кызлар бар иде инде – арадан берсен сайладым... Хатын-кызга хөрмәтем яшьтән үк зур булды, чөнки без биш ир бала үстек. Хатын-кызга әнкәйгә ышанган кебек ышандым. Бәлки, алай кирәк тә булмагандыр, чөнки алар гади генә зат түгел... Яши-яши әкрен генә аңлыйсың – акыл ягы да булырга тиеш хатын-кызда. Ә бүген инде мин: «Иң беренче чиратта әти-әнисенә карарга кирәк», – дим. Алар ничек гомер иткән, гомумән, нәселе нинди... Балаларга һәрвакыт әйтә торган тагын бер сүзем бар. «Әгәр йөргән кызың янына эштән кайтышлый керәсең һәм ул синнән: «Чәй эчәсеңме?» – дип сорый икән, бу дөрес түгел», – дим. Эштән кайтканыңны белә, шуңа күрә: «Әйдә, утыр, чәй эч», – диярга тиеш ул сиңа.

2 Нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Мин бу сорауга җавап бирә алмыйм... Икенче тапкыр өйләнүем булгач, хатыным белән очрашканчы ук аңа хыянәт иткән булам түгелме? Дөрес, алай дип карарга да ярамыйдыр, бәлки... Бу сорауга барысы да «хыянәтне», дип әйтәләрдер, билгеле. Ир кеше хыянәтне кичерергә тиеш тә түгелдер. Әмма шундый хәл килеп чыкса, чынбарлыкта барысы башкача да булырга мөмкин. Ир белән хатын аны үзе хәл итә. Ул бит бөтен җирдә кычкырып йөри торган әйбер түгел: читләр аны күп вакыт белми дә кала. Яшиләр бит... Нәрсә генә булса да, өйдән тышка чыгармаска кирәк. Берәү дә изге түгел... Ә инде күрә торып синең күз алдында чыгып китсә, монысы – бөтенләй башка очрак.

3 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр.

– Акыллы хатын өйдә барысын да оештыра: алиһә дә була, комфорт та тудыра. Өендә боларның һәммәсе булса, ир-ат чыгып китми ул: нишләп акча туздырып, шәраб алып, кемнедер сыйлап йөрсен – утыра да хатыны белән бәйрәм итә.

Гомумән, тормыш язылмаган тәртип буенча барырга тиеш. Мәсәлән, мин гастрольгә китәм генә, өйдә лампочка янып чыга. «Әти, кайчан кайтасың, безнең монда шундый хәл», – дип, сиңа шалтырата башлыйлар... Мин һәрдаим гаиләне тоеп яшим. Һәм ышанам! Ышансаң, сиңа бернәрсә дә комачауламый: эшеңне тыныч күңел белән башкарасың. Берәр айга чыгып киткән чаклар бар.

4 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Ничек булмасын инде?! Ул дус, иптәш тә. Сөяркә дә! Аның сиңа кем икәнлегә, беләсезме, кайчан сизелә?! Яңа гына хатын чирләп алды менә. Шөкер, ковид булмады... Кызым белән даруханәгә чаптык. Алсуны югалтканым күз алдыма килә... Кулымның берсе юк шикелле. «Бу баласыз мин яши алмыйм икән бит», – дим. Шулкадәр якын икән...

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Хәтерлим... Алсу – безнең Шәңгәлче авылы кызы. Әнисенең яман чир белән авырып вафат булган чагы... Аңарчы мин Алсуны Казанга, институтка укырга кертергә алып килгән идем. Баянчы ул, музыкант. Ярдәм ул кадәр кирәк тә булмады, укырга җайлы гына үзе кереп китте ул. Шуннан бирле без дус булып калдык. Аның әнисе үлгәндә мин инде ике ел ялгыз идем. «Егетең бармы, Алсу?» – дип сорадым. «Юк», – ди. «Әйдә, бергә яшик», – дим. Үзем өчен дә көтелмәгән тәкъдим булды бу. Валлаһи! Башка өйләнмәм, тормыш шулай үтәр инде дип уйлый идем... Әтисе риза булмас дип курыкты ул. Бабайга: «Күпме яшисемне әйтә алмыйм, әмма мин исән чакта Алсу бәхетле булыр. Ышанасың икән, бирәсең», – дидем. 19 ел торабыз менә – талашканыбыз юк! Бер тапкыр да! Әйткәләшү булгалый. Хатын сабыр, ә мин ярсып китүчән булсам да,

тиз басылам. Бер җизнәм: «Кайнеш, яши башлагач, хатын-кызның барысы да бер калыпка керә аның», – дигән иде. Еллар үткәч: «Синең бу гаиләң бөтенләй икенче», – диде. Беренче хатынымны да начар дия алмыйм. Әмма шулай килеп чыкты менә... Балаларны беркайчан ташламадым – ярдәм итеп яшәдем.

Алсу туйга каршы булды. Ә минем тәҗрибә бар, беләм: балалар, бераз үсүгә: «Әни, синең туй фотоларың кайда?» – дип сораячаклар. Сигез ак «Волга» белән барып алдым мин аны. Алсуга – 27, миңа 43 яшь иде бу вакытта. Авылда өй салып ята идем – шул яңа өйгә алып кайттым. Әле дә шунда яшәп ятабыз.

Ә бабай... «Кызымны бәхетле иттең», – дип әйткәне юк, әмма беләм – ул шулай уйлый. Аның безгә килми калган көне юк. Хатынымның иң якын кешесе ул: бабай килеп елмайса, Алсуның кәефе мең тапкыр күтәрелә. Без – бабай белән дуслар. Тормышыбыз барганга, оныкларга сөенә ул, бу – күңелемә җылылык бирә. Берәр җире авыртса, утыртам да шундук табибларга алып китәм. Беренче хатынның әнисен дә больницада кулымда күтәреп йөргән кеше мин... Алсу да минем туксанны узган әнкәемә шундый ук хөрмәтне күрсәтә: килендәшләре белән аны бергә тәрбияли алар.

6 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Үзебезне күз алдыма китереп карыйм... Юк, хатыным миңа бернәрсә белгертмәс иде. Акча корты түгел ул. Кайчакта аңа акча бирәм, ә ул: «Миңа кирәк түгел әле», – ди... Акчадан баш тарткан хатын-кызны күргәнегез бармы?

Танышларым арасында нәкъ шундый бер гаилә бар. Хатын бик акыллы анда, ирен хөрмәт итә. «Мин алдым, мин эшләдем», – дип ялгыш та әйткәне юк. Алар һәрвакыт: «Без шуны алдык әле», – дип сөйлиләр. Хатынының акчаны күбрәк эшләгәнен миннән башка кеше белмидер дә. Ире балаларны карый, түгәрәкләргә йөртә. Һәм өйдә бөтен стратегик мәсьәләләрне ул хәл итә.

7 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Әйбәт карыйм. Хатын-кыз сине сайлый икән, димәк, ул синдә нәрсәдер күргән, нәрсәдер тойган. Ә мондый гаиләләр бәхетлерәк була. Алсу белән дә шулай килеп чыкты бит – ул мине сайлады. «43 яшьлек бабай миңа нәрсәгә?» – дияргә дә мөмкин иде бит. Мин инде җитлеккән ир-ат идем: төрле ситуациягә җайлаша алам. Тормыш тәҗрибәм бар: кайда туктап торырга, әйтәсе сүзне кайда әйтергә икәнен беләм. Гомер иткәндә бернәрсәне онытырга ярамый: синең янәшәңдә – кемнеңдер иң кадерле кешесе. Аңа авыр сүз әйткәнче, рәнҗеткәнче бу хакта исеңә төшерәсең икән, син ул адымга бармыйсың.

8 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Хатын-кыз чибәрлеккә карамый! Ир кешенең аеклыгы, тормыш алып бара алуы аның өчен мөһимрәк. Минем дә менә кызым үсеп килә. Бераздан аңа да моны аңлатачакмын. Хатын-кызга тормыш итә торган ир кирәк – тик тормый торган. Өйдәгеләрнең диванда ятып торганымны күргәне юк менә. Көчем барда йокламыйм әле, эш исә гел табылып тора. Балаларны да шуңа өйрәтәм: «Әйткәнне көтмичә, үзегез белеп эшләгез», – дим.

Безнең кебек артистларга туры килгән хатын-кызга рәхмәт. Өйдә тормыйбыз. Әмма шунысы рәхәт: гастрольдә йөреп кайту гаиләне яңартып җибәрә. Яңалык төяп кайтасың, дөнья күреп, сагынып... Телефоннан аралашып торсаң да, өйдәгеләрнең дә сиңа сүзләре җыела.

9 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүен көтәсез?

– Мин, киресенчә, игътибар итмәсен иде, дим. Яшемә... «Картая бит бу», – димәсен. Үземне үзем сакларга тырышам: җәяү йөрим, көн дә урманга менеп төшәм... Хатыным өчен генә эшләмим моны, миңа бит балаларны үстереп бетерергә – ятим итмәскә кирәк... Янында үз-үзен караган, ышанычлы ир барса, хатынга да күңелледер дип уйлыйм. Үзеңне яшьрәк тоткан саен, читтән дә күренә икән ул.

10 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Куркыта, чөнки көнләшү барлыкка килергә мөмкин – чибәр хатынга бөтен кешенең күзе төшәчәк. Моңа әле популярлыгы да килеп өстәлсә... Андыйларның ирләренә Алла ярдәм бирсен. Икенче ягы да бар: яныңда чибәр, көчле хатын булганда, син дә бер башка үсәсең. Финалда бу ир бик бәхетле дә булырга мөмкин. Чөнки бүтәннәр кызыгып кына караганда, ул чибәр хатынны син иркәлисең. Хатын-кызның исә барысы да чибәр дә, көчле дә була ала. Ут төртеп – дәртләндереп тә торсаң...

11 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез, ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин арыдым, дип, диванда кырын ятып тора.

– Андый хәлгә очрасам, мөгаен, үзем берәр нәрсә пешерермен. Әле менә дүрт ай буе Казанда яшәп, сериалда төштем – гел үзем әзерләдем. Элек кыярга кадәр яба идем. Белгән эшне эшләп куюның авырлыгы юк аның. Алсу да шулай, ди. Кышка аның күпме әйбер тозлаганын күптән түгел интернетка куйган идем. Банкаларының күплеген күреп: «Иң уңган хатын», – дип яздылар. «Ясама бу кадәр», – дим, хәзер бит күп ашалмый алар.

12 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Нәрсәм юк – хатын миңа шуны бирергә тырыша. Аннан зур бүләк өмет итмим мин. «Син үзең дә ала беләсең, ал», – ди ул. Гастрольгә киткән җирдән яңа костюм алып кайтуыма алар ияләште инде. Аның белән нидер алырга чыксаң, бер проблема бар: сатучыдан бәя төшерүен сорый. Ә халык мине таный, яннарына килеп басуга, исәнләшә... Мин күбрәк үзем кешеләргә сюрприз ясарга яратам шул. Егерме ел инде авылдагы бөтен әбиләргә газета яздырам. Башта алтмышка якын иде алар, хәзер ундүртәү генә калдылар. Тракторым бар: язын бакчаларын сукалыйм, бәрәңге утыртам, көзен алып бирәм. Үз әнием олы яшьтә булгангамы, җәллим мин аларны... Хатынга да сюрпризларны ясаштыргалыйм: иллешәр роза күтәреп кайтып керәм. Кирәкми дисә дә, аннан барыбер күңеле була.

Тулысынча укыгыз »







Күпләр әлеге проблема өлкән кешеләрдә генә була дип уйлый. Ялгышалар. Эч кибү, тышка чыга алмау сабый балаларда да еш очрый. Эче авыртудан бәләкәч елый, көйсезләнә, аппетиты кача... Әлбәттә инде, баланың олы йомышын үти алмавы әти-әниләрне дә хафага сала. Сабыйның хәлен ничек җиңеләйтергә һәм бу бәладан ничек котылырга? Республика балалар клиник хастаханәсенең табиб-гастроэнтерологы Алмазия ШАКИРОВА белән шул хакта сөйләшәбез.

БӘЛӘКӘЧНЕҢ ЭЧЕ КИБӘ

Эч кибү – дефекация араларындагы интервалның озынаюын яки тышка чыгуның авырлашуын, акрынаюын белдерә. Тәрәт озаккарак тоткарланган саен, катылана һәм тыгызлана. Кайчагында баланың эче шуның кадәр кибә, хәтта олы йомышын мөстәкыйль рәвештә йомышлау инде мөмкин дә булмый. Шул рәвешле бер көн, ике көн үтәргә мөмкин. Димәк, эч кибү дигәндә без, беренче чиратта, тышка чыгуның сирәк (атнага ике тапкырдан кимрәк), авыр (нык көчәнергә кирәк, бу вакытта арт юлда авырту сизелә), уңайсыз (тәрәт массасы артык зур, тышка чыкканнан соң да, эчәклек тулысынча бушамаган кебек тоела) булуын күздә тотабыз. Әгәр дә балада шушы билгеләрнең берсе генә булса да, бу инде табибка күренергә кирәклекне белдерә.

1 яшькә кадәрге балаларда дисхезия күзәтелү ихтималын да әйтеп үтәргә кирәк. Ул функциональ тайпылыш санала. Дисхезия күзәтелгәндә дә бала тәрәт итә алмый. Бу оча төбе һәм аналь сфинктер мускуллары арасында координация булмау белән аңлатыла. Сабый көчәнә, көчәнгәндә йөзе кызара, тынычсызлана, елый. Әмма дисхезия вакытында баланың тәрәте һәрвакыт йомшак була. Дисхезия, гадәттә, ике-өч айлык балаларда ешрак күзәтелә, алты айларга ул бетә.

Тәрәтнең озакка тоткарлануы организмның агулануына китерә. Интоксикациянең билгеләре – баланың аппетиты булмау, көйсезләнү, хәлсезлек, битарафлык. Эчәклектә тәрәт ташлары да барлыкка килергә мөмкин.
Шуның аркасында эч күперү, эч авырту, арт юлда җәрәхәт күзәтелеп, баланың тормыш сыйфаты начарлана.

Әти-әниләр колагына

Бәләкәй балаларның йомышлавы үтә дә индивидуаль, ул тәүлеккә җиде тапкыр да, атнага бер генә дә булырга мөмкин. Күкрәк сөте имгән балаларның тәрәте ботка рәвешендә, йомшак, ә ясалма тукландырылган сабыйларның бераз тыгызрак була. 4 яшьтән өлкәнрәк балаларның атнага ике тапкыр тәрәт итүе норма санала.



Сәбәпләре:



- функциональ тайпылышлар (сабыйларда бигрәк тә);
- баланы өстәмә ашата башлау;
- сабыйны кисәк кенә күкрәктән аеру;
- туклandыру режимын үзгәртү;
- баланың рационында углеводларга бай ризыклар өстенлек итү;
- яшелчә, җиләк-җимешләрне аз куллану;
- балага суны җитәрлек күләмдә эчертмәү (аеруча ясалма тукландырылган очракта);
- баланы чүлмәккә артык иртә өйрәтә башлау;
- яңа шартларга адаптация чоры (ясле, балалар бакчасына бирү);
- эчәклектәге массаның чамадан тыш әчүе аркасында анусның рефлектор реакциясе.

Фото: www.pexels.com

БУ МӨҺИМ. Сабыйларның эч кибүе күбесенчә функциональ характерлы. Ләкин сирәк кенә булса да, ул эчәклекнең аномаль үсеше белән бәйле булырга мөмкин. Бер айга кадәрге баланың эче кипсә, тәрәте тасма рәвешендә чыкса, кан булса, баланың физик үсеше тоткарланса, эче күперсә, кичекмәстән табибка күрсәтү мөһим.

ТАБИБ КИҢӘШ ИТӘ. Баланың эче кибү күзәтелсә, иң беренче туклануына игътибар итегез. Ризык төрле булырга тиеш. Баланы пюре, сыек ризыкка гына өйрәтмәгез, рационында таралып тора торган ризыклар да булсын, аны чәйнәп ашый торган ризыкларга күнектерегез. Шулай ук суны җитәрлек күләмдә эчертү дә мөһим. 1 яшькә кадәрге сәламәт балалар өчен суның тәүлек нормасы – кимендә, 100 миллилитр. Сабый өчен уңай мохит булуы да бик мөһим. Әлеге чаралар ярдәм итмәсә, табибка күренергә кирәк. Үзбелдегең белән дәваланырга ярамый. Әле бүген дә күп кенә әти-әниләр әлеге проблемадан иң яхшы дәва дип кер сабынын атый. Ләкин кер сабыны ул – селте. Шуның аркасында арт юлда җәрәхәтләр, эрозияләр барлыкка килергә мөмкин. Монысы инде җитдирәк проблемалар китереп чыгарачак.



ДРКБның матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.



Әлеге проблема күбесенчә өлкән яшьтәге хатын-кызларда күзәтелә. Ир-егетләрдә ул сирәк очрый. Бәвел куыгының гиперактивлыгы дигән диагноз кайчагында яшьләргә дә куела. Кеше тормышын шактый ук катлауландыра торган проблемалардан бу. Тормыш сыйфатын киметеп кенә калмыйча, җитдирәк чирләргә дә китерергә мөмкин. Республика клиник хастаханәсе табибы, нейроуролог Әнвәр ӘМИРОВ белән бәвел куыгының ни өчен артык активлык күрсәтүе турында сөйләшәбез.

АРТЫК АКТИВЛЫК ЗЫЯНЛЫ

Бәвел чыгару системасының төп функциясе – бәвелне туплау һәм чыгарудан гыйбарәт. Әлеге процессны нерв системасы үзе контрольдә тотып, бәвел куыгының эшчәнлеген көйли. Бәвел юллары эшчәнлеге өчен җаваплы нерв структураларының зарарлануы бәвел капчыгының нейроген дисфункциясенә китерә. Бу аның гиперактивлыгы яки, киресенчә, гипоактивлыгы һәм мускулларының кыскару сәләте кимүе рәвешендә булырга мөмкин.

Бәвел куыгының гиперактивлыгы ул – симптомнар җыелмасы. Инфекция яки патологияләр булмаса да, кеше кече йомышка еш кыстала. Бәвел куыгы тулысынча мускулдан гына гыйбарәт булганлыктан, бәдрәфкә бару теләге тууга бәвелне тотып тору кыенлаша. Бик кысталса да, бүленеп чыккан бәвел күләме аз, хәтта берничә тамчы гына да булырга мөмкин. Әлеге чир белән ешрак хатын-кызлар, аеруча кырыктан өлкәнрәк яшьтәгеләр очраша. Авырлы ханымнарда да бәвел куыгының гиперактивлыгы күзәтелә ала. Бу очракта ул физиология белән бәйле.

Бәвел куыгының гиперактивлыгы тормыш сыйфатын шактый киметә. Ерак юлга чыгу, театр-концертларга бару, өйдән чыгып йөрү, чып-чын стресска әверелеп, кешене чикли. Бәвел тотмау аркасында башка төрле күңелсезлекләр дә башлана.

Төгәл диагнозны, әлбәттә, бары тик табиб кына куя ала. Шуның өчен дә иң элек урологка һәм неврологка күренү мөһим. Диагнозны раслар өчен, кан һәм бәвел анализларын тапшырырга кирәк булачак. Бәвелнең гомуми анализыннан тыш, Нечипоренко буенча да проба алына. Шулай ук өч тәүлек дәвамында бәвелнең күләме ачыклана, бәвел юлларына УЗИ ясала. Алынган мәгълүматлар нигезендә дәва чаралары билгеләнә.

Бәвел куыгының гиперактивлыгы башлыча консерватив терапия белән дәвалана. Моңа Кегель методикасы буенча оча төбе мускулларын ныгыту, сидек куыгының мускул тышчасының кыскаруын киметүгә юнәлдерелгән электростимуляция чаралары, дару препаратлары билгеләү керә. Аның нәтиҗәсе булмаган очракта, хирургия ысулы билгеләнергә мөмкин.

Сәбәпләре:
- цереброваскуляр чирләр (инсульт);
- нерв системасындагы тайпылышлар;
- Альцгеймер, Паркинсон авырулары;
- арка мие зарарлану (бүсер, шеш);
- диабет;
- организмда гормональ үзгәрешләр.

Билгеләре:
- кече йомышка еш кысталу (көн дәвамында тугыз тапкырдан күбрәк);
- бәвел куыгы буш булса да, аны тулы итеп тою;
- бик кысталганда да бәвелнең күләме аз булу;
- бәвел тотмау;
- төнлә бәдрәфкә йөрү.

Барлык рекомендацияләрне дәвалаучы табиб белән киңәшләшеп үтәгез.

БУ МӨҺИМ. Бәвел куыгының гиперактивлыгы күзәтелгәндә төп фактор дип, куык эчендәге басымны атыйлар. Бу исә бәвел куыгының рефлюксына китерә. Ә анысы, үз чиратында, хроник пиелонефрит башлану куркынычын тудыра.



ТАБИБ КИҢӘШ ИТӘ
- Каты итеп ясалган чәй һәм кофе, газлы сулардан баш тарту. Әлеге эчемлекләр сидек юлларына ярсыткыч тәэсир итә.
- Төнлә бәдрәфкә уяну күзәтелгәндә, йоклар алдыннан өч сәгать кала сыеклык эчүне туктатырга.
- Артык авырлыктан арыну да бәвел куыгының гиперактивлыгын киметергә булыша.



Республика клиник хастаханәсенең җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча әйдәп баручы белгече Валерия Белова ярдәмендә әзерләнде.

ЯҢА ЕЛ ТӨНЕНДӘ НӘРСӘ КИЯРГӘ

Яңа ел – гаилә белән каршы ала торган бәйрәм. Ничек каршы алсаң, шулай уздырырсың, диләрме әле? Кемдер кунакка бара, кемдер кунакларны үз өендә кабул итә, берәүләр затлы ресторанга бара, икенчеләр гадәти булмаган шартларда каршы алырга уйлап торадыр... Якынлашып килүче Юлбарыс елын кайда һәм ничек каршыларга уйласагыз да, киемегезгә игътибар бирергә онытмагыз. Ел хуҗасына нинди кием ошар икән? Күзәтүебез – шул хакта.

Юлбарыс киемгә карата артык зур таләпләр куймый. Шулай да ел хуҗасына ярарга тырышып, төрле җәнлек тиресе бизәкләрен хәтерләткән кием кимәгез, ул моңа шатланмас. Кием өчен нейтраль төсләр – аксыл көрән төснең ком, алтын төсмерләре урынлы булыр. Суның төрле төсмерләрен хәтерләткән күк, зәңгәр, фирүзә дә отышлы күренәчәк. Юлбарыс өчен төснең төсмере генә түгел, ә аның ачыклыгы да мөһим. Кызылның көрәнрәге, ягъни терракот төсендәгесе кулай булачак. Янып торган кызыл төс Юлбарысның ачуын китерергә мөмкин.

Өйдә гаиләгез белән генә утырсагыз да, бәйрәм киеменнән баш тартмагыз. Киемегез Юлбарысның игътибарын җәлеп итәрлек матур да, шул ук вакытта уңайлы да булсын. Теләсә нинди киемдә дә сез үзегезне патшабикәдән дә ким хис итәргә тиеш түгел.

Бәйрәм өчен җиңел, рәхәт, табигый тукымадан тегелгән күлмәккә өстенлек бирегез. Синтетик тукымалар, тире һәм мехтан тегелгән киемнәр быелгы Яңа ел төне өчен түгел. Күп катлы итәк, бер җил-кәсе ачык яисә кабарып тора торган җилкәле киемнәр Яңа ел төне өчен – менә дигән!

Бәйрәм киче өчен аксессуарларның су стихиясе төсендәгеләрен сайлау киңәш ителә. Бер генә булса да алтын бизәнү әйберен тагарга онытмагыз. Өстегездә өр-яңа, әле беренче тапкыр гына киелә торган кием дә булса, Яңа ел рухы ныграк сизелер.

Бәйрәм образын зур беләзек, озын яисә каурыйлы алкалар, төрле каеш, ефәк шарфлар белән тулыландырырга мөмкин. Матур булам дип, төрле металлдан эшләнгән ювелир эшләнмәләр белән артык мавыкмагыз, бәйрәм образын боза күрмәгез.

Яңа ел төнендә күзләрне һәм иренне аермачык күренеп торырлык итеп бизәнү дә килешә, тик артыкка китмәсен. Үзегезнең стильгә туры китереп, бераз ялтыравык алтын һәм көмеш өстәргә була.

Бәйрәм төнендә ирләр өчен иң отышлысы – гади классик костюм. Яңа елны өйдә генә каршыласагыз, рәсми булмаган күлмәк һәм чалбар – иң кулае. Джинсы чалбар белән йомшак тукымадан тегелгән футболка, свитер да ярый. Үзегезне иркен хис итә торган кием сайларга тырышыгыз.



Фото: www.pexels.com

ЯҢА ЕЛ МАКИЯЖЫ

Яңа ел төнендә күз явын алырдай буласыгыз киләме? Алайса, озакка сузмыйча, бәйрәм образын сайлап куегыз. Кием, прическаны гына кайгыртмагыз, ничек итеп бизәнәсегезне дә уйлап бетерегез. Яңа ел – ялтыравыкка бай бердәнбер бәйрәм. Киләсе ел символы моны тагын да ныграк таләп итә. Шуңа күрә дә макияжда глиттер (җемелди торган бөртекләр булган косметика) һәм пайеткалар булса яхшы. Күзгә акцент ясагыз. Визажист Ләйсән ХӘЙДӘРОВА ялтыравыклы «Смоки айс» макияж техникасын өйрәтер. Ул бар образга да килешә. Тик болай итеп бизәнсәгез, купшы прическалар ясамагыз. Чәчләрегезне хәзерге вакытта бик тә модалы булган «ат койрыгы» итеп җыя аласыз. Таратып җибәрсәгез дә килешер. Тик шуны онытмагыз: озын чәч тәрбияле булса гына матур. Макияж ясый башлаганчы битегезне чистартып, дымландырырга онытмагыз. Бит дымлы булмаса, тональ крем, кершән сөрткәч, вак җыерчыклар күзгә ташланып торачак.

Кичке макияж өчен тональ крем тыгыз текстуралы булса яхшырак. Тон сөрткәннән соң, яңак сөякләре астын чигәгә таба караңгылатабыз. Шул рәвешле яңакны «күтәртәбез». Моның өчен бронзатор кулланабыз. Биткә ул ял иткән төсмер бирәчәк. Шулай ук маңгайда чәч үскән зонаны, ияк асларын каралтабыз. Бу – йөзне бәләкәйләтер өчен лайфхак. Шулай ук борын яфракларына да тидерсәгез, борын кечерәк күренер.

Бит алмаларына румяна сөртәбез. Кичке макияжда куе алсу төсләр куллансагыз була. Макияж ялтырап торсын өчен, яңак сөяге, өске ирен өсләренә хайлайтер тидерәбез. Йөзне скульптуралауны кершән белән тәмамлыйбыз. Ул ялтыравыклы булса, тагын да яхшырак.

Кашларны махсус гель ярдәмендә өскә күтәртәбез дә шул төстәге карандаш белән буяп куябыз.

Кичке макияжда күзләр нык буялган булырга тиеш, ә озакка җитсен өчен, күз кабагына иң элек крем сыман тенины сөртәбез. Образыгызга туры китерелеп, ул кара, кара-көрән (коричневый), бронза төсләрендә булырга мөмкин. Без ясаган макияжда кара-көрән төс өстенлек итәр. Ул кызыл кием киючеләр өчен уңышлы булыр.

Өске һәм аскы керфек төпләрен, күзнең дымлы тышчасын да кара-көрән төстәге карандаш белән калын итеп буяп чыгабыз. Иң караңгы – кара-көрән төстәге тенины керфекләр төбенә сөртәбез. Шул ук гаммадагы бер-ике тонга яктырак төсне – күз кабагына, ә каш астына ачык төстәге тенины сөртәбез.

Каш астындагы сөяк өстенә тонык корректор тидерәбез. Аскы керфекләр тирәсенә дә караңгы төстәге тенины сөртәбез. Шул рәвешле күзне «ачабыз». Ахырда күз кабагы уртасына глиттер (ялтыравыклы махсус тенины) сөртәбез. Глиттерны кичке макияжда гына кулланабыз. Соңгы эш итеп тушь һәм аскы керфекләр тирәсенә консилер сөртәбез.

Әлеге макияжда ачык, янып торган төстәге иннекләр сөртү дә артык булмас. Хәзерге трендта бар да рөхсәт ителә. Образыгыз гына гармонияле булсын. Бүген тән төсендәге, кара-көрән төстәге иннекләр модада. Ирен читләрен дә кофе төсендәге карандаш белән йөртеп алыгыз. Хәзер бу – кабат актуаль. Глиттерлы помада буясагыз, иреннәрегез җемелдәп ялтырар. Яңа ел төнендә балкып торырсыз!

















QR-код аша кереп, күнегүләрне видеодан да карап ясый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.



Тыныч, тәвәккәл металл Үгезне 2022 елда кыю Юлбарыс алыштыра. Аның стихиясе – су. Хыял булып кына йөргән теләкләрегезне тормышка ашырыр өчен яхшы вакыт. Юлбарыс елы – кыю үзгәрешләр елы. Эш һәм яшәү урынын алыштыру өчен дә кулай. Киләсе елда яңалыкка омтылуга, яңа белем үзләштерүгә дә юллар ачык булачак. Үзегезне куркыныч астына куймасагыз, сәламәтлек белән авырлыклар туарга тиеш түгел.

Юлбарыс – үзсүзле җәнлек, үзе усал түгел. Ул һәрвакыт актив, кызыксынучан, табыш эзләгәндә курку белми, яңалыклар ярата. Юлбарыс билгесе астындагы 2022 ел энергияле, якты һәм көтелмәгән вакыйгаларга бай булачак.

Яңа ел алдыннан өегездә булган талисманнарны, үтеп баручы ел символларын ераккарак алып кую хәерле, Юлбарыс көндәшләр яратмый.

2022 елны өйдә яисә кунакта каршыларга була, әмма зур компанияләр белән җыелырга кирәкми. Юлбарыс, холкы буенча, тавыш яратмый, аңа уңайлы, тыныч мохит кирәк, шуңа күрә Яңа елга әкренләп хәзер үк әзерләнә башласагыз да була. Бәйрәм табынына туганнарны, якын дусларны гына җыю да Юлбарыс күңеленә хуш килер.

Яңа елны көлеп-шаярып, җырлап-биеп, төрле уеннар уйнап шат күңел белән каршы алыгыз. Кыю Юлбарыс актив кешеләрне үз итә!



Яңа елны көткәндә...

Бәйрәм табыны

Эскәтер һәм салфеткаларны яраштырып, ак һәм алтын төсләрдәгесен сайлагыз. Яңа ел төсләре буларак кабул ителгән яшел һәм кызыл төсләр быел артык булыр. Шулай ук табынга шәмнәр куюу үзенә күрә бер ямь өстәр. Тагын да матурлатасыгыз килсә, моның өчен кипкән җиләкләр, сәйләннәр яки чыршы уенчыкларын кулланып була.

Өстәлне ничек кенә бизәсәк тә, монда иң мөһиме – бәйрәм сые. Ул тәмле генә түгел, ә күзләрне дә җәлеп итәрлек булсын. Быел бәйрәм табынында итле ризыклар бигрәк тә хуплана – ел хуҗасы ерткыч җәнлек бит. Өстәлдә ит күбрәк булган саен, яхшырак. Кем кайсы итне хуш күрә, шунысын куя. Җиләк-җимешләрдән хөрмә, әфлисун, мандариннар булсын.

Иттән кала, табында яшелчәләр дә булу зарур: помидор, татлы борыч. Кабымлык өчен төрле рулетларны чиратлаштырып тезеп куярга мөмкин, үзенә күрә юлбарыс бизәген дә кабатлый бит.

Берничә төр ризыкны юлбарыс тиресеdәй итеп ясап бизәгез.

Өйне бизәү







Яңа елны каршы алырга әзерләнгәндә өйне әйбәтләп җыештырыгыз, артык, кирәкмәгән әйберләрегезне чыгарып ташлагыз, ләкин җиһазларны урыннарыннан күчермәгез. Йорт бизәүне фасадыннан ук башларга була. Ишегалдында кар сыннары ясап, гирлянда элү – әкиятне хәтерләтер.

Яңа елның аерылгысыз атрибутлары – җем-җем итеп янып торучы төрле төстәге утлар, шарлар булырга тиеш. Өй бизәү өчен табигый материаллар бик уңышлы булачак: эрбет агачы күркәсе, киптерелгән әфлисун телемнәре өйдәге бәйрәм рухын тагын да көчәйтеп җибәрәчәк.

Ел хуҗасы өйдә җылы, рәхәт булганны ярата, шуңа күрә диван һәм кәнәфигә йөнтәс плед ябып, йомшак мендәрләр куегез. Әмма артык ялтыравык әйберләр белән мавыгып китмәгез.



Яңа ел бүләге

- Якынлашып килүче елда бүләкләр файдалы да, шул ук вакытта матурлык, күңел өчен генә дә булырга мөмкин.
- Хатын-кызларга парфюм, картина, чигү, бәйләү кебек төрле кул эшләре өчен кирәк-яраклар бүләк итеп була.
- Ир кешеләрне яраткан шөгыльләренә, эшләренә туры килә торган әйберләр белән шатландырырга мөмкин. Мәсәлән, ау яисә балык тоту өчен кирәкле нәрсәләр.
- Юлбарыс – укыган кешеләрне хөрмәт итә. Димәк, китап – кем өчен дә яхшы бүләк.
- Актив тормышны үз итүче Юлбарыс елында төрле квестларга билетлар, матурлык салоннарына сертификат та кулай.

Яңа ел төне сынамышлары

- Өегездә бер генә булса да юлбарыс сыны торсын. Ул шәм дә, чыршы уенчыгы да булырга мөмкин.
- Акча янчыгыгызда акча булсын, ә ул өр-яңа булса, тагын да яхшырак.
- Юлбарыс, гадәттә, төннәрен бик актив була, шуңа күрә Яңа ел каршылаганда йоклап китмәгез.
- Быел ясалма чыршыдан баш тартып торыгыз. Өегезгә бер генә ботак булса да, чын чыршы алып кайтып куегыз.



Фото: www.pixabay.com

Бәйрәм табынына – деликатес

Яңа ел табынына нинди ризыклар әзерләргә икән дип, сез дә уйлап йөрисездер инде. Әйе, традиция буенча төрле салатлар, пилмән, мандарин булачак өстәлдә. Рубрикабыз кунагы – коллегабыз, журналист Ләйсән РӘХМӘТУЛЛИНА бәйрәм табынына чын мәгънәсендә деликатес тәкъдим итә. Рестораннарда гына сыйлана торган сарык кабыргаларын өйдә дә бик җайлы итеп пешереп була икән! Иң мөһиме – тиз дә эшләнә әле ул! Матур киемнәрегезне киеп табын артына утырганчы, тел йотарлык ризык әзер дә булачак. Кунакларыгыз гына түгел, Яңа – Юлбарыс елы да әлеге ит ризыгыннан канәгать калыр дип ышанабыз!



Кирәк

- 1 кг сарык кабыргалары;
- 300 г суган;
- 70 г соя соусы;
- 3 тырнак сарымсак;
- 2 аш кашыгы горчица;
- 1-2 ботак розмарин;
- ярты чәй кашыгы тоз;
- 2-3 данә дәфнә яфрагы (лавр);
- 2 аш кашыгы төрле тәмләткечләр: зира, кориандр, базилик, кара борыч.



Эш барышы

■ Башта ит өчен маринад әзерлибез. Суганны ярым боҗралап турап, шунда тоз салабыз. Суганның суы чыгарлык итеп әйбәтләп кул белән болгаткач, туралган сарымсак, горчица һәм соя соусын салып, тагын болгатабыз.

■ Сарык кабыргаларын юып, кирәкмәгән җирләрен кисеп алабыз. Иттә май калырга тиеш, газ мичендә пешкәндә ул эреп бетәчәк.

■ Шушы маринадка итне һәм калган тәмләткечләрне кушып болгатабыз. Итне маринады белән бергә пакетка салып, биш сәгатькә салкын урынга куеп торырга кирәк. Шунда ук пакетка берничә ботак розмарин да кушып җибәрәбез.

■ Соңыннан сарык итен шул пакет эчендә 180 градуска кадәр кызган газ мичендә бер сәгать пешерәбез.

■ Төрле тәмләткечләр кушып, озак итеп маринадланган сарык кабыргалары үз маенда бик тәмле булып пешә.

■ Кайнар итне өстәлгә салат яфраклары, розмарин яисә гранат җимешләре белән бизәп бирәбез. Гарнир өчен бәрәңге, яшелчәләр тәкъдим итәргә була.

Яңа ел сыегыз тәмле, өстәлләрегез мул булсын!



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.



санаторийга 2 юллама

Шифалы су-Ижминводы

Газета-журналларга язылу өчен кар көри торган җайланма, телевизор һәм башка бүләкләр

Бүләкләр 2022 елның 11 февралендә уйнатылачак

1 ЯЗЫЛ

2022 елның 21 гыйнварына кадәр «ТАТМЕДИА» АҖнең бер газета һәм бер журналына языл (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)

2 ҖИБӘР

«Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең копиясен безгә җибәр (телефон номерыгызны язарга онытмагыз). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 ОТ

электр иттарткыч, робот-пылесос, телевизор, кар көри торган җайланма. Төп бүләк — санаторийга 2 юллама



Тулырак мәгълүматны, акциянең узу вакытын, бүләкләр, аларны алу тәртибе турында tatmedia.ru сайтында белә аласыз. Акция 22.10.21–20.03.22 кадәр үткәрелә. Гаризалар 21.01.2022 кадәр кабул ителә. Оештыручы – ТАТМЕДИА АҖ. Товарлар рәсемдә күрсәтелгәннән үзгә булырга мөмкин. Реклама 16+

Укчы хатын-кыз

Җете, ачык, истә кала торган, дустанә – Укчы хатын-кызлар турында бу сүзләр. Аның белән теләсә нинди темага сөйләшергә мөмкин. Турысын әйтүе кайчак тирә-юньдәгеләрне үпкәләтә дә. Әлеге йолдызлыкта туганнар ирек ярата. Алар нечкә күңелле, хәтере тиз калучан.

Мәхәббәт. Горур һәм башбирмәс Укчылар тормыш юлдашын йөрәк белән генә түгел, акыл белән дә сайлый. Миһербанлы, олы йөрәкле кешене ул әллә каян сизә. Сайлаган яры кыю һәм тәвәккәл дә булырга тиеш. Сөйгән кешесе өчен әллә нинди корбаннарга бара ала. Ләкин хыянәтне мәңге кичерми. Тугрылык аның өчен – беренче урында.

Гаилә. Укчы хатын-кызларның күбесе гаилә корырга ашыкмый. Бу адымга барганда да хискә түгел, акылына таяна. Ышанычлы ир-егет янында ул кыюсыз бәләкәй кызчыкка әверелә белә. Укчы хатын-кызлар – көчле шәхесләр, гаиләдә дә ул тигез хокуклылыкка омтыла. Кемгәдер баш ию яки баш булырга омтылу Укчылар турында түгел.

Дуслык. Кешеләрне яраткан һәм яхшылыкка омтылган Укчылар өчен яңа танышулар бер йотым саф һава кебек. Чын дусларына ул һәрвакыт ярдәм кулын сузарга әзер. Кадерен белмәсәләр, ишекне шапылдатып ябып китәргә дә мөмкиннәр.

Карьера. Укчы хатын-кызлар – тормышта лидерлар. Алардан яхшы җитәкчеләр дә, менә дигән башкаручылар да чыга. Рухи канәгатьлек китергән теләсә кайсы эшне яратып башкаралар. Тиз кызыксыналар, шулай ук тиз сүрелергә дә мөмкиннәр. Укчыларга мәгариф, туризм, психология һәм иҗат өлкәсендәге эшләр күбрәк туры килә.

2022 елга гороскоп

Кучкар. Зәңгәр юлбарыс елы Кучкарларга үзгәрешләр алып килә. Моңа кадәр хыялда гына булган идеяләрне башкарырга мөмкинлекләр ачылыр. Интеллектыгыз һәм максатчанлыгыгыз сезгә ярдәм итәр.

Үгезбозау. Киләсе ел алдагыларыннан юмартрак булачак. Эштә күңелле яңалыклар көтелә. Җыелып килгән проблемаларны җиңел генә чишү юллары ачылыр. 2022 елны позитив дулкында уздырырсыз.

Игезәкләр. Тырышлык һәм үҗәтлек – иң кирәкле сыйфатлар. Дөньяга алсу күзлектән карарга өйрәнгән Игезәкләргә күктән җиргә төшәргә туры килер. Хәзер хыялланып утырыр чак түгел, җиң сызганып эшкә керешә торган чор.

Кысла. Яңа ел уңышлы башланып китәр. Тормышыгызда нииндидер зур яңалык булырга тора. Проблемалар туып торса да, аларны чишү юлларын да җиңел табарсыз. Гомумән, 2022 елда күтәрелүләр һәм төшүләр бик еш чиратлашыр.

Арыслан. Рухи яктан да, финанс ягыннан да үсеш көтелә. Үзегездә көч-куәт артканын тоярсыз. Ләкин амбицияләрне бераз йөгәнләргә дә туры килер. Кайчак компромисска бару – ул әле үз юлыңнан чигенү түгел.

Сөмбелә. Үзгәрүчән ел. Бер өлкәдә уңыш балкып елмайса, кайсыдыр өлкәдә кыенлыклар сагалавы бар. Финанс ягыннан бар да яхшы булыр. Ләкин нииндидер карар кабул иткәнче ныклап уйлагыз.

Бизмән. Киләсе ел күңелле яңалыклар һәм сюрпризлар елы булып исегездә калыр. Яңа перспективалар ачылырга тора. Әмма тормыштагы проблемалар беркая да китми. Бер адым ясаганчы, өч адымны алдан уйларга туры килер.

Чаян. Тыныч ел көтелә. Алга барырга комачаулаган киртәләрдән, ниһаять, арынырсыз. Акрын киткән – морадына җиткән дигән әйтем быел сезгә бигрәк тә туры килә. Карарлар кабул иткәндә ашыкмагыз.

Укчы. 2022 ел уңышлар алып килер. Тотрыклылык көтелә. Амбицияләрегезне тормышка ашырыр өчен яхшы вакыт. Ләкин гел уңышка гына өметләнмәгез, сикәлтәләр дә булмый калмас. Тырышлыгыгыз бәяләнер.

Кәҗәмөгез. Зәңгәр юлбарыс елы истәлекле вакыйгаларга бай булыр. Күп өлкәдә уңышка ирешерсез. Әмма моның өчен көчегезне дә, акылыгызны да аз сарыф итмәссез. Ашыкмагыз, язмыштан күбрәкне алырга тырышмагыз.

Сукояр. Холкыгызның яңа сыйфатлары ачыкланыр. Үзегезне бәхетлерәк, уңышлырак итеп хис итү сезгә яңа көч өстәр. Финанс ягын яхшырту өчен менә дигән мөмкинлек шәйләнә. Гомумән, ел тотрыклы һәм уңышлы булыр.

Балыклар. Шәхси өлкәдә дә, эштә дә күтәренкелек көтелә. Күптән уйлап йөргән проектларны тормышка ашыра башлау өчен кулай чор. Нәрсәгә тотынсагыз да, илаһи көчнең ярдәмен тоярсыз.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, Лилия ГӘРӘЕВА, Ләйсән РӘХМӘТУЛЛИНА әзерләде.

«СӨЕМБИКӘ» ЖУРНАЛЫНА ЯЗЫЛ ҺӘМ БҮЛӘК ОТ!

Кадерле укучыларыбыз арасында бүләк уйнатабыз

БҮЛӘКЛӘРЕБЕЗ УҢГАН ХУҖАБИКӘЛӘР ӨЧЕН ИҢ КИРӘКЛЕСЕ:



электр гриле

җиләк-җимеш киптерү җайланмасы

иттарткыч

Язылу квитанциясенең копиясен (телефон номерын куярга онытмагыз) 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт яисә suumbike@tatmedia.com адресына җибәрегез.

Квитанцияләр кабул итүнең соңгы көне — 25 гыйнвар.

Бүләкләр 28 гыйнварда уйнатылачак.

Нәтиҗәләрне февраль санында хәбәр итәрбез.

РЕКЛАМА

16+

ГЫЙНВАР

Д		3	10	17	24	31
С		4	11	18	25	
Ч		5	12	19	26	
П		6	13	20	27	
Җ		7	14	21	28	
Ш	1	8	15	22	29	
Я	2	9	16	23	30	

ФЕВРАЛЬ

Д		7	14	21	28
С	1	8	15	22	
Ч	2	9	16	23	
П	3	10	17	24	
Җ	4	11	18	25	
Ш	5	12	19	26	
Я	6	13	20	27	

МАРТ

Д		7	14	21	28
С	1	8	15	22	29
Ч	2	9	16	23	30
П	3	10	17	24	31
Җ	4	11	18	25	
Ш	5	12	19	26	
Я	6	13	20	27	

АПРЕЛЬ

Д		4	11	18	25
С		5	12	19	26
Ч		6	13	20	27
П		7	14	21	28
Җ	1	8	15	22	29
Ш	2	9	16	23	30
Я	3	10	17	24	

МАЙ

Д		2	9	16	23	30
С		3	10	17	24	31
Ч		4	11	18	25	
П		5	12	19	26	
Җ		6	13	20	27	
Ш		7	14	21	28	
Я	1	8	15	22	29	

ИЮНЬ

Д		6	13	20	27
С		7	14	21	28
Ч	1	8	15	22	29
П	2	9	16	23	30
Җ	3	10	17	24	
Ш	4	11	18	25	
Я	5	12	19	26	

ИЮЛЬ

Д		4	11	18	25
С		5	12	19	26
Ч		6	13	20	27
П		7	14	21	28
Җ	1	8	15	22	29
Ш	2	9	16	23	30
Я	3	10	17	24	31

АВГУСТ

Д	1	8	15	22	29
С	2	9	16	23	30
Ч	3	10	17	24	31
П	4	11	18	25	
Җ	5	12	19	26	
Ш	6	13	20	27	
Я	7	14	21	28	

СЕНТЯБРЬ

Д		5	12	19	26
С		6	13	20	27
Ч		7	14	21	28
П	1	8	15	22	29
Җ	2	9	16	23	30
Ш	3	10	17	24	
Я	4	11	18	25	

ОКТЯБРЬ

Д		3	10	17	24	31
С		4	11	18	25	
Ч		5	12	19	26	
П		6	13	20	27	
Җ		7	14	21	28	
Ш	1	8	15	22	29	
Я	2	9	16	23	30	

НОЯБРЬ

Д		7	14	21	28
С	1	8	15	22	29
Ч	2	9	16	23	30
П	3	10	17	24	
Җ	4	11	18	25	
Ш	5	12	19	26	
Я	6	13	20	27	

ДЕКАБРЬ

Д		5	12	19	26
С		6	13	20	27
Ч		7	14	21	28
П	1	8	15	22	29
Җ	2	9	16	23	30
Ш	3	10	17	24	31
Я	4	11	18	25	

ТАТМЕДИА



ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

WILDBERRIES



KazanExpress




OZON



Я Маркет







АО «ТАТМЕДИА». Адрес: 420066 г. Казань, ул. Декабристов, 2. ГРН 1071690057834

16+

Реклама